ӘДӘБИЯТ

6

ӘДӘБИЯТ 6

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

И Казан! Дәртле Казан!
Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Габдулла Тукай

Ф. Ә. Ганиева, И. Г. Гыйләҗев,
Ф. Ф. Исламов

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Тулыландырылган дүртенче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 373.167.1:821.512.145*06
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Г20

Ганиева Ф. Ә.— халык авыз иҗаты, Х. Туфан, И. Юзеев, И. Гази, Л. Ихсанова, Р. Миңнуллин, М. Мәһдиев, Ф. Яруллин бүлекләрен;
Гыйләҗев И. Г.— Г. Камал, С. Рәмиев, Ә. Фәйзи, Г. Ибраһимов, Г. Гобәй бүлекләрен; **Исламов Ф. Ф.** Ч. Айтматов бүлеген язды.

Фәнни редакторы — профессор *А. Г. Әхмәдуллин*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Ганиева Ф. Ә.

Г20 Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 6 нчы с-фы өчен дәреслек-хрестоматия / Ф. Ә. Ганиева, И. Г. Гыйләҗев, Ф. Ф. Исламов.— Тулыл. 4 нче басма. — Казан: Мәгариф, 2006.— 271 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1549-9

ISBN 5-7761-1549-9

© «Мәгариф» нәшрияты, 2000, үзгәрешләр белән
© «Мәгариф» нәшрияты, 2006, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Яңа дәреслекнең битләрен ачабыз.Ниләр көтә сезне анда?

Халыкның гасырлар буена да югалмыйча, җуелмыйча, аның рухын чагылдырып торган иҗатын өйрәнүне дәвам итәрбез. Сезнең, мөгаен, моңлы җырны ишеткәнегез бардыр. Ә нәрсә ул җыр яки моң дип уйлаганыгыз булдымы икән? Сөйләшүне шуннан башларбыз.

Кешенең бәхетле яки бәхетсез булуы нәрсәләргә бәйле? Тормышның матурлыгын ничек күрергә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ничек тоярга? Хискичерешләрнең нindиләре безгә таныш, гомумән, тормыш дигән зур төшенчә турында ни беләбез икән? Никадәр сораулар кызыксындыра кешене! Моңа кадәр уйлап карамаган булсак, бик күп сорауларны әдәбият үзе безнең алга куяр, һәм без алар ярдәмендә тормыштан да, әдәби әсәрләрдән дә җаваплар эзләрбез. Язучының таланты һәм хыялы ярдәмендә тудырылган гаҗәеп хикмәтле дөньяга сәяхәт ясарбыз.

Алай гына да түгел. Шигырьнең яки хикәяләп язган проза әсәренең теле ни өчен җырлап тора, күңелләрне җилкендерә икәнлегенә дә игътибар итми калмабыз. Нинди тылсым көче бар әдәби образда, тирән фикердә, нинди мәгънәләр яшерелгән хикмәтле сүзләрдә дип уйланырбыз, бергәләп җаваплар табарбыз.

Көч түгеп алган белем рухыбызны баетыр, акылыбызга көч өстәр, хыялыбызга канатлар куяр. Бер ел эчендә без тормышка тагын да якынаербыз, үзебезне дә, башка кешеләрне дә яхшырак таный һәм аңлый башларбыз. Матурлык, осталык дөньясына рәхим ит, укучы!

Халык авыз иҗаты

Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйланулары, тәҗрибәсен һәм хыяломтылышларын чагылдыра. Шулай да әкият, табышмак, мәкаль, мәзәк кебек жанрлар арасында җыр аерым бер урын алып тора. Әкиятне, мәзәкне берәү сөйли, башкалар тыңлый. Табышмакны берәү әйтә, тыңлаучылар җавабын табарга тиеш була. Ә менә җырны кеше үзе өчен генә дә башкара ала. Күңеле тулып моңайганда, ул ялгызы гына җырлап юана. Яки кәефе күтәренке булганда, үзалдына нидер көйләп, куанып йөри. Кешенең җаны, рухы әнә шулай җыр булып телгә килә, моң булып чыңлый.

ҖЫР

Халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушан көзгеседер. Бу бертөрле сихри көзгедер.

Габдулла Тукай

Җырны беренче булып уйлап тапкан кеше, мөгаен, «менә мин җыр иҗат иттем әле» дип уйламагандыр да. Ул кошлар сайраган, агач шаулаган, җил искән кебек, табигый итеп, үзе дә сизмәстән җырлап җибәргәндер. Хис-кичереш булып җырның сүзләре дә, көе дә берьюлы күңеленнән түгелгәндер. Әмма ул дөньяның яктырып, киңәеп киткәнен сизми калмаган. Бу матурлыкны тагын да кабатлыйсы килеп, якын кешесенә, туганнарына,

дусларына да җырлап күрсәткән. Шулай итеп, җыр, канатлы кош кебек, дөньяга таралган. Иң матурлары, башкалар да яратып тыңлаганы, кушылып җырлаганы күңелләрдән күңелләргә күчеп камилләшә барган. Анадан балага, буыннан буынга тапшырылып, халыкның уртак байлыгы булып, безнең көннәргә килеп җиткән.

«Әни» дип теле ачылганчы ук, һәркем әнисенең бишек җырын ишетә, шулай итеп, баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны, моңны таный башлый. Шуннан башлап кешене гомере буена җыр озатып йөри, якын сердәш тә, ышанычлы дус та һәм киртәләрне-чикләрне үтә торган хәбәрче дә ул — җыр.

Җырлар сүзләренең эчтәлеге, көенең яңгырашы ягыннан берничә төркемгә аерылалар. Бу төрлелек җырның кайсы чорда иҗат ителүенә, аның эчтәлегенә һәм башка сәбәпләргә бәйле. Борынгы халык көйләре, мәсәлән, күбесе озын, моңлы көйләр. Аһ-зар да, сагыш та яңгырый аларда. Әмма шул ук вакытта тормыш авырлыгына түзәрлек сабырлык, кайгыларны җиңәрлек көчле рух та бар. Иң кайгылы җырларда да явызлык, усаллык, ямьсезлек юк. Җырлар бары тик мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле булырга өйрәтә, татулыкка һәм бердәмлеккә чакыра.

Халкыбызның борынгы һәм иң матур җырларыннан берсе:

ГӨЛҖАМАЛ

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.
Нинди генә егеткә барырбыз дип, Гөлҗамал,
Колактан колакка гына сөйлиләр.
Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Сүзләренә игътибар итегез: энҗе бөртекләреннән генә тезелгән муенса кебек нинди матур сүзләр тезмәсе. Беренче ике җөмлә белән үк матур бер күренеш-картина ясап куелды — халыкның гасырлар буена

килгән тормыш-көнкүрешенә хас хезмәт процессы — җеп эрләү. Әмма ул көч куеп, тир түгеп башкарыла торган эш итеп түгел, ә ял итү, күңел ачу рәвешендә тасвирлана. Өстәвенә, чибәр, җиткән кызлар бергә кич утырырга җыелганнар; алар, мөгаен, иң матур киемнәрен кигәннәр, бизәнгәннәрдер.

Кыз бала үзенең киләчәген белергә тели, аңа өмет баглый. Күңелендәге хыялларын, хисләрен якын сердәшенә сөйли. Бу сүзләрне тыңлаганда без дә аның сердәшенә әйләнәбез, аңа карата күңелдә изге теләк туа. Кеше гомер буена үзенең якын, яраткан кешесе белән яшәү, бәхетле булу турында хыялланган.

Җырга матурлык өсти һәм аның борынгы җыр икәнен «әйтеп торган» сүзләр бар — шәмдәлләр (шәм куяр өчен махсус ясалган савытлар), киндер җеп эрләү, кызларның кул бавы — беләзекләр. Гөлҗамал исеме дә — «гөл» һәм «җамал» сүзләреннән ясалган гаҗәеп матур исем.

Инде көенә игътибар итегез. Һәр сүздә ничә борылыш, җәйге көндә тирбәлеп торган рәшә кебек серле авазлар агышы. Татар телен белмәгән халыклар да «Гөлҗамал» көен музыка сәнгатенең җәүһәре дип атадылар. Тыңлап туймаслык бу көй безнең иң зур хәзинәләребездән санала. Аны сүзсез генә көйләсәң дә яки музыка коралында уйнасаң да, ул бик күп мәгънәләрне аңлата ала, хыялны үзенә ияртеп алып китә.

Көе сүзләренә гаять килешеп, ярашып торган тагын бер җырны алыйк.

КӨЗГЕ АЧЫ ҖИЛЛӘРДӘ

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул.
　　Йөгереп китәрдәй булам ла,
　　Кайтып җитәрдәй булам
　　Көзге ачы җилләрдә лә
　　Туган-үскән илләргә.
Бетсен патша, янсын тәхет,
Безгә сугыш кирәкми шул.
　　Йөгереп китәрдәй булам ла,
　　Кайтып җитәрдәй булам

Көзге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә.
Без утырган машинаның
Тоткалары җиз генә шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә лә
Туган-үскән илләргә.
Бер илләрдән чыгып киткәч,
Кайтып булмый тиз генә шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә лә
Туган-үскән илләргә.

Бу җыр исә сүзләренең мәгънәсе, төзелеше һәм көенең башкарылу тизлеге (ритмы), аһәңе белән алдагы җырдан аерылып тора. Сүз «без» исеменнән бара, ниндидер зур тарихи вакыйгаларга багышланган. Аның чакыру, өндәү рухында булуы күмәк башкарылырга, зур мәйданда яки поход чыкканда җырланырга җайланган икәнлеген күрсәтеп, шуңа ишарәләп тора. Музыка белгечләре, бу җыр беренче бөтендөнья сугышы елларында иҗат ителгән, диләр. Революция һәм гражданнар сугышы вакытында ул аеруча киң таралган, заман рухына туры килгән җыр була. Танылган әдип Гомәр ага Бәширов: «Көзге ачы җилләрдә» дигән җырны без, яшь сугышчылар, 1920 елның җәендә Врангельгә каршы сугышка чыгып китәр алдыннан, бөтен рота һәм батальоныбыз белән Казан урамнарында җырлап йөрдек»,— дип искә ала (*Җ. Фәйзи.* Халык җәүһәрләре. — Казан, 1971).

«Көзге ачы җилләрдә» җыры хәзер дә яратып башкарыла, чөнки анда бүген дә бик әһәмиятле булган, безнең тормышыбызга турыдан-туры кагылган фикерләр әйтелә. Сугышны булдырмау — татар халкының гына түгел, җир йөзендәге барлык халыкларның уртак теләге. Туган җирне йөгереп кайтырдай булып сагыну хисе — шулай ук һәркемгә таныш, кадерле хис. Көенең дәртле, ышанычлы яңгыравы хәтерләү өчен җиңел, башкару өчен җайлы, матур булуы да бүгенге көн рухына

туры килә. Гомумән, җырлар, халкыбызның рухи мирасы булып, югалмыйча саклансыннар өчен, сәхнәләрдән, радиодан еш яңгырарга тиешләр.

Алда тыңлаган җырларның кушымта өлешләре көйгә күмәк кушылу, аны күтәреп алу, тагын да дәртлерәк яңгырату өчен уңайлы. Бер үк сүзләр кабатлана, ләкин төп өлештәге сүзләр мәгънәне көчәйтәләр. Әйтерсең лә җырны чыгаручы кеше «менә шушы сүзләрне исеңдә калдыр, шуның өчен өзелә минем үзәгем» дип әйтергә тели.

Халык җырларының тагын бер үзенчәлекле ягына игътибар итик. 1—2 юллар белән 3—4 юллар арасында, беренче карашка, бәйләнеш юк кебек. «Күлдә балык тоту», «машинаның җиз тоткасы» җыр текстына очраклы гына килеп кергән төсле. Әмма алар тормыштан алынган, халыкның язмышын чагылдырган бик мәгънәле сүзләр: «безгә балык эләкми», ягъни без язмышка хуҗа түгел, яки без утырган машиналар безне туган илдән еракларга алып киттеләр дигән мәгънәләр яшерелгән аларда. Менә шул эчке бәйләнеш, мәгънәви бердәмлек җырны бербөтен итеп, матурлап тора. Охшаш яңгырашлы сүзләр (рифмалар) дә җыр текстын берләштерүче салават күпере кебек җемелдәп торалар: эләкми — кирәкми, җиз генә — тиз генә, китәрдәй булам — җитәрдәй булам, җилләрдә — илләргә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Эчтәлеге яки яңгырашы буенча әлеге тыңлаган җырларга якын булган тагын нинди халык җырларын беләсез?

2. Җырларның исемнәре аның тексты, эчтәлеге белән бәйләнгәнме? Аларны башка сүзләр белән алыштырып буламы?

3. Халык җырларын сез каян яки кемнән ишетеп беләсез?

4. Халык җырларын аеруча яратып һәм оста башкаручы артистларны әйтегез.

Һәр заман үз җырын тудыра, дип әйтәбез. Бик борыңгыдан иҗат ителә килгән җырларны без эчтәлегеннән, көенең озын, моңлы булуыннан танып алабыз. Аларның күбесен, борынгы бабаларыбыз җырлаган кебек, музыка коралларына кушылмыйча да җырлап

була. Мондый вакытта без җырчының тавышын, көйдәге һәр борылыш, бизәкне аеруча ачык ишетәбез.

Хәзерге заманга якынлашкан саен, җыр күмәк башкаруга һәм төрле уен коралларына яраклаша, көйләнә бара, яңгырашы, рухы да үзгәрә. Бигрәк тә революциядән соң халык иҗаты өчен шартлар үзгәрә: хор белән җырлау, сәхнәдән башкару халык җырын композиторлар язган көйләргә якынайта төшә. Шул ук вакытта илдә, халык тормышында булган вакыйгалар да җырда чагыла башлыйлар. Борынгы җырларның матурлыгы, әһәмияте, кирәклеге аз гына да кимеми, киресенчә, яңа заман җырлары аларның урынын түргә, дәрәҗәлерәк урынга күчерә бара. Бүгенге халык иҗатчылары, махсус югары белемле композиторлар да борынгы көйләр матурлыгына, алардагы камиллеккә омтылалар.

Совет чорында иҗат ителгән берничә җыр белән танышыйк.

ТУГАН ИЛ

Нәкый Исәнбәт сүзләре

Китми күңелемнән минем һич
Шул сөекле илкәем.
Анда минем туган халкым,
Анда сөйгән әнкәем.

Анда таңнар җәйге диңгез
Балкуыннан нурлырак.
Анда җырлар сандугачның
Сайравыннан моңлырак.

Анда, сайрар кош шикелле,
Көй суза гармуннары.
Сызыла иркен тын һавада
Анда ил-зар моңнары.

Анда җырлый җирдә һәр таш,
Анда җырлый һәр агач.
Анда кайтсам, мин дә башка,
Анда мин дә — сандугач.

«Туган ил» — күп мәгънәле төшенчә. Бу сүзләрне без, шул илнең гражданины буларак, горурланып әйтәбез; Татарстан — туган республикабыз дип, татар халкының туган иле мәгънәсендә дә кулланабыз; үзебез туган авыл яки шәһәр турында сөйләгәндә дә, туган як, туган төбәк мәгънәсендә Туган ил дип зурлап эндәшәбез.

Халык көенә иҗат иткән җырында Нәкый ага Исәнбәт менә шул мәгънәләрнең барысын да сыйдырган, бергә җыеп алган да әйтерсең төрле чәчәкләрдән матур бәйләм ясаган. Шагыйрьнең нинди чагыштырулар куллануына игътибар итик. Күңелдән китми торган сөекле ил сөйгән әнкәй белән, таңнар җәйге диңгез балкуы белән, җырлар сандугач сайравы белән, гармун сайрар кош белән, шагыйрь үзе, ягъни «мин» образы, сандугач белән чагыштырылган, хәтта алардан өстенрәк тә куелган. Туган илне ярату, сагыну хисе шулкадәр көчле, җыр безне хыял дөньясына алып китә — анда җирдәге һәрбер таш, һәр агач та җырлый! Әлбәттә инде, чынлыкта таш белән агач җырламый, ә хисләре ташып торганга шагыйрьнең күңеле «җырлый», шуңа күрә дә җыр безнең күңелләргә дә килеп кагыла, без дә кушылып җырлыйбыз.

Сүз кем исеменнән бара икән? Җыр бит ул бер генә урынга беркетелмәгән, шуңа күрә дә аны канатлы дип әйтәбез. Чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган кеше туган ил турында тирән сагыш, сагыну хисе белән җырларга мөмкин. Бу вакытта көй моңлы-сагышлы булып яңгырый, өметсезлек һәм шул ук вакытта туган илгә бер әйләнеп кайту хыялы да була ул монда. Ә инде кыска вакытка гына туган ягыннан аерылган, тиз көннән кайтачагы билгеле булган кеше җырласа, ул өмет һәм ышаныч белән, минем әйләнеп кайтырга менә нинди матур илем — өем бар дип, куанып җырлый. Көйнең яңгырашы да үзгәрә, мондагы сагыш кими, дәрт-ышаныч өстәлә. Сандугач үз оясында яшәгәндә, үз куагына басып сайрагандагы кебек, җырлаучы да туган җирләренең гүзәллеге белән хозурланып, горурланып моңлана. Бу инде — якты моң, яшәү яме булып, үзеңнең бәхетле икәнеңне тоеп хисләнү.

Шулай да бу җыр, иң беренче чиратта, чит җирләрдә яшәгән кешенең җан авазы булып яңгырый. Юл

аралаш кабатланып торган «анда» сүзе ераклык, аерылганлык турында «сөйләп» тора.

Туган җир турында тантаналы рухтагы, күңелле көйләргә якынрак булып яңгыраган җырлар да иҗат ителгән. Шундый бер җырга мөрәҗәгать итик.

ЯШӘ, РЕСПУБЛИКАМ!

Биек тауның башларында
Уйный каплан баласы.
Яшә, минем республикам,
Яшә, Казан каласы!

Аккош чума күлләргә,
Былбыл куна гөлләргә.
Җырлый-җырлый, без барабыз
Алдагы шат көннәргә.

Безнең илләр — ямьле җирләр,
Үсә бездә ал гөлләр.
Гөлләр кебек матурлана
Безнең хәзерге көннәр.

Бу җыр 20 нче еллар башында Татарстан автономияле республикасы төзелү уңае белән чыгарылган. Халык әйтерсең үз дәүләтенең данын еракларга яңгыратырга теләгән, үз гимнын иҗат иткән. «Биек тау» дигәндә халык үзенең зурлыгын яки тау башына салынган Казан каласын күздә тоткандыр. Аккош, былбыл, ал гөл сурәтләре — халык иҗатының барлык жанрларында еш очрый торган образлар.

Җырның көе куплет белән кушымтага бүленүне саклаган, баштагы өлеше кызурак, икенче өлеше исә салмаграк ритмга корылган.

Халык җырлары вакытлар үтү белән яңара, төрләнә бара. Шулай да халык җырларының, гомумән халык иҗатының, иң гүзәл үрнәкләре — борынгы чорда иҗат ителгәннәре. Бүген кешенең хис-кичерешләрен, тормыш турындагы уйлануларын чагылдыра торган сәнгать чаралары күптөрле: җыр-бию янына опера,

балет, кино сәнгатьләре килеп кушылды, магнитофон, телевизор, радио туктаусыз уйнап, җырлап тора. Элекке заманда боларның барысын да моңлы җыр алыштырган. Салават күперендәге төсләрне, чәчәкләрнең җилдә тибрәлүе кебек нәфислекне, суның агышы кебек тылсымлы борылышларны халык җыры үзенә җыеп алган. Җырны башкаручылар да үз тавышларындагы сагышмоңны, иркәләү-яратуны җырга кушып җибәргәннәр, көйнең моңын көчәйткәннәр. Күкрәкләрне тутырып иркен сулыш алган җырчы, әйтерсең киң болыннар, биек тауларга эндәшеп, аларга тиң булып җырлаган. Моңны дәрьяга тиңлиләр — ул күңелләрне биләп ала, аны кошка тиңлиләр — ул күкләргә күтәрә һәм кешене көчле рухлы итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әле тыңлаган яки үзегез белгән җырларда нинди чагыштырулар таба аласыз?

2. «Мин» исеменнән һәм «без» исеменнән җырланган җырларда нинди аерма күрәсез?

3. «Моң» дигән төшенчәне ничек аңлатыр идегез? Ул җырның сүзләре белән бәйләнгәнме, көе беләнме? Мисаллар китерегез.

Җырлар халык авыз иҗатының иң күп санлы һәм төрлелеге ягыннан да иң бай өлешен хасил итәләр. Музыка белгечләре, көенең үзенчәлегеннән чыгып, җырларны дүрт төркемгә бүләләр: авыл көйләре, озын көйләр, кыска көйләр, такмаклар.

Халык иҗатын өйрәнүче галимнәр җырларның нинди уңай белән, кайда башкарылуына карап, түбәндәге жанрларны билгелиләр: йола җырлары (мәсәлән, туй җырлары), уен җырлары, хезмәт җырлары, иҗтимагый тормышны чагылдырган җырлар, тормыш-көнкүреш җырлары, лирик җырлар.

Җырның эчтәлегенә, тематикасына карап та төркемләргә мөмкин. Җыр китаплары, гадәттә, шундый бүлекләрдән тора.

Шушы төрлелек, жанр байлыгы җырларның халык тормышында аерылгысыз юлдаш булганлыгы, кешеләрнең һәрдаим җырны кирәксенеп, аны иҗат итеп торуларын да аңлата. Берничә мисал китерик. Сез аларны кайсы төркемгә кертер идегез?

АЙ БЫЛБЫЛЫМ

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделнең камышы.
Таң алдыннан чут-чут килә
Сандугачлар тавышы.

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата.
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата.

Ай былбылым, вай былбылым
Кунып сайрый талларга.
Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга.

Сораулар

1. Бу җырда нинди кичерешләр, нинди халәт чагыла?
2. Кабатланган сүзләр, тезмәләр җырга нинди төсмер бирәләр?
3. Бу җырны кемнәр башкаруында ишеткәнегез бар?

САБАН ТУЕ

Сабан туе — хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе шул,
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
Бәйрәм итик көн буе.

Шау-гөр килә киң болыннар,
Кырлар һәм су буйлары шул,
Котлы булсын, авылдашлар,
Ямьле Сабантуйлары!

Бәйрәм итик шатланышып,
Туганнар, бергә-бергә шул,
Безнең бергә булуыбыз
Китсен бөтен гомергә.

Танылган татар композиторы Җәүдәт Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» (Казан, 1971) дигән китабында мондый юллар бар: «Бу җыр ифрат матур, һәм халыкның бәйрәм хисләрен чагылдырган сүзләре белән ул күңелле көйләрнең классик үрнәге булган «Алмагачлары» белән янәшә басарлык. Сүзләрен 1940 елда, Гөлсем Сөләйманова соравы буенча, шагыйрь Мөхәммәт Садри язган. М. Садри сүзләрен халык үзенеке итеп кабул итте».

Сораулар һәм биремнәр

1. «Сабан туе — хезмәт туе» дигәндә башта һәр сүзнең аерым мәгънәсенә игътибар итегез, аннан соң сүз тезмәләренең гомуми мәгънәсен аңлатыгыз. Сабан туен күргәнегез бармы? Бу бәйрәмнең нинди үзенчәлеге бар? Көйнең рухы, яңгырашы нинди? Эчтәлеккә туры киләме? Җырның төрен, жанрын билгеләгез.

ШОМА БАС

Гамир Насрый сүзләре

Уйнат, уйнат гармуныңны,
Биесеннәр егетләр.
Безнең илнең егетләре
Бары да бөркет кебекләр.

Кушымта:
Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз.

Сайрат, сайрат гармуныңны,
Җилкенсеннәр яшь кызлар.
Безнең кызлар нурлы йөзле,
Әйтерсең лә йолдызлар.

Кушымта.

Шаулат, шаулат бию көен,
Ашкынсыннар барысы да.
Яшь егетләр чакырсыннар,
Кызлар чыксын каршыга.

Кушымта.

Әйдә, әйдә катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр.
«Баскан җирдән ут чыгара
Безнең яшьләр» дисеннәр.

К у ш ы м т а.

Җырның янәшәсендә генә, аның аерылгысыз юлдашы булып, бию яши. Бигрәк тә күңелле, шаян җырлардан биюгә күчеп китүе җиңел. Эштән туктап торган арада, яшьләр җыелган җирдә җилкенеп биеп алулар — электән килгән матур бер гадәт. Ләкин бит бию өчен дә көй кирәк. Уен коралы булмаганда да аптырап калмаганнар — такмак әйтеп, бик җиңел көйгә җырлап торганнар. Такмакларның аерым бер көйгә салынганнары да, «Өммегөлсем», «Эпипә», «Әнисә» кебек теләсә нинди бию көенә җырлана торган, эчтәлекләре ягыннан үзара бәйләнмәгән бик күп сандагы шигъри тезмәләр дә бар. Такмакларның максаты — биючегә (яки биючеләргә) ритм биреп, аларны дәртләндереп тору.

Сабантуйларында, төрле бәйрәмнәрдә халыкның җырлап-биеп күңел ачу рәвеше булган бу сәнгать төре соңгы елларда сәхнәләргә менде, төрле спектакльләрнең, концертларның аерылгысыз бер өлешенә әверелде.

Кыска, күңелле җырлар, такмаклар, уен җырлары — күңел ачу чарасы гына түгел, буыннан буынга тапшырылып килә торган осталык, тапкырлык, әдәп кагыйдәләреннән торган бер мәктәп тә. Мәсәлән, «Шома бас» такмагы — шундыйларның берсе.

Такмаклар — җырның үзенчәлекле төре, ул, башка жанрлар кебек, көй белән артык тыгыз бәйләнмәгән. Сөйләшкәндә дә без «такмак җырлау» димибез, «такмак әйтү» дибез. Такмакның көйсез әйтелә торганнары да бар. Балаларның уен такмаклары (мәсәлән, санамышлар) яки табигатькә дәшеп әйтелә торган такмаклар (яңгыр теләгәндә, тилгәнне куганда һ. б.) моңа мисал була ала.

Җыр турында сөйләшүгә йомгак ясыйк.

1. Халык авыз иҗатының башка төрләреннән аермалы буларак, җыр сүз сәнгате генә түгел, ул көй белән, музыка сәнгате белән дә бәйле.

2. Өстәвенә, җ ы р әле ул тагын бер осталыкны, тагын бер иҗатчыны таләп итә. Бу талант иясе — җырлаучы, башкаручы. Җырның ни дәрәҗәдә моңлы, тәэсирле булуы җырчының тавышына, сәләтенә бәйле.

3. Шулай да җ ы р н ы ң иң әһәмиятле үзенчәлеге — аның әйләнә-тирәдәге тормышны матурлап, бизәп торудан тыш, һәркемнең күңелендә, һәр кешенең рухи байлыгы булып яшәвендә. Җырның көен, сүзләрен уйлап табучы да, аны башкаручы да үз кичерешләре, тормышка мөнәсәбәтләре турында сөйлиләр.

Сәнгатьнең күп төрләре югары дәрәҗәгә ирешкән, опера һәм балет театрлары гөрләп эшләп торган бүгенге чорда халык җырлары югалып калмадымы дигән сорау туарга мөмкин. Зур сәхнәләрдә композиторларыбыз иҗат иткән көйләр яңгырап тора, концертлар куела.

Әмма иң куанычлысы шул: Тукай әйткән «сихри көзге» — халык җырлары көннән-көн кадерлерәк була бара. Илһам Шакировның иҗади батырлыгы — халык моңын сүндерми саклавында. Бүген аның исемендә җыр ярышлары үткәрелә һәм җырчыларның осталыгы борынгы халык көйләрен башкара алулары белән бәяләнә.

Татар халкының горурлыгы, җан авазы булган Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев фестивальләре үткәрелә. Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Әлфия Афзаловалар башкаруындагы халык җырлары тарихка китеп югалмыйлар, рухи байлык, бәяләп бетергесез хәзинә булып, безнең буынны киләчәк буыннарга ялгап торалар.

Биремнәр һәм сораулар

1. Җыр турында мәкальләр, әйтемнәр һәм матур фикерләр җыеп, дәфтәрләрегезгә языгыз.

2. Халкыбызның үз туган якларына, авылларына атап чыгарган җырларын «Җырлар китабы»ннан эзләп, әти-әниләрегездән, әби-бабаларыгыздан сорап язып алыгыз. Кем күбрәк җыр таба алыр?

3. Кызлар исеме белән аталган җырларны барлап карагыз. Бу җырларга исем нәрсәдән чыгып бирелгән?

4. Җыр дәфтәре башлап, анда яраткан җырларыгызны язып барыгыз.

Әдәбиятта драматургия үзенә аерым бер урын алып тора. Драма әсәрен укып чыгу гына җитми, аны уйнап, башкарып күрсәтергә кирәк. Шуңа күрә аны сәхнә әсәре дип тә әйтәбез. Драматургиягә театр, ягъни махсус бина, җиһазланган сәхнә, уенны башкаручы артистлар, аларга киңәш бирүче режиссер кирәк.

Күп кешеләрнең уйланулары, тырышлыклары һәм осталыгы нәтиҗәсендә башкарылган уенны без с п е к т а к л ь дибез. Шулай да, театр яшәсен өчен, аның төп иҗатчылары — драматурглар булу шарт. Татар театрының формалашуына гаять зур өлеш керткән, татар драматургиясенә нигез салучылардан булган күренекле әдип Галиәсгар Камал иҗаты беренчеләр рәтендә тора.

Галиәсгар Камал
(1879—1933)

Татар театрының тарихы Г. Камал исеме белән бик тыгыз бәйләнгән. Игътибар итеп барыйк әле: 1906 елның 22 декабрендә Казанда беренче мәртәбә татарча «Кызганыч бала» исемле спектакль куела. (Хәзер бу көн татар театрының туган көне булып билгеләп үтелә.) Шушы зур тарихи вакыйганың сәбәпчесе — Г. Камал, чөнки төрек язучысы Намикъ Кәмалнең «Кызганыч бала» исемле әсәрен татарчага ул тәрҗемә итә. Танылган төрек язучысы белән татар драматургының фамилияләре бер булу да игътибарны җәлеп итә.

Татар театрының яшь башлавы Г. Камалны гаять рухландыра. 1907 елда ул унтугыз яшендә үк язган «Бәхетсез егет» драмасын зурайтып, яңа фикерләр өстәп

кабат эшли. Әсәр шул ук елны сәхнәдә куела да башлый. Тәрҗемә иткән һәм үзе язган әсәрләренең исемнәре дә охшаш: «Кызганыч бала», «Бәхетсез егет». Язучы үз чорында яшәгән кешеләрнең, аеруча яшьләрнең, язмышлары өчен борчыла. Ни өчен кешеләрнең тормыш юллары төрле, бәхетсезлек каян килә, сәбәпләре кайда, дип уйлана.

Г. Камал спектакльләргә үзе дә бик теләп катнаша, яшь актерларга киңәшләр бирә. Театр дөньясына үзенең энеләрен — Габдулла белән Габдрахманны да алып килә. Алар соңрак Камал I, Камал II исемнәре белән актер һәм режиссер буларак танылалар.

Шулай да Г. Камалның тормышы каршылыксыз гына бармый. Шактый кырыс табигатьле әтисе аны башта укымышлы мулла яки сәүдәгәр итү өчен тырыша. Г. Камал кискен рәвештә баш тарткач, аны, бай кызына өйләндереп, «тәүфыйкка» утыртмакчы була. Ярый әле өйләнгән кызы укымышлы, аның күңелен, максатларын аңлый торган кеше була, язучының талантын күрә белә, иренә ярдәмче булып яши.

Сүзне беренче мәртәбә татарча спектакль куелудан башлап киткән идек. Татар дөньясында зур шау-шу тудырган бу вакыйга Г. Камал иҗатына менә дигән «азык» була, үзен һәм театрның дошманы булган каенатасын «сәхнәгә чыгарырга» да мөмкинлек туа.

Драматургның замандашы, күренекле артист Габдулла Кариев спектакльдә Хәмзә бай ролен шулкадәр оста башкара, башка артистлар да шулкадәр яратып уйныйлар, «Беренче театр» тамашачылар иң күп йөри торган спектакльгә әйләнә. Бу турыда Фатих Әмирхан болай дип яза: «Г. Камал әфәнденең бу комедиясе нәкъ театр мәсьәләсенең кайнаган вакытында чыгуы белән бигрәк әһәмиятледер. Татарча театрларга мөхалиф[1] кешеләр үз кыланышларын шул ук татар театрына барып күрсеннәр» (*Ф. Әмирхан.* Сайланма әсәрләр. 2 том.— 287 б.).

Комедия — көлкеле вакыйга һәм хәлләрне тасвирлаучы, кеше характерындагы йомшак яки кимчелекле якларны арттырып, көчәйтеп күрсәтүче һәм тормыштагы кире, зарарлы сыйфатларны кискен рәвештә тәнкыйтьләүче әсәр.

---

[1] Мөхалиф — каршы булган, дошман.

«Беренче театр» комедиясендә нинди вакыйга тасвирлана, без кайсы урыннарда, ни өчен көлеп җибәрәбез яки елмаеп куябыз, кемнәрне яклыйбыз — әсәрне шуларга игътибар итеп укыйк.

БЕРЕНЧЕ ТЕАТР

Комедия бер пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Хәмзә бай — иске фикерле Казан бае; башында ак бүрек, яшел кәләпүш, өстендә намаз туны, аның эченнән бишмәт, аның эченнән кыска җиңле камзул кигән. Чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.

Гафифә — Хәмзә байның кызы.

Вәли — Хәмзә байның кияве.

Хәбибрахман — Хәмзә байның улы, аңгыра.

Факиһә — Хәбибрахманның хатыны.

Биби — Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.

Фатих — Хәмзә байның кибетчесе.

Вакыйга Казанда, Хәмзә байның өендә бара.

Бай сымак бер өй. Ике якта икешәр ишек. Түрдә тәрәзәләр, тәрәзә арасында көзге. Стена буенда урындыклар. Сул тарафта бер диван. Аның алдында өстәл. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Вәли күренә; өстенә пальтосын кигән, кулына таяк тоткан, күңеле бик шат, өйнең бер башыннан бер башына кызу-кызу атлап йөри.

Вәли *(кычкырып)*. Гафифә! Гафифә!

Гафифә *(бүлмәдән, сузыбрак)*. Әү!

Вәли. Буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам.

Вәли. Тизрәк бул! *(Халыкка таба карап.)* Гафифә дисәң Гафифә, бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә дип коты чыга, аның каршында «ир кеше» дигән сүз «ерткыч җанвар» дигән сүз белән икесе бертигез. Бары мин генә ул кадәр куркынычлы җанвар түгел. Башта миннән дә коты очты. Соңыннан, минем тарафтан шул

яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды. *(Ян ишеккә барып, ишеккә башын тыгып.)* Һи! Әле тиз генә буласың юк икән. Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс. *(Башын бүлмә ишегеннән алып, халыкка таба карап, куллары белән хатын-кыз битенә пудра сөрткән төсле итеп күрсәтеп, бераз көлебрәк.)* Бизәнә, мич акшарлаган шикелле итеп, битләрен буяп маташа. Шулай да булса, үзенә килешеп тора тагын. *(Ян ишеккә бара, карый, төсләрен бозып.)* Ул нишләвең инде? Мин монда кайчаннан бирле кайчан киенеп бетерә инде дип көтеп торам.

Гафифә *(бүлмәдән)*. Йә, ярар ла, хәзер булам, пудра матур төшмәгән.

Вәли. Тизрәк бул инде, зинһар! *(Башын бүлмәдән алып, ишекне ябып, халыкка таба карап.)* Менә сиңа кирәк булса, мин инде өстемә пальтоларымны кигәнгә бер сәгать булды. Ә ул әле һаман пудра ягынып бетерә алмый; пудра ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята. Әле ярый, көзге ямьсез күрсәтә дип, көзгене бәреп ватмаган. *(Уң як ишектән, кулына поднос белән чынаяклар күтәреп, Биби узып бара.)*

Вәли *(Бибине күреп)*. Әй, Биби, тукта әле!

Биби *(борылып карап)*. Нәрсә дисең?

Вәли. Кара әле, ә!..

Биби. Карыйм ич инде!

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим, нинди нәрсәдер.

Вәли. Тфү, черт! Сөйләп бетергәнне көт!

Биби. Йә, көтәм.

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим!

Вәли *(ачуланып)*. Тыңлап тор дим мин сиңа!

Биби. Тыңлыйм ич!

Вәли. Тыңласаң шул: менә без хәзер театрга китәбез...

Б и б и. Кая?

В ә л и. Театрга!

Б и б и. Нәрсә төятергә?

В ә л и. Баш төятергә.

Б и б и. Нинди баш?!

В ә л и. Атаң башы! Мин сиңа төятергә димим, театрга дим, аңладыңмы, театрга дим!

Б и б и. Йә, аңладым инде, театрга, ул нинди җир соң?

В ә л и. Анысы сиңа кирәк түгел. Без китқәч, каенатай кайтыр, ул сорар безне, «кайда киттеләр?» дип. Син аңа әйт: «Кодаларга киттеләр»,— дип. «Театрга киттеләр» дип әйтмә!

Б и б и. Сорамаса нишләрмен?

В ә л и. Тик торырсың!

Б и б и. Ярый. *(Кереп китә башлый.)*

В ә л и. Тукта әле! *(Биби туктый.)* Син, аңгыра нәрсә, рәтләп әйтә дә белмәссең әле.

Б и б и. Нишләп белмәскә!

В ә л и. Йә, әйтеп кара әле, ничек дип әйтерсең икән?

Б и б и. «Вәли җизниләр театрга китмәделәр, кодаларга киттеләр» диярмен.

В ә л и *(ачуланып)*. Иштең ишәк чумарын! Мин сиңа алай дип әйттеммени?

Б и б и. Соң ничек дидең?

В ә л и. Мин сиңа «театрга киттеләр» дип әйтмә, «кодаларга киттеләр» дип әйт дидем.

Б и б и. Мин дә бит «киттеләр» димәдем.

В ә л и. Фу, җәфа икәнсең, кайдан башыма бәла алдым! Менә син яхшы тыңла: әгәр дә каенатай безне «кая киттеләр?» дип сораса, «кодаларга киттеләр» диген. Башка сүз әйтмә, бар, юлыңда бул!

Б и б и. Ярый. *(Кереп китә.)*

В ә л и *(үз-үзенә)*. Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә юләр: миңа ни эшкә кирәк иде аңар театр дип сөйләп торырга? Мин аңа дәрес әйтәмме? *(Ишектән Гафифә килеп чыга. Аңа карап.)* Нихәл, буласыңмы инде?

Г а ф и ф ә. Хәзер булам инде. Нәрсәгә шаулашасыз икән дип карарга гына чыккан идем.

В ә л и. Әнә шул бар ич әле, бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем. «Без хәзер театрга барабыз» дигән идем, «нәрсә төятергә?» дип, миннән сорап ята.

Г а ф и ф ә. Ул һәрвакыт шулай. Һич аңламый ул. Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. «Абыстай Гарифәнең алдырган кислотасы юк микән? Бик күңелләрем болганып тора. Үзебездә судысы бар барын да, ирләр өйдә вакытта кислота алдырырга онытылган»,— дип әйтте дип сора дигән идем, барган да: «Абыстай, киез каталарын биреп торсыннар ла»,— дип сорап, миңа кислота урынына киез ката күтәреп кайткан. Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керерлек булдым.

В ә л и. Йә, ярар, аларын башка вакытта сөйләшербез, театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!

Г а ф и ф ә. Хәзер булам. Ә, ни, синнән шуны гына сорыйм дигән идем. Ул театрда кеше күп булыр микән?

В ә л и. Һу! Күп булмыймы соң! Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач, инде бөтен шәһәр халкы агылыр.

Г а ф и ф ә *(борыннарын җыерып, иркәләнгән бала кыяфәтендә)*. Әй! Әем! Алай булгач, мин бармыйм ла, анда кеше күп булгач, мин оялам.

В ә л и *(үз-үзенә)*. Менә сиңа кирәк булса! *(Алдына карап, башын бераз кашып.)* Ничек булыр икән соң? Юк, минемчә, әле бу көн кеше ул кадәр үк күп булмас. Күбесенең картлары җибәрмәс. Кайсыберсе кеше сөйләүдән куркып калыр.

Г а ф и ф ә *(янә әүвәлгечә)*. Алай булгач, без дә бармыйк: мин дә кеше сөйләүдән куркам. Әти белсә, ул да ачуланыр.

В ә л и *(бик тирән уйга калып, башын күтәреп, халыкка таба карап)*. Уттан котылдым, инде суга төштем. Моннан инде ничек котылырга? *(Гафифәгә карап.)*

Мин бит инде, анда барырга дип, билет та алып кайткан идем.

Гафифә. Кайтсаң ни! Бармый калган булгач, акчаңны кире кайтарып алырсың.

Вәли. Бер алган булгач, кире кайтармыйлар шул инде аны.

Гафифә. Теләсәң ни эшлә, мин барырга куркам!

Вәли. Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар.

Гафифә. Ашамасалар да, мин бармыйм, кирәкми.

Вәли. Юк инде, бармый калырга ярамый, барабыз! Ул бит бик күңелле була. Үзеңнең дә көлә-көлә эчләрең катып бетәр.

Гафифә. Андый көлкеләрне ат кәмитендә дә бик күп күргән инде. Монда да әллә нинди артык җире булмас, кирәкми, мин бармыйм.

Вәли. Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә көчләмим, үзем генә барам.

Гафифә. Ә, ярар менә, барыр идең бугай, кара син аны, анда ялгыз гына кызлар карарга бармакчы була. Җибәрәмме соң мин сине, Алла боерса, гомеремдә ялгыз җибәрмим!

Вәли. Теләсәң ни эшлә, мин бармыйча калмыйм. Син бармыйсың икән, мин үзем генә тотам да барам! Хуш, сау бул, мин киттем. *(Чыга башлый.)*

Гафифә *(тиз генә Вәлинең артыннан барып тота)*. Йә, йә, бетте, мин юри генә әйттем. Әйдә, мин дә барам.

Вәли *(кире кайтып)*. Ну, әйдә, алайса, барсаң, тизрәк киен!

Гафифә. Хәзер киенәм. *(Бүлмәгә таба бара башлый. Соңра янә борылып.)* Кара әле, анда өскә киенгән көенчә генә утыралармы?

Вәли. Юк, салып утыралар.

Гафифә. Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз.

Вәли. «Бармыйбыз» дип сөйләмә, мин барам, киттем, алайса. *(Чыга башлый.)*

Г а ф и ф ә. Барам, барам!!

В ә л и *(мыскыл итеп)*. «Барам, барам!» Ә үзе һаман терәлеп тора. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Син, шулай итеп матaшып, мине уеннан калдырмакчы була торгансыңдыр, ахры. Уен башланырга бары ярты гына сәгать калган.

Г а ф и ф ә. Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям.

В ә л и. Ну, бар, зинһар, тизрәк бул.

Г а ф и ф ә *(ишектән керә башлый да, янә борылып)*. Нинди күлмәгемне киим икән: асылынмы, йонынмы?

В ә л и *(үз-үзенә)*. Асыласың килсә, асыл инде. *(Гафифәгә.)* Зинһар, мине йөдәтмә. Эстәдең ни[1] ки: асылмы, йонмы, сатинмы, батисмы, ситсымы — минем өчен бар да бер.

Г а ф и ф ә. Ярый, алайса, мин зәңгәр асылымны киям. *(Китә башлый.)*

В ә л и. Әй, юк тукта әле, зәңгәр асылыңны кимә, нинди булса да берәр йон күлмәгеңне ки. Сезнең андый чачаклы-чуклы карават чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк. Без анда бүләк багарга[2] бармыйбыз, уен карарга барабыз.

Г а ф и ф ә. Алай булгач, нинди йон күлмәгемне киим?

В ә л и. Теләгәнеңне ки.

Г а ф и ф ә. Теге гармун итәкле кызыл йон күлмәгем ничек булыр?

В ә л и. Шәп булыр.

Г а ф и ф ә. Аның шул буе озын булган. Чәнчелеп беткән җөйче[3], шулкадәр әйттем: «Факиһәнеке төсле матур булсын, яхшы итеп тек»,— дип. Бозып кына бирде. Юкка гына дүрт тәңкә акча әрәм иттем. Моннан ары, Алла боерса, гомердә ул хатынга тектермәм.

В ә л и. Ярый, шулай итәрсең. Бар, тизрәк бул.

---

[1] Э с т ә д е ң н и — теләгәнеңне.

[2] Б а г у — карау.

[3] Җ ө й ч е — тегүче.

Гафифә. Соң кайсын киим?

Вәли. Башкасын.

Гафифә. Теге, буйга буф бөргән сирый күлмәгемне киимме?

Вәли. Ки.

Гафифә. Ул да шул бик килешеп бетми, чабулары бик тар булган.

Вәли. Алайса, бүтәнне ки.

Гафифә. Ал йон күлмәгем ничек булыр?

Вәли. Бик ал булыр.

Гафифә. Кызылы?

Вәли. Бик кызыл булыр.

Гафифә. Яшеле?

Вәли. Бик яшел.

Гафифә. Соң ниндиен киим?

Вәли. Матурракны.

Гафифә. Теге шикалат төсле, тоташ буйлы, бантиклы күлмәгемне кисәм ничек булыр?

Вәли *(шатланган булып).* Һу! Менә, менә, эзли торгач таптың, ахры, бик һәйбәт булыр. Үзе шикалат төсле дә булгач, бигрәк шәп була инде ул. Чөнки шикалат — бик тәмле нәрсә.

Гафифә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак җиң[1]. Килешмәс. Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер юньле, матур күлмәгем юк.

Вәли. Соң бит аны хәзер генә тегеп булмый лабаса, уф Алла! Бар икән кылану, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда. Сезне көтеп, уеннан калыр хәлем юк. *(Чыгып китә башлый.)*

Гафифә *(артыннан барып җитеп, Вәлинең җиңеннән тотып, ялынган рәвештә).* Йә инде! Ни эшләвең инде ул? Торасың да чыгып китәм дип куркыта баш-

---

[1] Сак җиң — тар җиң.

лыйсың. Мин сиңа бармыйм дип әйтмим ич! Әйткәч, ни була соң инде? Мин синнән әллә нәрсә сорамыйм бит, бары тик нинди күлмәгемне киим дип кенә сорыйм.

Вәли. Мин сиңа әйттем бит инде. Теләсәң нәрсә ки дип. Миңа дисәң, бөтенләй бернәрсә дә кимә.

Гафифә. Соң шулай диген аны. Яхшылап кына сораганда, тотасың да ачулана башлыйсың. Алай булгач, ярый торган булса, мин бернәрсә дә кимим, шушы өстемдәге күлмәгем белән генә барам.

Вәли *(йөзләре яктырып)*. Һай, бәрәкалла! Бик яхшы булыр, бар. Зинһар, тизрәк. Өстеңә генә ки дә, хәзер китәбез. *(Гафифә ашыгып кереп китә.)* Уф Алла, җаным чыга язды. *(Ишеккә барып карап.)* Яңадан тагы бер-бер нәрсә тапкан булып чыга күрмәсен,— ә, юк икән. *(Ишекне яба.)* Киенә икән, ахырында мең бәла белән көчкә җиңдем. Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак башы кадәр генә булса да бер революция булды. Ярый, ни булса да булды, минем максудым[1] булды. *(Кулларын угалап.)* Их хозур! Хәзер театрга китәбез. *(Таягын ике кулының бармак очлары белән генә тотып, сүз арасында төрле шатланган һәм мәсхәрә кылган кыяфәтләргә кереп җырлый.)*

Бүген театр була, трат-та-та, трат-та-та!
Шатлыктан күңелем тула, трат-та-та, трат-та-та!
Картның кәефе бик китә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Уйнаучыларны тетә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Барам мин театрга, трат-та-та, трат-та-та!
Хатыным белән бергә, трат-та-та, трат-та-та!
Кайнатай кайтып кергәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Безнең киткәнне күргәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Ачуланса да курыкмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Барыбер сүзен тотмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Кайтып кергәчтен тузар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бөтен кәефне бозар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бозса бозар кәефне, трат-та-та, трат-та-та!
Хәзергә мин кәефле, трат-та-та, трат-та-та!

---

[1] Максудым — максатым.

Гафифә *(ишектән өстенә киенгән көенчә чыгып).* Йа, бар икән Ходаем, тагы нәрсә юләрләнәсең? Әллә син дә кәмиттә паяз[1] булмакчы буласыңмы?

Вәли. Әһә! Булдыңмы әле син, аппагым? Әйдә, алайса, киттек инде, былбылым! *(Гафифәне култыклап чыгып китәләр.)*

Сораулар һәм биремнәр

1. Беренче күренешнең эчтәлеген сөйләгез.
2. Вәлинең ни өчен күңеле бик шат? Шулай икәнлеге аеруча кайсы урында күренә? Гафифәне ул ни өчен ашыктыра?
3. Гафифәне нинди итеп күз алдына китердегез? Вәли аның турында ни дип сөйли?
4. Вәли белән Гафифә ни өчен тиз генә җыенып чыгып китә алмыйлар? Сәбәпләрен санап чыгыгыз. Ул сәбәпләр җитдиме әллә түгелме?
5. Биби образы кайсы яклары белән көлкеле итеп тасвирланган?

Сәхнә буш кала.

Бераздан бик кызуланып, уң як ишектән **Факиһә** килеп керә.

Факиһә *(ян-ягына карап).* Монда да юк! Болар кая киткәннәр? *(Ишекне ачып кычкыра.)* Биби! Биби! *(Биби чыга.)* Син беләсеңме?..

Биби. Беләм!

Факиһә. Беләсең икән, әйт, алайса: кая киттеләр җизниләр?

Биби. Алар, син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр.

Факиһә. Соң ничек дип кенә әйттеләр.

Биби. Абзый сораса, «кодаларга киттеләр» дип әйтерсең диделәр.

Факиһә. Ә башка кеше сораса?

Биби. Башка кеше кем сорасын? Фатих абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Факиһә. Менә мин сорыйм.

Биби. Син башка кешемени?

---

[1] **Паяз** (паяц) — клоун.

Ф а к и һ ә. Йә, әйт инде, кая киттеләр?

Б и б и. Әй лә, әйтмим!

Ф а к и һ ә. Театргамы?

Б и б и. Ә! Үзе дә белә икән. Аны сиңа кем әйтте?

Ф а к и һ ә. Йә, бар. Алдыңа кара, эшеңне эшлә... *(Биби кереп китә.)* Шул, шул, театрга киткәннәр. Мин үзем дә сизгән идем аны сизүен. Җизни ул безнеке шикелле җебегән авыз түгел. Исенә бернәрсә килеп төште исә, хәзер шул минут ук эшли дә ала. Безнеке генә ул тегермән ташы шикелле, һич кузгатыр хәл юк. Тукта әле, мин дә алып бардырыйм әле. Кеше барган җирдән мин генә ни эшләп калып торырга соң? *(Бик кызуланып, сул як ишеккә кереп китә. Сәхнә бераз буш тора. Бераздан, кычкырышып, Хәбибрахман белән килеп чыгалар.)*

Х ә б и б р а х м а н *(кулларын селтәп)*. Бармыйм дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.

Ф а к и һ ә *(мыскыл итеп, бармакларын бөкләп санарга керешә)*. Бу булды бер!

Х ә б и б р а х м а н. Икенчедән, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Ф а к и һ ә. Ике, өч.

Х ә б и б р а х м а н. Анда кергәч тә нинди урынга утырырга?

Ф а к и һ ә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә; кеше ишетсә, «моның белгән нәрсәсе бар микән?» ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйбыз, мин куркам.

Ф а к и һ ә. Чү, чү, тагы куркуыңнан егылып китә күрмә! Шулкадәр зур гәүдәң белән «куркам» дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйм!

Ф а к и һ ә. Нинди бармаган да, нинди нитмәгән! Кеше барган җирдән без генә калып торырга! Әйдә, әйдә

барабыз! Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкигә дә чыктылар[1]. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык, кияве белән кызы барган булгач, әткәй дә бер сүз әйтә алмас. Әйдә, тотабыз да барабыз. Нәрсәгә соң без генә ул кадәр куркып торырга!

Хәбибрахман *(башын кашып).* Белмим шул, ничек булыр икән? Минем үземнең дә бер күрәсе килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Әле мин син йөдәтерсең дип әйтмәгән идем. Гайнулла җизнинең кияве Гаптерәхимнәр дә «барабыз» дигәннәр иде.

Факиһә. Соң, алай булгач, тагын ни кирәк инде? Кеше бармый торган җирмени ул? Кеше баргач, бергәбергә күңелле дә булыр. Әйдә, өстеңә киен дә, барабыз. Мин дә хәзер киенеп чыгам. *(Кызуланып, уң як ишеккә кереп китә.)*

Хәбибрахман *(ишеккә таба карап, үз-үзенә).* Мин әле барам дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмадым, ә ул киенергә дә кереп китте. Нишләргә икән инде, шулай ук барырга туры килер микәнни? Әти орышмас микән? Без чыгып киткәнче, кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул әтинең гадәте начар икәнен белми. Беркөнне Гали хаҗи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. *(Борып күрсәтә.)* Күзләремнән утлар күренде. Аны кешегә сөйләп йөреп булмый. «Әти колакны борды» дип хатынга әйтсәң, хатын хәзер ул: «Һәй, нәни бәби! Шул башың белән колагыңны бордырып торасыңмы?» — дип мыскыл итәргә тотына. *(Кесәсен капшап.)* Барабыз баруын да, әле кесәдә барырлык акча бар микән? *(Портмонетын алып, акчаларын өстәлгә бушатып саный.)* Унбиш тиен дә унбиш тиен — утыз тиен, тагын унбиш тиен, була кырык биш тиен. Тагын биш тиен, булды илле тиен, илле тиен дә егерме тиен, була җитмеш тиен. Тагын илле тиен. *(Бармаклары белән исәпләргә керешеп)* Йөз, йөз ун, йөз егерме, булды бер

---

[1] Плашкигә чыгу — табигать кочагында ял итү.

сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... *(Янәдән исәпләп.)* Ике, өч, дүрт, дүрт сум да егерме тиен. *(Портмонетына сала.)* Өч тәңкәсенә билет алсак, каладыр бер сум егерме тиен. Анысы барырга-кайтырга булса, хәер, җитә икән җитүен, түлке бер дә барасы килми шул. Ичмаса, әти дә кайтмады. Әллә бармыйм микән? Ничек итеп бармый калырга? Ә, булды. Менә монда качып утырам да, әти кайткач кына торып чыгам. *(Диван башына барып посып утыра. Факиһә килеп чыга.)*

Ф а к и һ ә *(үз-үзенә)*. Әле һаман теге ужым бозавы киенеп чыга алмаган икән. Нишләп тора икән инде тагын? *(Сул як ишеккә кереп китә.)*

Х ә б и б р а х м а н *(башын бераз күтәреп карап, бик шатланып)*. Аллага шөкер, котылдым, күрмәде. Әти кайтыр инде.

Ф а к и һ ә *(ишектән чыгып)*. Анда юк, әллә кая киткән, шундый чакларда, анасы кыйнамасын дип качкан балалар шикелле, куча торган гадәте бар иде, бер-бер җирдә качып тормыймы? *(Әзләргә тотына. Почмакта тора торган кресло артларын карый, Хәбибрахман бу вакытта, балалар шикелле, башын эчкә яшерә. Факиһә килеп күрә дә, акрын гына көлеп, диванның икенче башына барып, аягы белән идәнгә тибеп кычкыра.)* Һәй, бәдбәхет! Күсе бар!

Х ә б и б р а х м а н. Һай! *(Сискәнеп сикереп тора.)*

Ф а к и һ ә *(мөстәһзианә[1] көлеп)*. Һа, һа, һа! Анда син бар идеңмени? Мин белмәдем. Ул кадәр куркытмаган булыр идем. Анда ни эшләп утырасың?

Х ә б и б р а х м а н *(ни әйтергә дә аптырап торып)*. Акчам төште. Шуны аладыр идем.

Ф а к и һ ә. Нинди акча?

Х ә б и б р а х м а н. Менә театрга барырга акча җитә микән дип санап торадыр идем дә, берсе төшеп китте.

Ф а к и һ ә. Шул гомердән бирле әле өстеңә киенмичә акча санап тордыңмы?

---

[1] М ө с т ә һ з и а н ә — мыскыллап.

Х ә б и б р а х м а н. Мин хәзер киенәм. Башыма бүрек киям дә тунымны гына киям. *(Кереп китә.)*

Ф а к и һ ә *(кычкырып кала)*. Кара аны, анда да кәнәфи башына акчаңны төшермә, анда да күсе булыр. *(Көзге каршына килеп шәлләрен, калфакларын төзәтә башлап.)* Ну, ир соң! Ир димәсәң, хәтере калырлык бар. *(Ишеккә карап.)* Биби! Биби! *(Биби чыга.)* Әткәй безне «кая киттеләр?» дип сораса, «кодаларга киттеләр» диген.

Б и б и. Ник, анда җизниләр киттеләр бит. Сез дә шунда барасызмыни?

Ф а к и һ ә. Без театрга барабыз, әмма син шулай дип әйт.

Б и б и. Ярый, әйтермен. Бая җизни, син әйтә белмәссең дип, мине яңадан әйттереп карап маташа.

Ф а к и һ ә. Әйтә белдеңме соң?

Б и б и. Ник белмәскә, белдем.

Ф а к и һ ә. Йәле, тагын әйтеп кара. Безне кая киттеләр диярсең икән?

Б и б и. Әллә белмәс дип беләсеңме? Мин инде аны Фатих абыйдан күптән өйрәнеп куйдым. «Театрга киттеләр» диярмен.

Ф а к и һ ә. Һи, аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа шулай дип әйтергә куштыммыни?

Б и б и. Ник, үзең әйттең ич. «Җизниләр кодаларга киттеләр, сез дә шунда барасызмы?» — дигәч, «юк, без театрга барабыз» дип.

Ф а к и һ ә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла. Әгәр дә әткәй сораса, «кая киттеләр?» дип, «кодаларга киттеләр» диген.

Б и б и. Ярый, ярый, аңладым. «Икесе дә шунда киттеләр» диярмен.

Ф а к и һ ә. Кая?

Б и б и. Кодаларга.

Ф а к и һ ә. Бар, эшеңдә бул! *(Биби кереп китә. Хәбибрахман тунының югары төймәсен төймәли-төймәли чыга.)*

Х ә б и б р а х м а н. Әйдә, булдым.

Ф а к и һ ә. Әйдә, әйдә, булсаң, тизрәк атла аягыңны. *(Ишектән чыкканда, Хәбибрахманның аркасыннан этә.)*

Х ә б и б р а х м а н. Тукта! Төрткәләмә инде ул кадәр! Чыгам ич. *(Чыгып китәләр.)*

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу күренештә нәрсә турында сүз бара?

2. Хәбибрахман кем ул? Аның нигә театрга барасы килми? Хәбибрахманның көлкеле сыйфатлары, кыланышлары турында сөйләгез.

3. Факиһә белән характерлары охшаганмы? Нинди аерма бар? Театрга барырга Факиһә Хәбибрахманны ничек итеп күндерә?

Сәхнә буш кала. Бераздан Ф а т и х килеп керә.

Ф а т и х *(як-ягына каранып)*. Абзый кая икән соң әле? Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде. Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп. Эһем, эһем. *(Тамак кыра.)* Әллә бөтенләй өйдә юкмы? *(Ишекләрне карана.)*

Б и б и. Эһем, эһем. *(Ишектән чыга.)* Нәрсәгә тамак кырып йөргән буласың?

Ф а т и х. Абзый өйдәме?

Б и б и. Өйдә.

Ф а т и х. Ни эшли?

Б и б и. Тире җыеп күн эшли.

Ф а т и х. Йә, шаярма әле, чынлап әйт әле, өйдәме?

Б и б и. Ни эшкә ул сиңа?

Ф а т и х. Кирәк.

Б и б и. Әүвәле әйт ни эшкә икәнен, аннан соң әйтәм.

Ф а т и х. Йә, әйт инде, шаярма.

Б и б и. Нәрсә бирәсең, әйтәм.

Ф а т и х *(шаярып)*. Әйтсәң, сине үземә хатынлыкка алырмын.

Б и б и. Һи, мәхәббәтсез!

Ф а т и х. Мәхәббәтсез? Мин нишләп мәхәббәтсез булыйм? Кара бу мыекларны! *(Мыекларын борып күрсәтә.)* Кызларның калфак чугына ярарлык.

Б и б и. Йә, күп телеңә салынып торма монда, бар, чык!

Ф а т и х. Ник, шулай ук мине яратмыйсыңмыни? Мин сине әле абзыйдан сорарга дип менгән идем, анда ялгыз гына күңелсез.

Б и б и *(боргаланып)*. Һай, конарсыз[1] !

Ф а т и х. Кызларның шул булыр инде аларның, алар һәрвакыт шулай һавалы булалар. Кызлар алар, яшь чагындарак, патшага барам мин, дип торалар да, ди, аннан ары, санатка дип әйтәләр, ди; ул да эләкмәгәч, актыгында, солдат булса да ярар, дип әйтәләр, ди.

Б и б и. Йә, йә, бар, мыскыл итмә! Бар, чык! Абзый кайтыр, абыстай да хәзер менәр.

Ф а т и х. Күптән шуны әйтергә кирәк, мин синнән баядан бирле: «Абзый өйдәме?» — дип сорыйм ич. Өйдә булмаса, хуш сау бул. *(Чыгып китә.)*

Б и б и *(үз-үзенә)*. Ялганлый торгандыр ла ул, мине алдар өчен генә, юри генә әйтә. *(Кереп китә, бераздан Хәмзә бай кайтып керә. Күрмиенчә, ишек төбенә җәеп куйган паласка сөртенә.)*

Х ә м з ә *(кычкырып)*. Гөнаһ шомлыклары! Аяк астына әллә нәрсә җәеп куйганнар. Мал кадерен белмиләр. Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да бернәрсә дә күреп булмый. *(Күзлеген сөртә.)* Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге[2] башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем. *(Ишек янындагы урындыкка утырып.)* Әй, кая, кайсыгыз бар анда? Аякны тартыгыз әле. *(Биби килеп чыга.)* Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың, тарт аякны! *(Биби салдыра башлый.)* Чү, чү, чү, карап тарт! Мәсихемне[3] бозма! Абыстаң кая? *(Биби киез итекнең берсен салдыра.)*

[1] К о н а р с ы з — мәхәббәтсез.

[2] Ә ч е л е к т ә г е — мәдрәсәдәге чишенү бүлмәсе.

[3] М ә с и х е м н е — таһарәтемне.

Б и б и. Аш өендә.

Х ә м з ә. Нишли анда?

Б и б и. Аш пешерә.

Х ә м з ә. Ник, килен кая?

Б и б и. Алар Хәбибрахман абый белән ни... ни... әй... кодаларга киттеләр.

Х ә м з ә. Ыграк тарт! Кулың черегән мәллә! *(Биби, кинәттән тартып җибәреп, Хәмзәне егып төшерә.)* Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә. *(Биби кире китә. Хәмзә, мәшәкатьләнеп, аягын салып бетерә.)* Башка кеше булса, мин аңа кирәгеннән биргән булыр идем булуын, әллә ничек, кыз балага сугарга ул кадәр кул барып җитми. *(Туныи салып, чөйгә элеп куя.)* Бүген иртә белән чәч алучыга кергән идем, бөтенләй ишегеннән керер хәл юк. Җыен кызыл авыз кибетчеләр тулган. Байларына бөтенләй әйләнеп тә карамыйлар, чәч алучысы да һич санга санамый. «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытлары булмый»,— дип, авыз ерып тик тора. *(Чалбар балагын җыеп бәйләп куйган тасмаларын чишә.)* Алары да шул кибетчеләр яклы. Аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң? Кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар. Аларга бай акчасы кызганычмыни... Биби, Биби! *(Ишектән Биби чыга.)*

Б и б и. Нәрсә дисез, абзый?

Х ә м з ә. Бар әле, берәрсенә әйт әле, мәдрәсәдәге Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый чәч алырга чакыра»,— дисеннәр.

Б и б и. Нинди мәче алырга?

Х ә м з ә. Һай, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени! Чәч алырга дим! Чәч! *(Үз чәчен тарткалап.)* Менә, менә шушыны алырга дим! *(Биби чыгып китә.)* Бу кадәр аңгыра булырлар икән. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: «Бар, агач базарына Хисмәткә бар да аны тизрәк монда алып

кайт»,— дип җибәргән идем, барган да бер зур кисмәк алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде. Әле ярый хәзергә үзем исән. Үзем үлгәч, болар дөньяда ничек итеп көн күрерләр? *(Биби ишектән килеп чыга да тик тора. Аңа карап.)* Нихәл, нишләп терәлеп торасың анда?

Биби. Абзый, Миңнебай абзыйга әйткән идем: «Коръән укый торган шәкертне алып чык»,— дип, «Нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк»,— ди.

Хәмзә *(аяк тибеп)*. Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, мәчеттә Коръән укый торган шәкертне — Гайфулланы чакырып чыксын!

Биби. Икесен дә чакырсынмы?

Хәмзә. Нинди икесен дә?!

Биби. Коръән укучыны да, Гайфулланы да?

Хәмзә. Үләм инде, мин сезнең белән җәфаланып үләм! Аңгыра. Соң шул Коръән укучы шәкерт белән Гайфулла икесе дә бер ләбаса инде! Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы! *(Биби чыгып китә.)* Менә инде син сөйләш алар белән. И Алла! И Алла! Ахры инде, дөньяда акыллы кеше үк калмагандыр. Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чигә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр. Тукта инде, әүвәл тизрәк чәчемне алдырыйм да аннан соң, тәһарәт алып, вирдләремне[1] укырмын. *(Ишеккә таба борылып.)* Әй! Кая сез! Башымны чылатырга сабын, су бирегез. *(Ишектән кереп китә, бераздан, чынаяк, поднослар күтәреп, Биби керә.)*

Биби. Үзләре юньләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар. *(Чәй урыны әзерли, өстәлнең почмагына самовар, поднос, аның янына зәңгәр эмалированный полоскательный куя.)* Көне-төне эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн орыш та талаш. Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга

---

[1] Вирдләремне — догаларымны.

киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын. *(Ишектән Хәмзә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән. Бер кулына яшел кәләпүшен, бер кулына күзлеген тоткан.)*

Хәмзә. Бар, миңа муенга салырга эскәтер китер! *(Биби чыгып китә. Хәмзә өстәл янына килеп, пласкательный янына кәләпүшен, аның янына күзлеген куя. Биби бер каралган кызыл эскәтер китереп бирә. Бибигә карап.)* Кая, миңа урындык бир әле. *(Кызыл эскәтерне муенына бәйли, Биби урындыкны китереп бирә. Янә Бибигә карап.)* Бар әле, теге якта камут тартмасында минем блитывам бардыр, шуны монда китер. *(Биби чыгып китә, Хәмзә урындыкка утыра.)* Заманалар бозылды. Әле менә бүген теге урыс сымак нәрсәләр театр уйнап, динне мәсхәрә кылмакчы булып йөриләр икән. Шуны булдырмаска йөреп, бүген ясыйгка[1] бара алмый калдым. «Уйнатмагыз, рөхсәт юк!» — дип, Җамали үндергә[2] әйткән идек, ул: «Минем эшем түгел, пристефкә[3] үзенә әйтегез»,— диде. Пристефне өйдә туры китереп булмады, галавага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк: «Минем эшем түгел, сез палисәмистерга[4] барыгыз»,— диде. Аңа барган идек, бакзалга киткән. Губирнаторга да барган идек, бутишник: «Ул бу вакытта кеше кертми, иртәгә сәгать 12 гә килегез»,— диде. Шулай итеп, ахрысы, бәдбәхетләрне туктатып булмады. Алла боерса, икенче вакыт уйнатмабыз әле, пристефне алдан күреп куярбыз. *(Ишектән Биби килеп керә, аңа карап.)* Нихәл, булдымы?

Биби. Менә булды. *(Бритваны өстәлгә китереп куя.)* Коръән укучы шәкерт өйдә юк, ди, иптәшләре белән театрга киткән, ди.

---

[1] Ясыйг — кояш баегач укыла торган намаз.

[2] Үндер — урядник *(рус сүзе)*, тәртип саклаучы.

[3] Пристеф — полиция бүлеге башлыгы (пристав).

[4] Палисәмистер — шәһәрнең полиция башлыгы (полицмейстер).

Хәмзә *(ачуланып)*. Ходай орган икән! Йөзләре генә кара булсын, бар, чакыр монда Фатихны!

Биби. Фатих абый ул син кайтканчы ук чыгып китте.

Хәмзә. Кая?

Биби. Шунда китте.

Хәмзә *(ачуы тагын да кабарып)*. Кая шунда?

Биби. Шунда инде, театрга китте.

Хәмзә. Ә? Театрга? Кемнән сорап китте?

Биби. Берәүдән дә сорамады. Вәли кияүләр белән Хәбибрахманнар да киткәч, мин генә нишләп калыйм, диде дә китте.

Хәмзә *(тәмам алакайланып)*. Ә? Ни дисең? Вәли кияү дә китте дисеңме?

Биби. Китте.

Хәмзә *(урыныннан сикереп тора)*. Хәбибрахман да киттеме? *(Бибинең өстенә бара.)*

Биби *(кире чигенеп)*. Китте.

Хәмзә *(яңадан өстенә барып)*. Гафифә? Факиһә?

Биби *(яңадан чигенеп)*. Алар да киттеләр. *(Хәмзә кулларын йомарлап, иреннәрен тешләп, «эмммм!» дип, Бибинең өстенә килә башлый, Биби чыгып кача.)*

Хәмзә *(Биби чыгып киткәч, халыкка таба карап, кулларын сузып)*. Йә, әйтегез инде, зинһар, нишләтим боларны? *(Гайрәтләнеп.)* Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны! Барам да якаларыннан тотып, өстерәп алып кайтам. *(Тиз генә эскәтерне муеныннан тартып алып, башын сөртә-сөртә, киемнәргә таба бара.)* Мин сезгә бирим әле кирәгегезне! *(Өстенә кия башлый, кычкыра.)* Кая киез ката? Китерегез тизрәк, ә менә монда икән! Йөзе караларны. *(Ашыгып-ашыгып кия.)* Бәдбәхетләрне, муены астына килгәннәрне!.. *(Чыгып китә.)*

Пәрдә төшә.

Сораулар

1. Хәмзә байның кыяфәтен, холкын нинди итеп күз алдына китерәсез? Ул сәхнәгә ничек килеп керә һәм ничек чыгып китә?

2. Хәмзә бай көне буе кайда, нинди эш белән йөргән? Аның нигә ачуы чыккан?

3. Хәмзәнең Бибигә, Хәбибрахманга мөнәсәбәте нинди?

4. Биби ни өчен яшьләрнең театрга киткәннәрен әйтергә була? Ул башкалар уйлаганча ук аңгырамы?

5. Әсәрдә кемнәр арасында каршылык бар? Ул каршылык нәрсәләр, нинди сәбәпләр белән бәйле?

ҺӘР КӨЛҮНЕҢ МӘГЪНӘСЕ БАР

Әсәрдә Хәмзә бай гаиләсе һәм аңа бәйле кешеләр белән танышабыз. Тасвирланган вакыйга гади генә — Хәмзә байның кияве белән кызы, килене белән улы, этиләре өйдә булмаудан файдаланып, беренче мәртәбә татарча куела торган спектакльгә китеп баралар. Менә шунда барырга җыенган вакытта аларның театрга, бер-берсенә, этиләренә карата булган мөнәсәбәтләре гаять оста итеп ачыла. Алай гына да түгел, без аларның гаиләдә һәм, гомумән, тормышта нинди карашлар белән, ничек яшәүләрен дә чамалый алабыз.

«Беренче театр»ның комедия икәнлеген ничек исбатлап була? Әсәрнең төзелешенә игътибар итегез әле. Бер пәрдәдән, берничә күренештән торган бик җыйнак пьеса. Чын тормышта театрга җыенып чыгып киту өчен күпме вакыт кирәк булса, спектакль дә шул вакыт эчендә генә бара. Драматург тагын бер алым куллана — әсәрнең геройлары сәхнәдә парлашып кына күренәләр, бер-берсе белән һәм, иң әһәмиятлесе, бик куркып торган этиләре белән очрашмыйлар, әйтерсең качышлы уйныйлар. Менә шулай гади генә төзелгән әсәрдә автор көлке дә, гыйбрәтле дә булган тормыш күренешләрен тасвирлый. Барлык сөйләшүләр театрга бару-бармау мәсьәләсенә бәйләнгән. Беренче карашка гадәти генә бу хәл әсәр геройлары өчен шактый катлаулы эш булып чыга.

Вәли инде күптән киенеп, әзерләнеп куйган. Хикмәт аның өстенә киенеп куюында гына түгел, ул — яңа-

лыкка омтылып, үз ихтыяры белән, ирекле булып яшәргә теләүче актив кеше. «Каенатай кайтып керсә, гомердә театрга җибәрмәс» дип сөйләсә дә, бөтен күңеле белән яңача яшәргә теләгән Вәлинең, ничек кенә булса да, театрга бармый калмаячагына шикләнмибез. Гафифә образы да бик әһәмиятле роль уйный. Аның театрга барасы килмичә көйсезләнүе, бик озак әзерләнүе кызык. Матур күренәсе килеп бизәнү, кием сайлау, гомумән, хатын-кызларга хас сыйфат булганга, аның бу кыланышлары бүгенге көн укучысына да таныш, без шуңа күрә көлеп җибәрәбез. Инде ул, «пудрам тигез төшмәгән» дип, яңадан юынып маташкач, күлмәкләре күп булганга, кайсын сайларга белмичә аптырагач, бик урынсыз чакта әле тегүчегә, әле иренә бәйләнеп торгач, гел көлкегә әйләнеп китә. Гафифәнең кием сайлаулары да, бармыйбыз дип сатулашуы да шактый җиңел хәл ителә. Беренче күренештә Вәли белән Гафифә арасында әнә шундый каршылык булып ала, аларны сәхнәдә без шул вакыт арасында гына күрәбез.

Икенче күренештә дә шул ук каршылык. Биредә инде, киресенчә, хатын-кыз булса да кыю, үткен характерлы Факиһә үзенең ирен — Хәбибрахманны театрга барырга күндерә алмыйча интегә. Мондагы каршылыкның да сәбәбе көлке — гомере буена әтисе кушканча гына яшәп, аннан коты очып курка торган Хәбибрахманны өеннән алып чыгып китүе кыен. Театрга, таныш булмаган җиргә барырга ул аяк терәп каршы тора. Аның холкын белгән Факиһә, «әткәй орышса мине орышыр, сине орышмас» дип, җаваплылыкны үз өстенә алгач кына риза була.

Менә, ниһаять, «кайтып керсә, эш харап, ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс» дип, барысы да куркып торган Хәмзә бай үзе кайтып керә. Әмма инде театрга бару-бармау мәсьәләсе ул кайтканчы ук хәл ителгән — яшьләр театрга китеп барганнар. Ул әле бу хәлне белми. Өйдә үзен бар кешегә хуҗа итеп тота, Бибине дә, башкаларны да туктаусыз орыша, сукрана, әмма инде без аның көче кимеп барганлыгын күреп торабыз. Сәхнәгә дә ул абына-сөртенә килеп керә, мәдрәсәдә лаканга егылганлыгы турында сөйли, ләкин үзенең җиңелә баруын танырга теләми, бу хәл белән килешәсе килми. Аның һаман да әле көчле, кодрәтле булып күренергә тырышуы тамашачыда, укучыда көлү тудыра.

Әсәрнең исеме бик әһәмиятле. Чөнки театр әсәр геройлары арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләрнең үзәгендә тора. Алай гына да түгел, Хәмзә бай нәкъ менә театрны булдырмас өчен бик тырышып йөри. «Заманалар бозылды. Куйдырмагыз, рөхсәт юк» дип, кемнәргә генә бармый, шулай да театрны туктата алмый. Замана үзгәргән, аның рөхсәте яки тыюларының мәгънәсе калмаган.

Театр белән, ягъни алдынгылык, культура-мәдәният үсеше белән Хәмзә бай арасындагы каршылык — җитди мәсьәлә. Ләкин ул каршылыкны тормыш инде үзе хәл итә, иске карашлы Хәмзә бай тормыштан читтә кала. Аның тырышып йөрүләре дә кирәксез, файдасыз бер эш икәнлеге ачык күренә. Димәк, әсәрнең комедия булуы көлкеле хәлләргә, кызыклы геройларга һәм шактый җиңел хәл ителә торган каршылыкка корылган булуында икән. Әсәр турында сөйләшкәндә, без тагын бер төшенчәне — «каршылык» сүзен кулландык. Аны әдәбият белемендә конфликт дип атыйлар.

Конфликт — әсәр геройларының үз арасында яки әсәрдә тасвирланган кеше образы белән тормыш хәлләре арасында туган каршылык. Ул кешенең үз күңелендә дә булырга мөмкин, моны без эчке каршылык дибез. Мәсәлән, Хәбибрахманның «Минем үземнең дә бер күрәсем килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Нишләргә икән инде? Эти орышмас микән?» дип икеләнүендә шундый каршылыклы хис чагылып кала.

Конфликт ике яки берничә кеше арасында булырга мөмкин. Мәсәлән, һәр күренештә катнашучылар арасында, Вәли әйтмешли, «бармак башы кадәр генә булса да» каршылык булып ала: бәхәсләшәләр, бер-берсен үгетлиләр, ачуланышалар, юмалыйлар. Болары — озакка бармыйча, шактый җиңел хәл ителә торган конфликтлар.

Катнашучыларны без ике төркемгә бүлә алабыз: бер якта — моңа кадәр барысын да үзенә буйсындырып, мин генә дөрес яшим, дөньяның тоткасы мин дип, үзенә-үзе ышанган Хәмзә бай, икенче якта — аның дөньяга карашлары, үзләренә баш булып яшәве белән килешмәүче яшьләр. Алар, куркуларын җиңеп, өй эчендә бикләнеп ятудан туеп, театрга китәләр.

Әсәрдә тагын бер конфликт бар. Ул — Хәмзә бай һәм аның кебек иске карашлы кешеләрнең театр, алдынгылык, мәдәният белән сугышып-көрәшеп йөрүләрендә күренә. Бу — озак еллар буена барган җитди конфликт. Димәк, әсәрдә конфликт берничә урында, төрле характерда, каршылыкның көче дә җиңелчә яки кискен көрәш дәрәҗәсендә булырга мөмкин.

Алга таба без әсәрләрдә нинди каршылыклар бар, ул кемнәр арасында, нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килгәнлегенә игътибар итеп, конфликт турында сөйләшүне дәвам итәрбез.

«Беренче театр» куелу белән, беренче адымнарын ясап яши башлаган татар театры бүген бөтен ил күләмендә танылды. Алай гына да түгел, татар театры Финляндия, Төркия һәм Европаның күп кенә илләренә гастрольләргә йөри.

Танылуның сере — драматургларның, режиссер, актерларның талантлы булуларында һәм татар халкының театрны үз тормышыннан аерылгысыз итеп санавында, аны яратуында.

Нәкъ Тукай әйткәнчә:

Театр — яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Казанда нинди театрлар бар?
2. Режиссер һәм актерлардан кемнәрне беләсез?
3. Иң яраткан драма әсәре яки спектакль турында сөйләгез.
4. Г. Тукайның «Театр» шигырен ятлагыз.

Татар әдәбиятын гомерләрен халыкка хезмәт итүгә багышлаган талантлы язучылар, журналистлар, акыл ияләре иҗат итте һәм итәләр. Алар әһәмияте беркайчан да кимемәячәк, югалмаячак фикерләр әйттеләр, бәхетле тормыш турында хыялландылар. Бәхетне кешеләрнең ирекле, тигез хокуклы булып яшәүләрендә күрделәр, аңлы-белемле кешеләр генә киләчәк тормышны матур итеп төзи ала дип ышандылар. Үзара ярдәмләшеп, кулга-кул тотынып хезмәт иткән язучылар якын дуслар, фикердәшләр дә булдылар. Драматург Галиәсгар Камал янәшәсендә проза һәм драма әсәрләре белән танылган Фатих Әмирхан, шагыйрь Габдулла Тукай һәм романтик рухлы Сәгыйть Рәмиев булды.

Сәгыйть Рәмиев

(1880—1926)

Әдәбиятка талант ияләре төрле төбәкләрдән килә торды. Мәдәният учагы булган шәһәрләрнең берсе — Оренбург. Шуңа якын гына авылда туган Сәгыйтьнең бала чагы сәяхәттән башланып китә: этисе Лотфулла агай сал агызучы булганлыктан, җәй көннәрендә ул күп җирләрне күреп өлгерә. Кыш көннәрендә исә алар Оренбург, Урал тирәсендәге шәһәрләрдә яшиләр.

Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсе Сәгыйтьне олы юлга алып чыга. 1902 елны, алдынгы шәкертләрнең берсе булып, мәдрәсәне бүләк белән тәмамлаганнан соң, аны шунда мөгаллим итеп калдыралар. Ул фарсы телен, алгебра, геометрия фәннәрен укыта.

1905 елгы революция дулкыны күп каләм ияләрен әдәбият һәм мәдәният мәркәзе[1] булган Казанга алып килә. Шагыйрь булып танылып килүче Сәгыйть Рәмиев биредә «Таң йолдызы» газетасында эшли. Таң ату, кояш чыгу, уяну — аның иң яраткан образлары. Алар Рәмиев иҗатында гына түгел, гомумән татар поэзиясендә азатлык һәм яңарышның символына әверелделәр. 1907 елны иҗат иткән «Таң вакыты» шигырендә автор барлык татар халкына эндәшә, халкының язмышы өчен йөрәге әрнегән герой булып күз алдына килә.

Сәгыйть Рәмиевнең театр тарихына да бәйләнеше бар. Алдагы дәресләрдә сүз алып барган беренче театрны оештыруда ул да актив катнаша, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметовлар арасында була. Алай гына да түгел, спектакльне ачып җибәргәндә кереш сүзне сөйли. Спектакльдә уйнаган яшьләрне мактап, «Театр» исемле шигырен яза.

Хәзер без аның берничә шигыре белән танышырбыз.

УКУ

Сөекле сеңелләрем Гафифә
илә Вәсимәгә

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә җиткән уку,
Уку, уку, уку.

Юлымызны хак иткән уку,
Йөземезне ак иткән уку,
Үземезне баг[2] иткән уку,
Уку, уку, уку.

Раст, чын кеше эше уку,
Баг вә рәхәт җимеше уку,

---

[1] Мәркәз — үзәк, башкала.
[2] Баг — бакча.

Ачкан рәхәт ишегең уку,
Уку, уку, уку.

Гакылга нур биргән уку,
Мөкатдәс[1] уй биргән уку,
Су юкта су биргән уку,
Уку, уку, уку.

Дәүләт, бәхет биргән уку,
Мөлек[2], тәхет[3] биргән уку,
Безгә кирәк илла[4] уку,
Уку, уку, уку.

Урысча да уку — уку,
Кытайча да уку — уку,
Кемчә генә дә уку — уку,
Уку, уку, уку.

Ирләргә дә фарыз[5] уку,
Кызларга да фарыз уку,
Фарыз эшнең барысы уку,
Уку, уку, уку.

Сораулар һәм биремнәр

1. Уку нәрсәләр белән чагыштырыла, шуларны әйтеп, аңлатып чыгыгыз.

2. «Илтеп күккә җиткән», «Су юкта су биргән» дигән юллар нинди мәгънәдә кулланылган?

3. «Уку» сүзен шагыйрь нинди мәгънәләрдә куллана, китап уку мәгънәсендә генәме?

4. Сәгыйть Рәмиев сеңелләренә биргән киңәшне сез бүген кемнәргә әйтер идегез?

---

[1] Мөкатдәс — изге, кадерле.
[2] Мөлек — байлык.
[3] Тәхет — *бу урында:* дәрәҗә мәгънәсендә.
[4] Илла — тик, фәкать.
[5] Фарыз — кирәкле эш, бурыч.

АВЫЛ

(Кыскартып алынды)

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш[1]:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш.

Нинди иркен, нинди рәхәт,
Нинди бар җир гөл генә;
Синдә төн дә юк, төнең дә
Бер болытлы көн генә.

Ул кара бер күгеңә бу
Фирүзә[2] бит, бик зуры,
Күр аеңны, кайда бар бу?
Бер гаҗәеп бит нуры!

Һәм гаҗиб[3] бер яктылыкта
Җир көмеш төсле тора:
Анда — урман һәм дә таулар,
Монда кырлар яктыра.

Синдә бар да чын матур һәм
Чын матур синдә генә,
Тагы да артыр бер матурлык
Китдисәм мин дә менә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдәге чагыштыруларны табыгыз. Нәрсәләр каршы куела, ни өчен дип уйлыйсыз?

2. Шагыйрь кемнең авылы турында язды икән? Аны ничек сиземләп була?

3. Авыл табигатен сурәтләгән детальләрне табыгыз. Җир ничек көмеш төсенә керә ала? Шәһәрдә ни өчен бу күренешләр юк?

---

[1] Хуш — күңелгә ягымлы.

[2] Фирүзә — яшькелт төстәге кыйммәтле таш.

[3] Гаҗиб — гаҗәеп.

4. Сезнең дә авылыгыз шулай матурмы? Аның табигатен тасвирлап карагыз, рәсемен ясагыз.

5. Шигырьнең соңгы юлларындагы шаян интонацияне аңлатыгыз. Мәгънәсен баштагы дүрт юлдан эзләгез.

6. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез, ятлагыз.

Сәгыйть Рәмиев — гомерен әдәбиятны, мәдәниятне үстерүгә багышлаган кеше. Шуңа күрә ул шигырьләрендә дә сүзне уку, аң-белемле булудан башлый. Укучысын (шул исәптән үзенең сеңелләрен дә) ышандыру, укуга дәртләрен кузгату өчен, бик матур сүзләр эзләп таба, күз алдына килерлек итеп сурәтли. Укыган кешене күккә менеп җиткән кеше белән тиңли. Ул чор укучысы өчен бу бер хыялый чагыштыру гына булса, без инде, космонавт булу өчен никадәр белем һәм тырышлык кирәк булуын белгәнгә, әлеге образны зуррак, тирән мәгънәлерәк итеп кабул итәбез. «Юлыбыз хак, йөзебез ак» дигән юлларны да киң мәгънәсендә аңлыйбыз — дөреслек, хакыйкать бары күп уку һәм уйланулар нәтиҗәсендә, китапларда сакланып калган белемнәрне үзләштергәндә генә табыла; йөз аклыгы — тормышта ялгышмыйча, адашмыйча, кешеләргә файда китереп яшәү. Шул чагында тыныч күңел, саф намус белән яшәрсең дип нәтиҗә ясыйбыз.

«Уку» сүзе һәр куплетның, һәр юлның ахырында кабатланып, шигырьне «чигеп» барган бизәк ролен үти. Кабатлаган саен аңа яңа мәгънә өстәлә, әһәмияте көчәйтелә. Шигырьдә әйтелгән фикерләр беркайчан да искермәячәк.

Авыл тормышы татар әдәбиятында бик яратып тасвирлана. Язучыларның күбесе өчен авыл — туган җир, туган ил. Халыкның да күпчелек өлеше авылда яши. Авыл кешеләре бер-берсе белән якынрак аралаша, бер-берсен яхшырак белә.

Сәгыйть Рәмиев тә — кечкенәдән авыл табигатенә гашыйк кеше. Шуңа күрә авылны яратуы турында ул нәкъ халык җырларындагыча арттырылган, көчәйтелгән образлар кулланып яза: «Бер авыл мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш». Без шагыйрь белән бәхәсләшмибез, киресенчә, аңа кушылып уйлый башлыйбыз, күз алдына үз туган авылыбыз яки без булган, белгән авыл килә. Нәрсә сихерләгән соң Сәгыйть Рәмиевнең күңелен? Тын, тыныч, иркен, киң... Ни генә дисәк тә,

бу сыйфатларны шәһәрдә табуы кыен бит. Өстәвенә, күкнең фирүзә ташыдай зәңгәрлеген бары авылда гына күреп була. Шәһәрдә күкне биек йортлар каплый, электр лампочкалары «төсен ала». Урман, кырлар, таулар авылның һәр урыныннан күренеп, аның бер өлеше булып тора, шуңа күрә табигатьнең матурлыгы авылда күбрәк, ачыграк күренә.

Шагыйрь бераз шаяртып та ала: авылга эндәшеп, менә мин шәһәр кешесе булдым инде, синең өчен читтән килгән кеше, матурлыгыңны да киметеп торамындыр әле, мин киткәч, синдә тагын да тын, тыныч булып калыр — матурлыгың артыр, ди. Чынлыкта исә авылны шагыйрь күңел күзе белән күреп, искиткеч сокланып яза, тере җан иясе белән сөйләшкәндәй, авылны олылап, яратып сөйли.

Казанга килеп, әдәбият һәм сәнгать дөньясында ялкынланып иҗат иткәндә, С. Рәмиев авылын әнә шулай сагына. Ул аны матурлыкның өлгесе дип саный, табигать гүзәллеге белән тиң куя, һәрвакыт бу образны — күренешне күңелендә йөртә.

Шулай да аны шигърият күбрәк мавыктыра, һәм, авылыннан гафу үтенгәндәй, ул тагын шигырь яза:

Булмас артык олуг бер эш
Илгә хезмәт итүдән;
Илгә хезмәт хөрмәтенә
Үскән җирдән китүдән.

Хыял-кичерешләргә бай күңелле, романтик рухлы шагыйрь Оренбург, Урал, Әстерхан төбәкләре аша үтә һәм татар халкының сөекле шагыйре булып тарихта кала.

Революциягә кадәрге татар поэзиясендә иң якты йолдыз, әлбәттә, Габдулла Тукай булды. Бу чорда иҗат иткән кайсы язучы турында сүз барса да, фикер йомгагы гел Тукайга барып ялгана. Ул бик аз яши, ләкин шул кыска гына гомере эчендә дә хискә һәм фикергә гаҗәеп бай иҗат калдыра. Бу сер күпләрнең игътибарын тартып, аларны сихерләп тора. Бүген әдәбиятта Тукай образын тасвирлаган әсәрләр үзләре бер китапханә булырлар иде. Гомере буе Тукайга табынган, аның иҗатын, тормыш юлын бөртекләп өйрәнгән һәм Тукай турында беренче зур әсәр язган әдип —

Әхмәт Фәйзи
(1903—1958)

Татар язучыларының тормыш юлын өйрәнгәндә, кызыклы бер үзенчәлек ачыла: алар, әйтерсең хәзерлексез генә Казан шәһәренә килеп керү ярамас дип, байтак вакыт Казанны читтән урап йөриләр. Әхмәт Фәйзинең дә тормыш сукмаклары шулай бормалы була.

Ул Уфа шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туа. 1921 елда Оренбургка килә, Көнчыгыш институтына укырга керә. Ачлык елында Төркестан якларына китәргә мәҗбүр була, аннан Донбасска юл тота. Барган җирләрендә татар яшьләрен укыта, аң-белем тарата, күрәсең, үзе дә күп белем җыя. 20 нче еллар ахырында Казанга килеп урнашкан Әхмәт Фәйзи турында шагыйрь Сибгат Хәким болай дип искә ала: «Ул әдәбиятка әзерлек белән килде. Безне ул үзенең көчле эрудициясе[1] белән,

[1] Эрудицияле — тирән белемле, төрле өлкәдә мәгълүматлы.

татар әдәбияты гына түгел, Көнчыгыш, рус, дөнья әдәбиятлары турында да иркенләп, тирәннән фикер йөртүе белән сокландыра иде».

Әхмәт Фәйзи — күпьяклы талантка ия булган әдип: шагыйрь, прозаик, драматург, тәнкыйтьче, тәрҗемәче һәм танылган опера, балет либреттоларының[1] авторы да. Мәсәлән, композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын», «Җәлил» операларына, Фәрит Яруллинның «Шүрәле», Рәшит Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетларына либреттолар яза. Игътибар итегез: Тукай поэмаларын башка сәнгать төренә күчерүче дә — Әхмәт Фәйзи. Аның Тукай исеме белән бәйле тагын бер әсәре — «Тукай» драмасы бар.

Шулай да Әхмәт Фәйзи иҗатының югары ноктасы, аның төп китабы — «Тукай» романы. Әсәрнең язылу тарихы турында әдип үзе болай дип яза: «Тукай турында роман язу, кызыктыргыч эш булу белән бергә, гаять катлаулы һәм җаваплы эш иде. Аны турыдан-туры язарга утырганга кадәр миңа озак еллар шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын, аның яшәгән чорын, мохитен[2] өйрәнергә һәм тикшерергә туры килде» (*Ә. Фәйзи*. Әдипнең эрудициясе.— Казан, 1973.— 197 б.). Ул архивларда утыра. Тукайны белгән кешеләрне эзләп таба, Тукай яшәгән урыннарда була. Шул рәвешчә, аңа талантлы язучы гына түгел, тарихчы галим дә булырга туры килә. Ә. Фәйзигә «Тукай» романы өчен 1958 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

ТУКАЙ

(Романнан өзекләр)

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем.

Габдулла Тукай

Габдулланы Сапый абзый иң элек үз өенә алып кайтты. Бу — Җаекның читендәрәк бер тыкрыкта читән коймалы йортта эче-тышы белән җыйнак кына бер катлы агач өй иде.

[1] Либретто — опера, балетның эчтәлеген аңлатып язган әдәби текст.

[2] Мохит — әйләнә-тирә, чолганыш.

Хуҗаларның кайтып төшүе өйдә бинихая ыгы-зыгы кузгатты. Әллә нинди карчыклар, яшь кенә кызлар һәм зур киез итек кигән бер аксак малай, чыр-чу килеп, аларны каршы алдылар.

Зарыктыргыч озын һәм авыр юлның, ниһаять, очына чыгуына ышанмаган сыман аптырабрак торган Габдулланың билбауларын чиштеләр, бишмәтен һәм бүреген салдырдылар. Ул берьюлы җиңеләеп калды. Авыр киемнәр эчендә хәрәкәтсезлектән оеп каткан кулларын бер алга, бер артка чайкап, Габдулла идән буйлап йөреп китте. Сапый абзый, киез итекләрен салганнан соң, читекләрен киеп алды һәм аларның куныч сырларын тигезләп сыпыра-сыпыра сөйләнде:

— Аллага шөкер, исән-сау кайтып җиттек әле, юл газабы — гүр газабы, дип белми әйтмәгәннәр шул. Мондый юлдан соң үзеңнең начар гына өең дә гүрнәчә[1] кебек!..

Ишек төбендә кемнәрдер чыш-пыш сөйләшеп алдылар, аннан соң Хәят апа, ниндидер үпкәләгән өзек-өзек тавыш белән:

— Әйдә, Газизә җаным, түрдән уз! — диде. Газизә дип дәшелгәне басынкы гына кызлар тавышы белән сөйли башлады:

— Рәхмәт, узып тормыйм, кайтканнарын күреп, кереп әйттеләр. Ашыга-ашыга килеп җиттем. Минем энекәш...

Габдулла Газизәнең үз апасы икәнлеген төшенде һәм тиз генә ал якка йөгереп чыкты. Башыннан ук чапан бөркәнгән һәм буйга җиткән кыз зур кара күзләре белән Габдуллага карап елмайды һәм чапан астыннан ике кулын чыгарып аңа сузды.

— Апаң бу синең, Габдулла, күреш! — диде Хәят апа. Апа белән эне бер-берсен танымый гына күрештеләр, аталары үлеп, Сак белән Сок шикелле, Кушлавычтан икесе ике якка аерылып киткәндә, Газизәгә җиде-сигез

---

[1] Гүрнәчә — (*русча:* горница) кунак өе, ак өй.

яшь, ә Габдулла дүрт-биш айлык имчәк баласы гына иде бит! Шуннан соң ун ел узып киткән! Язмыш аларны икесен ике якка хәбәрсез-нисез йөртте-йөртте дә, менә хәзер генә алар Җаекта олау йөртүче вак сәүдәгәр Сафиулла абзыйның бусагасында очраштылар!

Габдулла киенеп алып, апасы белән урамга чыкканда, караңгы төшеп җиткән, шуның өстенә, җиңелчә генә буранлап ябалак кар ява иде.

Госмановлар йортына чаттан борылып урам аша гына чыгасы икән, эне белән апа озак бармадылар, асты таш, өсте агач, аслы-өсле җидешәр тәрәзәсе белән урамга караган йортның таш капкасыннан кереп, сары буяулы баскычтан өйнең өске катына менеп киттеләр.

Апасы белән Габдулла биек түшәмле һәм берничә бүлмәле зур гына өйгә килеп керделәр. Көн җылы булуга карамастан, өй эссе ягылган һәм пешеп чыккан итле токмач исе аңкып тора иде. Габдулла нәкъ аш вакытына тап булган икән, бүлмәләрдә кашык-аяк шалтыраган тавышлар ишетелеп тора, хатын-кыз, савыт-саба күтәреп, ыгы-зыгы килеп йөри.

Ул ара булмады, чаршаулы ишектән урта буйлы, тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле, бала итәкле күлмәк өстеннән күгелҗем төстә хәтфә камзул кигән ягымлы гына хатын чыкты.

— Күреш дәү апаң белән,— дип, Газизә Габдулланың җиңеннән тартты, Габдулла дәү апасына ике кулын сузды.

— Зур шәкерт икән, гомерле генә була күрсен, бәрәкәтле аяклары белән килсен,— дип каршы алды дәү апа һәм Газизәгә Габдулланы чишендерергә булышты. Бераздан дәү апа Габдулланы урта ишек янына алып килде һәм, чаршауны ачып, эчтәгеләргә күренми генә дәште:

— Син, монда кара әле, менә шәкертебез килеп төште...

Һәм ул Габдулланы, аркасыннан җиңел генә этәреп, бүлмәгә кертеп җибәрде. Арттан чаршау ябылды, һәм

Габдулла стеналарына чиккән намазлыклар, сөлгеләр, пыялаланган шәмаилләр[1] эленгән, зур асылмалы лампа белән яктыртылган көзгеле бүлмәдә әллә нинди өч ят кеше алдында басып калды. Алар, өстәл тирәсендә утырган килеш, ашауларыннан туктап, Габдуллага карадылар. Габдулла бераз каушап китте.

Беренче булып зур гына борынлы, җирән мыеклы кеше дәште:

— Ә-ә-ә! Каениш бу минем, каениш! Казан кунагы! Йә, кил, күрешик!

Алар ике кулларын сузып күрештеләр. Җизнәсенең елмаеп торган ягымлы йөзен күргәч, Габдулланың каушавы бетте.

Икенче көнне Габдулла уятканны да көтми, мәктәпкә бару дәрте белән, үзе үк сикереп торып утырды. Аның уянганын күреп, Газизә апасы:

— Габдулла җаным, идәнгә басмый тор, мин хәзер киез итегеңне алып киләм,— диде һәм киптерер өчен кичтән үк мич башына ыргытылган киез итекләрне алып килергә йөгерде. Ләкин кире әйләнеп килгән чакта аңа җизнәсе очрады һәм аның кулыннан киез итекне алып, табанын әйләндереп карады.

— Үкчәсе тузып килә,— диде ул,— тишелеп чыкканчы, төп салдырып алырга кирәк. Кертеп бирегез теге кемгә, төп салып бирсен.

Шулай итеп, мәктәпкә бару бүген булмый калды. Ләкин бу мәҗбүри рәвештә өйдә утыру бер көн белән генә бетмәде. Галиәсгарның «теге кем» дип әйткән кешесе киез итекне ике көн тотты.

Шул арада Габдулла өйнең өске каты һәм аскы каты белән танышып өлгерде. Өйнең аскы катында торучы ирле-хатынлы хезмәтчеләр — Гыймади һәм

---

[1]Ш ә м а и л — язып, стенага эленеп куелган дини догалар.

Гайниямал белән ул аеруча кызыксынды. Гайниямалның, себерке йә идән чүпрәге тоткан килеш, бүлмәдән бүлмәгә җил кебек өерелеп йөрүен Габдулла бу йортка төшкән көннән алып күрә килде. Күлмәк итәкләрен кыстырган ябык гәүдәле, ирләр кебек җитез, яшь кенә хатын иде ул үзе. Габдулла аңа тиз ияләшеп китте. Беренче көн аштан соң ук, өстәлдәге савыт-сабаны җыешып йөргән арада, Гайниямал аңа кечкенә, әмма үткер күзләре белән карап елмайды да кыю гына:

— Казан шәкертенә безнең Җаек авыл булып кына күренәдер инде. Казанны бик зур кала дип сөйлиләр бит,— дип куйды. Ә икенче көн иртә белән:

— Габдулла акыллым, менә бу җирне сөртеп алганчы гына аякларыңны сандыкка күтәреп утырчы, йә булмаса аска, абыең янына төш, ул да — синең кебек мәдрәсәдә укыган шәкерт,— диде. Габдулла башта «абыең» дигән сүзне төшенмәде. Ул арада кемдер берәү, тышкы ишектән башын тыгып:

— Гайниямал, бала уянды, төшеп кенә мен әле,— дип дәште.

— И Алла, Ходаем, яңа гына имезгән идем ләбаса,— дип, Гайниямал шулай ук ирләр кебек йомылып чыгып китте. Аның инде бала анасы булып, «абыең» дигәне әлеге ишекне ачып дәшкән ире икәнне Габдулла шунда гына төшенде. Кичкә таба ул Газизә апасы белән бергә алар янына төште. Бу — ике тәрәзәсе белән ишегалдына, бер тәрәзәсе белән урамга караган уртача зурлыктагы бер бүлмә булып, түрдәге сәкесе белән бераз Кырлайдагы сабак абыстаеның кызлар укыта торган бүлмәсен хәтерләтә иде. Гайниямалның ире Гыймадетдин, Габдулла кергәндә, бүлмә уртасында бүкән сыман тәбәнәк кенә әйбер өстендә бик бирелеп балта сабы юнып утыра иде.

— Вәгаләйкүмәч сала-а-ам! — дип шаяртып кайтарды ул Габдулланың сәламен. Кулындагы балта сабын мылтык төзәгән сыман күзләренә күтәреп, аның өсте тигез юнылганмы, юкмы икәнен карый-карый, сорашып китте:

— Йә, нихәл, шәкерт! Исән-сау гына килеп җиттеңме? Казан бит ул анавы Җембете белән Тургай түгел, өч атналык юл диләр бит аны.

Аннан соң ул, эшеннән күзен алмыйча гына, Габдулланың кайда, нәрсә укыганнарын сорашырга тотынды. Габдулла сөйләп бирде. Аны бәләкәйсетеп каршы алган Гыймади хәзер инде эшен бер якка куеп, Габдулланы үзенең тиңдәше сыман итеп сөйләшеп алып китте:

— Карале син!.. Синең яшеңдә без ул китапларны белми идек әле. Син бик югары киткәнсең, алайса. Болай булгач, хәзрәт сине мокыт нугай балалары белән утыртмый инде, үзенә утырта инде дәрескә...

Ул арада Гайниямал сәкегә үз пары белән шыбыр тиргә баткан калай самовар китереп утыртты һәм Газизә белән Габдулланы табынга дәште.

— Юк, юк, рәхмәт, утырып тормыйбыз,— дип сикереп торды Газизә.— Әйдә, Габдулла, безне көтә торганнардыр.

— Алай ярамый инде. Безне сансынмау була ич ул,— диде Гайниямал.

— Әйе ләбаса. Кеше кешедән өстен, әмма берәү дә аштан өстен түгел,— дип, фәлсәфәгә керешеп китте Гыймади, Габдуллага карап.— Тукта, торып тор, менә мин сиңа бер китап күрсәтим әле...

Ул, шүрлеккә үрелеп, битләре саргаеп, керләнеп беткән тышсыз бер китапны алды да Габдуллага бирде.

— Бу китап берәүдә дә юк, Гурьевтан килеп монда укып яткан мәрхүм Зәйнетдин шәкерттән мирас урынына калган китап бу. Менә син аны укып кара әле.

Габдулла китапны кулына алды һәм, һәрвакыттагыча, кулына төшкән яңа китапка ничек ташланса, моны да аеруча зәвык белән йотылып карый һәм укый башлады. Соң бу аның, элек-электән ишетеп, моңарчы ничек кулга төшерергә белми йөргән китабы «Әбүгалисина» бит! Агалы-энеле ике егетнең бер ел буена тау тишегенә бикләнеп гыйлем алулары һәм аннан дөньяны таң

калдырган «нежүм» гыйлемен[1] өйрәнеп, зур галимнәр булып чыгулары турында гаҗәп кызык хикәя бит бу!

Китапның Габдуллага берьюлы ошавын күреп, Гыймади ярым шаяру, ярым мактану рәвешендә:

— Күрдеңме, бездә нәрсәләр бар?!— дип куйды.

— Кычкырып укычы, Габдулла! — дип үтенде Гайниямал. Габдулла укып китте.

Бер битен укып икенче биткә күчкәч, Габдулла өзелеп калган җөмләне ялгый алмый тынып калды. Аннан соң икенче битнең юклыгы билгеле булды.

— Ә ул бите аның элек-электән юк иде... Анда ниндидер бер тылсымлы сүз булган, шуңа күрә аны берәү ертып алган,— дип аңлатты моны Гыймади һәм дәвам итте: — Бу китапның хикмәте дә шунда бит. Моны һәркем үзенчә аңларга тиеш. Менә миңа бер хәлфә кеше укып күрсәтте моны. Китапта бер төрле язылган, ә ул аны икенче төрле аңлатып бирә: «Бу китапның һәрбер сүзендә хикмәт ята. Аны укый белергә генә кирәк»,— ди. Патшалар турында серле итеп язылган урыннары бар моның. Теләсәң тегеләй аңла, теләсәң болай.

— Әй, бүлдермәле, укысын кеше,— дип туктатты аны Гайниямал.— Ничек язылган, шулай аңлый инде кеше. Тотасың да үзеңчә бер мөгез чыгарырга тотынасың. Йә, йә, укы Габдулла!

Габдулла тагын укып алып китте, һәм бу китапта язылган мәсьәлә Гыймадиның күңелен аеруча кытыклаган мәсьәлә булып чыкты. Ул тагын Габдулланы бүлми түзә алмады:

— Күрдеңме, гыйльме кимия[2] нишләтә? Вәт, менә шулай гыйльме кимияне өйрәнеп алып, кеше күзенә күренми йөрсәң икән!

— Әбәү, сине берәү дә күрмәгәч, бик күңелсездер ул!— дип, келтерәтеп көлеп җибәрде Гайниямал.

---

[1] «Нежүм» гыйлеме — күк җисемнәре, йолдызлар турындагы белем.

[2] Гыйльме кимия — химия фәне.

И. М. Воробьев рәсеме.

Гыймадига бу гыйльме кимияне кимсету булып тоелды, кеше күрмәгәч, кызык буламыни?

— Әй, дөньяның чибәре каян килгән? — дип ачы телләнде Гайниямал.— Син үзеңнең әнә шул тукмак кебек борыныңны кешедән яшерер өчен күренми йөрисең киләдер әле.

Габдулла укудан тукталды. Гыйльме кимиянең нәтиҗәсе әлеге Гыймади белән Гайниямалның бер-берсенә менә шундый сүзләр белән чеметешүдән ары китә алмады. Габдулла бу әче телле әңгәмәнең шактый катлаулы булып бетәсен көткән иде. Юкка гына хәвефләнгән икән. Шушы кичне үк ул Гыймади белән Гайниямалның яратышып сөйләшү рәвешләре шулай икәнен төшенде.

...Габдулла, апасы белән үзләренә менгәч, сорашып, Гыймадиның кайчандыр мәдрәсәдә укый башлаган ярлы шәкерт булуын, ачтан үлмәс өчен, өлкән шәкертләргә самовар куеп, байларга көнлекче булып көн күрүен, ахырда уку белән эшне берьюлы алып бара алмый, менә шулай бай ялчысы булып калуын, аннан соң шушында асрау булып торучы Гайниямалга бикә димләве белән өйләнүен белеп алды.

Сораулар һәм биремнәр

1. V сыйныфта өйрәнгән «Исемдә калганнар» исемле әсәрнең эчтәлеген исегезгә төшерегез. Әсәр ничек тәмамланган иде?

2. Җаекта нәни Габдулланы кемнәр каршы ала?

3. Туганлык хисләре сурәтләнгән урыннарны бүлектән билгеләгез.

4. «Габдулла җаным, идәнгә басмый тор, мин хәзер итегеңне алып киләм» һәм «Исемдә калганнар» әсәрендәге «Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән» дигән юллар арасында нинди бәйләнеш бар, нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

5. Ни өчен Габдулла Гайниямал белән Гыймадига хөрмәт белән карый?

6. Гыймадиның: «Кеше кешедән өстен, әмма бирәү дә аштан өстен түгел»,— дигән сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?

7. Әсәрдә нинди тормыш сурәтләнә?

Җаекның атаклы мәдрәсәсенә барыр көн килеп җитте. Әлеге кода абыйның улы Талип, озын муенлы, күтәрелеп тора торган җәлпәк борынлы, уйнак күзле малай, букчасын иңенә кыеклап аскан хәлдә килеп керде. Алдан сөйләшү буенча, ул Габдулланы мәдрәсәгә ияртеп алып барырга тиеш иде. Мәдрәсәдә Габдулланы кай сыйныфка[1] утырту, кайсы хәлфәгә тапшыру мәсьәләсе дә хәл итеп куелган иде инде.

Габдулла, Талипка ияреп, мәдрәсәгә китте. Өйдәгеләр аны һәрберсе үзенчә:

— Тырышып укы, улым, бар!

— Изге сәгатьтә!

— Аллага тапшырдык! — дип озатып калдылар.

Кырлайдан киткән көннән алып бу мәдрәсә Габдулланың күз алдында әллә нинди серле шәүлә булып балкып торды. Соңга таба ул аның төшләренә керә башлады. Аныңча, бу мәдрәсә, әлбәттә, Кырлайныкы сыман тау битендә инешкә таба авышып утыра торган бер катлы агач өй түгел, бәлки Казанның Күл буе мәдрәсәсе кебек ташпулат. Моның хәлфәсе дә Кырлайның Хәбри хәлфә төсле бишбилле иске бишмәт кигән, бөкрәеп йөри торган, мужикка охшаган, ябык чырайлы хәлфә түгел, бәлки озын мәһабәт буйлы, тула ак йөзле, сөрмә тарткан җитди күзле, ак бикасап чапан[2], яшел чалма кигән кеше. Тамак кыру да монда Хәбри хәлфәнеке төсле

[1] Кай сыйныф — ничәнче сыйныфка.

[2] Бикасап чапан — бәрхеткә ука белән чигелгән яхшы, затлы чапан.

кәҗә йөткергәндәй кәһ! кәһ! итеп түгел, Ташъяк ярминкәсендәге кәмит алдында зур җиз быргы кычкырткандай күкрәп чыга, мөгаен...

Һәрхәлдә, Габдуллага бу мәдрәсә юлы зур бер батырлык юлы булып, бу көн бәйрәм көне кебек тантаналы булып тоелды. Бу гади йөреш түгел, балалыктан — олылыкка, бүгеннән киләчәккә батыр бер омтылыш, кыю бер сикереш ясау иде.

Юл өстендә бер төркем бала-чаганың пыр тузып, якага-яка килеп сугышулары Габдулланың уйларын тузгытып җибәрде. Бу сугыш читтән карап торыр өчен никадәр генә кызык булса да, мәктәпкә соңга калудан куркып, Габдулла юлын дәвам иттерергә теләде. Әмма аның юлдашы Талип:

— Кая барасың, мәдрәсә шушы бит инде, — дип, аны шып туктатты һәм ике катлы йортка төртеп күрсәтте. Бу — мәчеттән йөз таяк чамасы ераклыкта, Чаган елгасына караган ярның өстенә салынган, нәкъ Габдулла килеп төшкән Галиәсгар бай йорты сыман асты таш, өсте агач һәм зурлыгы белән дә, аңардан кайтыш булмаса, бер генә дә артык түгел, искерәк бер йорт иде. Аның яртылаш җимерек агач капкасы аша йортның эче ялтырап күренеп ята, түрдә кечкенә бер катлы йорт һәм сул якта мунчамы — нәрсәнеңдер почмагы чыгып тора, алар артында яр астында туңган Чаган өсте җәелеп ята иде.

Талип Габдулланы мәдрәсә йортының эченә алып керде. Габдулла, йозак белән бикләнгән ишектән тыш, икенче баштарак тагын бер ишек күрде. Анысы ачык иде.

— Әнә теге ишектән керәп булмыймыни? — дип сорады ул Талиптан.

— Юк, анысы — ятып укый торган өлкән шәкертләрнең ашханәсе. Аннан үтеп була булуын, тик олы шәкертләр безне анда җибәрмиләр.

Һәм, шул сүзне дөресләгән сыман, ишектән нәкъ Габдулланыкы төсле камалы бүрек очып чыкты да ерак

түгел генә бәдрәф янындагы бозлавык өстенә барып төште. Аның артыннан кызарынып-бүртенеп, әрләшә-әрләшә, букча таккан бүрексез малай чыгып йөгерде.

Балалар артыннан Габдулла да, Талипка ияреп, сыйныфка килеп керде. Сыйныф кечерәк кенә өч тәрәзәле, тәбәнәк түшәмле бик гади бүлмә иде. Бернәрсә генә Габдулланың игътибарын үзенә тартты: балалар, Кырлай мәдрәсәсендәге кебек, сәкегә яисә коры идәнгә түгел, бәлки тәбәнәк кенә тар һәм озын өстәлләр арасына кереп, дүртәр-дүртәр булып тезелеп утыралар. Габдулланың билгеле урыны булмаганга күрә, ул Талип янына сыенып, бишенче булып утырды. Аны шунда ук кысрыклап төрткәли башладылар:

— Бар, бар, үз көрсиеңә[1] барып утыр! Кеше көрсиенә килеп тыгылма!

Габдулла шунда ук ике төрле сабак алды: бердән, бу тәбәнәк озын өстәл «көрси» дип атала, икенчедән, монда бишенче булып утырырга ярамый икән!

Төрткәләү дәвам итте. Талипның:

— Юк, ул яңа шәкерт, ул шушы сыйныфныкы. Галиәсгар байның каенише,— дип, торып аңлатуы да ярдәм итмәде. Габдулланы, бәлки, ай-ваена карамый төртеп чыгарган да булырлар иде, әмма шулвакыт әлеге фәррашның[2] кереп, шау-шуны басар өчен кулындагы пеше чыбыгы белән шәкертләр өстеннән уңлы-суңлы чажлатып селтәнеп алуы, берничә шәкертнең: «Әл-лә-лә-лә!» — дип, чын күңелдән әрнеп куюлары белән, Габдулла мәсьәләсе онытылды.

Кырлай һәм Кушлавыч мәдрәсәләрен күргән Габдулланы бу мәдрәсәнең тәртибе һәм балаларның үзенә мөнәсәбәте гаҗәпләндермәде. Аны теге мәдрәсәләр белән бу мәдрәсә арасында әллә ни аерма юклыгы гаҗәпләндерде. Ләкин ул аерманың бер дә булмавына ышанмады

---

[1] Көрси — кресло, урындык (мәдрәсәләрдә эскәмия яки киез җәелгән урын булырга да мөмкин).

[2] Фәррәш — мәчет-мәдрәсәне карап торучы, җыештыручы.

һәм әле сыйныфка килеп керәчәк хәлфә аның бу турыдагы бөтен шикләрен җуеп ташларга тиеш иде. Ул өйдән үк үзенең Шәпеш хәлфәдә укыячагын белеп килгән иде, шуңа күрә ул Талипның колагына ятып шыпырт кына сорады:

— Шәпеш хәлфә кем ул, зур хәлфәме?

Җавап бирү урынына Талип Габдуллага әйләнеп, аңа ни өчендер гаҗәпләнеп карады.

«Шәпеш хәлфәне дә белмисеңме?» дигән караш иде бу.

Габдулла кызарынды. Ул: «Кояш нәрсә, ул кайсы яктан чыга?» дигән кирәксез һәм көлке сорау биргән сыман тойды үзен. Димәк, Шәпеш хәлфә — ул монда Җаекта бик зур кеше һәм аны белмәү гаеп! Габдулланың күз алдына тагын хыялындагы әлеге бикасап чапанлы, яшел чалмалы, мәһабәт буйлы, сөрмә тарткан күзле, җиз быргыдан күкрәп чыккан тавыш белән тамак кыра торган зур галим килеп басты.

— Шәпеш хәлфә керәп килә! — дип ысылдады кемдер. Сыйныф кинәт тып-тын булды. Ишектән, зур кулларын кая куярга белми селтәнгәләп һәм аунаклап, Талипның атасы, әлеге кода абзый килеп керде. Габдулла: «Бәй, бу нишләп килеп керде әле монда? Әллә тагын Вәрәкыя апаны эзләп йөриме?» — дип уйлап та бетермәде, шәкертләр дәр килеп аякка бастылар. Габдулла, аптырап, авызын ачып калды:

— Менә кем икән ул Шәпеш хәлфә!

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдә Талипның кыяфәте ничек бирелә?

2. Габдулланың хыялындагы мәдрәсә турында сөйләгез.

3. Габдулланың хыялларын чынбарлык белән чагыштырыгыз, ул ни өчен мәдрәсә турында шулай хыялланган була?

4. Шәпеш хәлфә белән очрашкач, аның күңелен нинди хисләр били? Ул нинди хәлфәләрдән белем алырга тели?

5. Чагыштыруларны, эндәш сүзләрне табыгыз, сөйләмдә кулланып (мисаллар китереп) күрсәтегез.

6. «Һәрхәлдә, Габдуллага бу мәдрәсә юлы зур бер батырлык юлы булып, бу көн бәйрәм көне кебек тантаналы булып тоелды» дигән юллардан сез ни аңлыйсыз, сөйләп бирегез.

— Әнә шәкертебез дә кайтты. Йә, ошадымы безнең мәдрәсә?

— Ошамыйча ни, монда мең чакрымнан килеп укучылар бар. Симидән, Сарытаудан, Гурьевтан... Казанның үзеннән килеп укучылар да бар монда.

— Сиңа нәрсә булды? Ник турсайдың? Малайлар кыйнап кайтардыларммы әллә? Әллә хәлфә колагыңны бордымы?

Шундый сүзләр белән каршы алдылар өйдә Габдулланы.

Ул үзенең кичерешен берничек тә аңлата алмады һәм моңа үзе дә гаҗәпләнде: ничек аңлатасың? Аны малайлар кыйнамады. Ләкин ул кайтып куанып сөйләрлек әйбер дә тапмады. Юк, Кырлай һәм Кушлавыч мәктәпләреннән артык җире юк иде бу мәдрәсәнең. Хәтта, киресенчә: авыл мәктәпләренә ул ияләшкән, шәкертләре һәм хәлфәләре белән үзләшеп беткән иде. Монда бар да ят, салкын, тупас, Шәпеш хәлфә үзе генә ни тора!

Икәү генә калгач, Газизә апасы, энесенең хәлен төшенеп булса кирәк:

— Күнегерсең әле, күгәрченем, ияләшмәгәннеке ул,— дип, аның башыннан сыйпап куйды.

Дөрес, кеше вакыты белән бар нәрсәгә дә күнегә. Ләкин Габдулла өчен бу мәктәпкә ияләшү авыр булды. Шәпеш хәлфәгә ул бөтенләй ияләшә алмады. Эш Шәпеш хәлфәнең усаллыгында, аның балаларны суккан чагында өзеп ала торган, очына шакмак таккан камчысында түгел иде. Әгәр бөтен дөнья хөкеме алдында Шәпеш хәлфә чыгып: «Мин балаларга башка хәлфәләрдән артыграк кул якканым юк»,— дип ант итсә, ул хаклы булыр иде. Шундый заман иде бу, кыйнамый укыту укытуга саналмый, аталар балаларын мәктәпкә:

«Хәлфә, мә, ите сиңа, сөяге миңа!» — дип китереп тапшыралар иде.

Шәпеш хәлфә, шәкертне кыйнаудан битәр, кыйнамый гына үзәгенә үтә белә, һәм ул моның тиңе юк остасы иде...

Ләкин Габдулла өчен иң авыры бу түгел иде әле. Мәсьәлә шунда ки, үзенең мәдрәсәдә яшәве өчен кемгә, нинди байга һәм нинди көчле куллы кешегә бурычлы булса, Шәпеш моның рәхмәтен тегеләрнең балаларына мөнәсәбәте белән кайтара килде. Андый балаларның ул сабак белмәүләрен дә, шуклыкларын да сизмәмешкә салынды, аларга төшәргә тиеш җәза һәм шелтәне дә икенчеләргә күчерде. Галиәсгар бай Шәпешкә, бердән, кардәш, икенчедән, аның мәдрәсәдә яшәвенә иң нык таяныч булып килде. Ә Габдулла — Галиәсгар байның кардәше. Бу — мәсьәләне хәл итте. Шәкертләрнең тән һәм җан палачы Шәпеш Габдулланы үз канаты астына алды.

Бу берьюлы шәкертләрнең күпчелеген Габдуллага каршы аякландырды, хәтта Талип, Шәпешнең үз улы, Габдулладан ераклашты. Ник дисәң, Талип үз әтисен яратмый иде. Башка балалар Шәпешнең шакмаклы камчысы һәм мыскыллауларыннан өйләренә кайтып котылалар. Талип аңардан өенә кайтып та котыла алмый иде бит!

Иптәшләренең, алар белән бергә Талипның (Габдулла аңа ияләшеп килә иде инде) кырыс мөнәсәбәте Габдулланы бөтенләй ялгыз калдырды. Бөтенесеннән авыррак кичерде ул моны. Бу борчылу, Кырлайны, Казанны сагыну тойгылары белән кушылып, Габдулланың күңелен әзме әрнетте, һәм ачы яшь аның күзләрен әзме томалады! Нинди бәхетсез ул хәзер! Шәпеш аны яклап чыккан саен, Габдулланың аңа җен ачуы кузгалды, ул аңа һаман дошманлаша барды.

Кырлайның ябык кына чырайлы, бөкрәя төшкән, кәҗә кебек кәһ! кәһ! итеп тамак кыра торган Хәбри хәлфә, Габдулланың башлап телен ачкан яхшы күңелле

хәлфә, кайда ул хәзер, кайда?! Ничек, ничек аны күрәсе килә хәзер Габдулланың! Нинди әйбәт хәлфә булган, ничек Кырлайда чагында аның кадерен белмәгән ул!

Кырлайдан — Сәгъди абзыйлардан, Кушлавычтан — Гайшә апалардан, Яңа Бистәдән — Вәли абзый белән Газизә ападан аерылып, мең бәлаләр белән Җаекка килү, күргән җәфалар, аерылу үкенечләре — һәммәсе, һәммәсе Габдуллага бушка бирелгән корбаннар булып күренделәр. Шулхәтле аның Кырлайдан китәсе, Казаннан аерыласы килмәгән иде бит! Ләкин Җаек һәм андагы зур мәктәпкә кереп уку хыялы барын да җиңде. Һәм менәтерә сиңа нәрсә килеп чыкты?!

Сораулар һәм биремнәр

1. Шәкертләр ни өчен Шәпеш хәлфәне яратмыйлар?
2. «Үзәккә үтә белә», «тиңе юк остасы» дигән сүзләр кергән җөмләләрне табып укыгыз, аларның мәгънәсен аңлатыгыз.
3. Сагыну хисе бу бүлектә ничек сурәтләнә? Габдулла кемне һәм ни рәвешле сагынып искә ала?
4. «Габдулланың кичерешләре» дигән темага кечкенә күләмле инша языгыз.
5. «Ите сиңа, сөяге миңа», «үз канаты астына алды» кебек сүзтезмәләрнең мәгънәсен ачыклагыз.
6. Бүлеккә исем куегыз.

Ләкин шуңа да карамастан хәлфәнең «менә тушыннан тушында хәтле» дип биргән сабакларын Габдулла һәрвакыт төгәл әзерләп килде, чатнатып тыңлатты, ярты кыштан гына тотынуына карамастан, сыйныфта иң алдынгы шәкерт булып китте. Аермачык: эш хәлфәдә түгел иде, әлбәттә. Шәпеш дөньяда бер кешене дә белемле ясамады. Аңардан укыган шәкертләр үзе шикелле томана, дорфа булып чыктылар, адәм рәтле эшкә ярамадылар. Габдулланың үз тырышлыгы, укуга һәм китапка булган хәвәслеге[1] тантана итте монда. Ләкин

[1] Хәвәслек — сәләт, кызыксыну.

Габдулланы болай да үз канаты астына алган Шәпеш аның алдынгылыгы белән үсенеп китте. Урыны чыкса-чыкмаса да, шәкертләр алдында да, хәлфәләр алдында да, үзе еш кына йөри торган аш мәҗлесләрендә дә ул Габдулла белән мактанырга тотынды. Галиәсгар, мәчеттәнме, берәр мәҗлестәнме кайтып керсә, каенише белән горурланды:

— Габдулланы хәлфәсе бик мактап торды әле. Имтиханга яңа казаки тектерми булмас үзенә.

Җизнәсенең аның белән горурлануы, ике апасының да моңа куанулары Габдуллага башта бик күңелле булды. Ләкин тора-бара бу хәл үзенең киресенә әйләнде.

Балалар ачуны озак саклап йөрмиләр, балалык балалык инде ул! Габдулланың да иптәшләре белән арасы төзәлеп килә, кайбере белән ул хәтта дуслашып та өлгергән иде инде. Шәпешнең мактавы, һичшиксез, аны тагын да иптәшләренә каршы куячак. Ни хакы, ни хакы бар аның Габдулла белән мактанырга?! Әйтерсең Габдулланы үзе тәрбияләп үстергән, үзе башлап телен ачкан, үзе аның күкрәген ачып, аңа үз гыйлемен тутырган! Юк, шатланмады Габдулла бу макталуларга, киресенчә, аны каты эч пошуы басты.

Беркөнне бөтен сыйныфтан ике шәкерт кенә сабакларын әйбәт тыңлаттылар: берсе — Габдулла, икенчесе — Әхмәдулла купец малае Яхъя.

— Басыгыз! — дип, хәлфә бөтен сыйныфны аякка бастырды. Аннан соң ул Габдулла белән Яхъяны алар арасыннан аерып алды да, аларга саф саен йөреп, һәрбер баланың яңагына берәр тапкыр чабып чыгарга кушты. Габдулла аптырап калды. Утызлап баланың күзләре аңа һәм Яхъяга текәлделәр. Аларның һәркайсы белән диярлек Габдулланың көрмәкләшкәне, шаярып дөмбәсләшкәне бар. Ләкин менә монда сиңа каршы торырга мөмкинлеге булмаган иптәшенең бер дә юкка ничек итеп чынлап яңагына китереп сугарга мөмкин? Габдулланың күзе Талипка төште. Ул Габдуллага: «Йәле, син

минем яңакка ничегрәк китереп сугарсың икән?» — дигән сыман, мыскыллы караш ташлап басып тора иде.

— Габдулла, йә! — дип ашыктырды Шәпеш.

Терәлеп торып булмый, бер карарга килергә кирәк иде. Һәм әллә каян үзлегеннән сүзләре табылды:

— Сабакка килгәндә сала[1] кешесенең чанасы чалулап китте дә иңбашыма китереп сукты. Өзелеп чыктымы дип торам, менә әле дә сөм тоймый[2],— дип, Габдулла уң кулын асылындырып чайкап күрсәтте һәм ялганының шундый шома килеп чыгуына үзенең дә исе китте.

Хәлфә аңа нәрсәдер әйтмәкче булып, ышаныр-ышанмас карап торды-торды да коры гына:

— Бар, алайса, урыныңа утыр! — диде.

Иптәшләре өстеннән палачлык хезмәтен Яхъяның берүзенә башкарырга туры килде.

Соңыннан иптәшләре дә Габдулланың бу хәйләсен яхшы таптылар. Ә башка көннәрне аңардан аерылып йөри торган Талип бүген мәктәптән Габдулла белән бергә кайтты.

— Син шәп уйлап таптың, әй! Ничек, ничек әле? Чалулап китте дә калак сөягемне сындырып ташлады, дидеңме?

Ул рәхәтләнеп көлде. Габдулланың да күңеле күтәрелеп китте. Алар юл буе һәр сүздән бер кызык табып, көлә-көлә шаулашып кайттылар.

Шәпеш хәлфә белән беренче алыш, шулай итеп, Габдулла файдасына хәл ителде һәм шактый шома гына үтеп китте.

Ләкин икенче алыш шактый җәнҗаллы булды, һәм Габдулла белән хәлфәсенең үзара мөнәсәбәтен бөтенләй өзеп ташлады.

---

[1] Сала — авыл (искечә әйтелеш, кала — шәһәр, сала — авыл).

[2] Сөм тоймый — бернәрсә тоймый, сизми.

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдулла Шәпеш хәлфәне ни өчен тыңламый? Аның хәйлә уйлап табуы, сезнеңчә, дөресме?

2. Талипның ни уйлавын, хисләрен ничек аңладыгыз, шуны фикерләп языгыз.

3. Яхъя урынында сез булсагыз нишләр идегез? Яхъя дөрес эшләдеме?

4. Бүлеккә нинди исем бирер идегез?

Март урталарының язга караган кояшлы көннәреннән берсе иде. Мәктәптә балаларның һәммәсен бер сыйныфка җыйдылар. Мөдәррис[1] үзе керергә һәм имтиханнар алдыннан балаларның белемнәрен сынау булырга тиеш иде. Ул авырып киткән икән. Аның урынына сыйныфка Сираҗетдин дигән карт хәлфә керде. Бөтен шәкерт дөр килеп аягүрә басты. Бу — калын түгел, ләкин таза гәүдәле, кечкенә мыеклы, сакалын кырган, тулы битле, көләчрәк соры күзле кеше иде. Ул мәһабәт түгел, ләкин өстендәге казакие һәм кыска гына чәчен маңгай тиңентен каплап, тигез генә итеп кигән кара хәтфә кәләпүше аның кыяфәтенә ниндидер тулылык, спайлык[2] бирәп тора иде. Ул, кулын күтәрер-күтәрмәс кыска гына хәрәкәт белән, балаларга утырырга кушты. Үзе көрсиләр алдындагы өстәлнең бер башына шәкертләргә ян белән килеп утырды да, ашыкмый гына башын аларга таба борып, күзләрен кысыбрак елмаеп куйды. Балаларга бу: «Мин сез наяннарны беләм бит»,— дигән сыман хәйләкәр, шуның белән бергә дусларча сердәшлекне белгертә торган караш иде. Балаларга бу ошады, ахры, алар бер-берсенә шыпырт кына нидер әйтешеп алдылар.

Шәпеш хәлфә, өстәл янына килеп, балаларга каршы утырды һәм Сираҗи хәлфәгә акрын тавыш белән нидер сөйләргә тотынды. Габдулла йотардай булып Сираҗи хәлфәне күзәтте. Шәпеш сөйләгән вакытта, Сираҗи яки

---

[1] М ө д ә р р и с — укытучы.

[2] С п а й л ы к — җыйнаклык, күркәмлек, матурлык.

аңа бөтенләй карамады, йә, ышанмаган кеше сыман, аңа күз төшергәләп кенә алды. Һәрхәлдә, бу — Габдуллага шулай тоелды. Бу — кыяфәте белән үк акыллы, әйбәт кешенең Шәпешкә икенче төрле мөнәсәбәтен ул күз алдына китерә алмады. Ә Сиражи хәлфә, бөтен сыйныф ишетерлек аермачык тавыш белән:

— Юк, туктагыз әле, Шәфигулла әфәнде, без аны калдырып торыйк! — дип, Шәпешнең ниндидер сүзен кире каккач, Габдулла бөтенләй рәхәтләнеп китте.

Аннан соң Сиражи хәлфә шәкертләргә үтелгән дәресләре буенча сораулар бирде. Ара-тирә Шәпеш тә үзенең сорауларын кыстыргалады. Габдулла Сиражи хәлфәнең аңардан соравын бик теләп көтеп утырды. Ләкин эш Габдуллага килеп җитәрәк, Шәпеш хәлфә аңа карап алды да, башка сыйныфның шәкертләренә төбәп:

— Садака бирү һәм алу фарызмы[1], сөннәтме? — дигән сорауны бирде. Габдулланың хәтеренә килде, Җаекка килеп төшүнең беренче көнендә үк Шәпеш аңа шул сорауны бирде, һәм чатнатып кайтарган җавабы өчен Габдулланы барысы да мактадылар.

Шәпешнең соравына әлеге шәкерт җавап бирә алмады. Шәпеш тагын Габдуллага күз төшереп алды һәм теге шәкерткә үзенең соравын кабатлады. Габдулла сорауның кабатлануын һәм Шәпешнең үзенә карап-карап куюын яхшыга юрамады. Шул сорауның ул хәзер үзенә биреләсен һәм Шәпешнең күрәләтә аның белән мактанырга җыенуын Габдулла сизеп алды, һәм бу нәкъ ул уйлаганча килеп чыкты да. Шәпеш:

— Җавап бирә алмадың, алайса,— диде һәм тантаналы рәвештә Габдуллага таба борылды. Габдулланың эче «жу» итеп китте.

Әгәр дә ул хәзер үзе белгән җавапны кычкырып әйтеп бирсә, Шәпешнең Сиражи алдында түбәсе түшәмгә тиячәк: әйтерсең бу белемне Габдулланың күкрәген ярып ул салып куйган! Әгәр дә инде Шәпеш хәлфәнең

---

[1] Ф а р ы з — тиешле, кирәкле эш.

шәмкә чөен[1] төшерер өчен «белмим» дип җавап бирсә, Сираҗи хәлфә алдында оят...

— Йәле, Габдулла, бәлки, син белә торгансың? — дип, аңа мөрәҗәгать итте Шәпеш хәлфә һәм, Габдулланың һичшиксез җавап бирәчәгенә ышанган хәлдә, урындык аркасына ята биреп һәм елмаебрак күзләрен йомды. Габдулла башын түбән иде.

— Йә! — диде, күзләрен ачып, Шәпеш һәм борчылып бер кузгалып куйды.

Габдулла дәшмәде һәм маңгай астыннан гына хәлфәсенә карап алды.

— Телең йотмагансыңдыр бит? — диде кызыбрак хәлфә.— Йә, әйт, син аны беләсең бит!

— Белмим,— диде Габдулла, акрын тавыш белән, һәм Сираҗи хәлфәгә карап алды.

— Ишетмим, ни диде? — дип түземсезләнеп кычкырды Шәпеш хәлфә.

Утызлап тавыш бик зур канәгатьлек белән Габдулланың җавабын кабатлады:

— «Белмим» диде! «Белмим» диде!

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен Габдулла Сираҗи хәлфәне бер күрүдә үк ошата?

2. Габдулланың Шәпеш хәлфәгә икенче тапкыр да җавап бирергә теләмәвен ничек аңлыйсыз?

3. Бүлекнең соңгы өлешен рольләргә бүлеп укыгыз. Диалог дип нәрсәгә әйтәбез?

4. Шәпеш хәлфә белән Сираҗи хәлфәгә чагыштырма характеристика бирегез.

Габдулла аркасында бөтен мәдрәсә алдында оятлы булган Шәпеш хәлфә вакыйганы аның җизнәсенә кайтып сөйләде.

---

[1] Шәмкә чөе — хәйлә чөе: мактану, масаю өчен корып куйган хәйләсе.

— Белә торып әйтмәде. Юри хәлфәсен оятка калдырыр өчен шулай итте ул, астыртынлык эшләде остазына карата,— дип әрнеде.

Бу дәү апасына һәм Зөһрә белән Фатыймага ирешге. Габдуллага һәрберсеннән өлеш чыкты.

— Син нәрсә! — дип, җизнәсе мөмкин хәтле ачы итеп әйтергә тырышты.— Эшләмә дә, юньләп укыма да, син монда атаң малын ашап ятам дип белдеңме? Алай булса, әнә мичкә белән су ташы, югыйсә мин суны акча түләп ташытам.

Ашарга утыргач, Зөһрә аның алдына кечкенә агач табак белән ботканы дык иттереп утыртты һәм авыз эченнән нәрсәдер мыгырданып алды. Башкалар ишетмәделәр, ләкин Габдулла аның «әрәмтамак» дигән сүзен аермачык ишетте. Ул табакны этәреп куйды да өстәл яныннан торып китте. Газизә аны юатып, яңадан утыртырга теләп карады. Ләкин Габдулла тәмам үзсүзләнеп утырмады һәм коры гына:

— Әрәмтамак булса, боткасын үзе ашасын! — диде.

— Кара, мин сиңа әрәмтамак дидеммени,— дип, Зөһрә бераз куркынып, акланырга теләп карады. Габдулла дәшмәде. Аннан соң ул Гыймадиларга төшеп китте.

Гайниямал өстәге хәлне, төшеп, Гыймадига сөйләп тора иде.

— Кит инде! — дип кычкырды Гыймади һәм, керел килүче Габдулланы күрү белән: — Габдулла, карале, син хәлфәгә белә торып әйтмәдеңме әллә чыннан да белмәдеңме? — дип сорады.

— Әйтәсем килмәде дә әйтмәдем,— диде Габдулла.— Мин әйткән белән мактана бит ул... Шәпеш!

Гыймади кычкырып көлде һәм, Габдулланың аркасыннан кагып:

— Шулай кирәк, дус кеше! Билләһи, дөрес эшләгәнсең! — дип куйды. Ул үзе кайчандыр Шәпеш шәкерте булып, аның аркасында бөтен мәдрәсәсен нәләтләп чыккан кеше иде.

Газизә төште һәм, «дәү апа чакыра» дип, Габдулланы өскә дәште.

— Мин анда менмим,— дип кырт кисте Габдулла.

— Менми кая барасың, юләр! — дип, Газизә апасы йомшак кына шелтәләп куйды.

— Мин Гыймади абзый белән су ташыйм. Үзем эшләп ашыйм,— диде Габдулла.

Дәү апа үзе төшеп шактый вакыт юаткач һәм өндәгәч кенә, ул кире менәргә риза булды.

Бу кәҗәләнүе өчен Габдулла җизнәсенең тагын да тузынуын көткән иде. Ләкин җизнәсе дә, башкалар да бу турыда ләм-мим бер сүз катмадылар, әйтерсең берни дә булмаган. Үзләре чакырып алдырган ятимне ашавы белән битәрләүнең кызулык белән эшләнеп ташланган гаделсезлек икәнен сизделәр булса кирәк, һәммәсе эчләреннән тындылар.

Шәпеш хәлфәнең генә шәкертенә мөнәсәбәте тәмам бозылды. Бервакыт шаярып тәрәзә ваткан өчен, Шәпеш хәлфә гаепләне тотып бирүне таләп итте. Дәшүче булмады. Шуннан соң ул, бөтен сыйныфны аякка бастырып, беррәттән яңаклатты. Бу җәзадан Габдулла да читтә калмады. Гаҗәп: ул моны бик тыныч каршылады. Беренче тапкыр иптәшләре белән беррәттән җәзалануына ул хәтта куанып һәм горурланып йөрде. Ул инде иптәшләре арасында үз кеше, сердәш булып китте. Талип белән алар хәзер аерылмас дуслар булдылар.

Имтиханнар җитте. Габдулла сынауларны җиңел үтте. Шәпеш инде бу юлы Габдулладан ничек кенә булса да үч алырга тырышты. Арага Сираҗи хәлфә төште һәм Габдулланы кыерсытырга юл куймады.

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдулланың үз сүзендә нык торучанлыгы нинди вакыйгадан күренә?

2. Сираҗи хәлфә образы сездә нинди тәэсир калдырды?

3. Әсәрдән чыгып, яхшылык һәм явызлык, гаделлек һәм гаделсезлек төшенчәләрен аңлатып бирегез.

4. Габдулланы тулырак характерлагыз. Аның кайсы яклары сезгә бигрәк тә ошады?

5. «Гаҗәп: ул моны бик тыныч каршылады» җөмләсендә Габдулланың нинди характер сыйфатларын күз алдына китерәсез?

6. Гыймади һәм Гайниямал образларын тексттагыча характерлагыз. Үзара фикер алышыгыз.

7. «Әрәмтамак», «ләм-мим», «гаделсезлек», «үз кеше», «сердәш» дигән сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз.

Иртәгә мәктәпкә барам дигән кичне Габдулла шундый күңелсез уйлар белән басылып утыра иде. Өске өйдән Газизә апасы төшеп:

— Габдулла, әйдәле, аккошым, сине җизни чакыра, — диде.

Габдулла өске өйгә килеп кергәндә, Галекәй дә анда иде. Җизнәләре, аларны үз янына чакырып алып, болай диде:

— Балалар, сез иртәгә мәдрәсәдәге сабакларыгыздан соң Әхмәтша хәлфәгә урысча укырга йөри башларсыз. Дөньялык өчен анысы да кирәк. Без менә үзебез, урысча укымагач, прошениеме, адресмы язарга кирәк булса, Әхмәтша учительгә йә судтагы писарьга йөгерәбез. Хәзер муллалар да урысча укый, дөньясы укыта...

Җизнәсенең бу карары Габдуллага шактый сәер тоелды...

Менә моны ишеткән Габдулла, җизнәсенең русча укытырга карар итүен белеп:

— Нигә, мин быел кода абыйдан укымыйммыни? — дип, шатлыгын яшерә алмыйча, сорамый булдыра алмады.

— Нигә укымаска?! — дип гаҗәпләнде җизни кеше һәм, Габдулланың үз шатлыгын яшерә алмыйча соравын сизеп, кызып китте: — Мин сине сабакка кемгә бирсәм, син шуңа йөрерсең, яме? Хәлфә сайлау синең эш түгел. Иң тәкъвә[1], иң укымышлы хәлфәбез ул

---

[1] Тәкъвә — әдәпле, тәрбияле.

безнең. Әхмәтша хәлфә дөньялык өчен әйбәт булса, Шәфигулла хәлфә ахирәт[1] өчен әйбәт. Икесе дә кирәк!..

Икенче көнне мәдрәсәдән кайткач, Габдулланың ашавы ашау, эчүе эчү булмады: ул школага барырга ашыкты.

— Габдулла, яманнан ярты кабым калдырма, ашап бетер! — диде аңа Газизә апасы.— Шкулга барырга әле сәгатьтән артык вакытың бар, кая ашыгасың?

— Ие, анда урынсыз калсаң,— диде Габдулла,— хәлфә «урын юк» диер дә кире кайтарып җибәрер.

— Җибәрмәс бер дә! Җизнәң сөйләшеп кайтты инде,— диде дәү апасы.

Язга таба ул белем ягыннан Галекәйне дә, быел гына укырга кергән иптәшләрен дә узып китте. Моңа аның зирәклеге һәм тырышлыгы нык ярдәм итте. Бервакыт ул, дәрес тыңлатырга аягына баскач, учительдән:

— Карап укыйммы, яттанмы? — дип сорады.

— Белсәң, яттан укып кара,— диде кызыксыныбрак учитель.

Габдулла Ушинский дәреслегендәге шигырьне тотлыгусыз яттан укып алып китте:

Дети, в школу собирайтесь,
Петушок пропел давно.
Попроворней одевайтесь,
Смотрит солнышко в окно...

Мактауга бик саран Әхмәтша учитель, Габдулла сөйләп бетергәч, «молодец!» дип куйды, һәм бу бөтен сыйныфны Габдуллага борылып карарга мәҗбүр итте. Габдулла бурлат кебек кып-кызыл булып янып китте. Нигә дисәң, мактауны ишетү һәм бөтен сыйныфны үзенә карату рәхәт булу белән бергә, әллә ничек кыен да иде.

— Дәрестән соң миңа керерсең,— диде учитель аңа, русчалатып.

Габдулла учительнең чакыруына кызыксыну катыш каударланып куйды: «Нәрсәгә икән?»

---

[1] Ахирәт — *бу урында*: теге дөнья мәгънәсендә.

Дәресләр беткәч, ул, учитель кушуы буенча, аның өенә керде. Учительнең квартирасы мәктәпнең түбән катында булып, ишеге баскычтан төшү белән үк сул якта иде.

— Әйдә, уз, Мөхәммәтгарифов! — дип дәште эчтән Әхмәтша учитель. Ул стена эченә кертеп ясалган кечкенә шкафы янына килде һәм, аның пыяла капкачын ачып, андагы күп кенә эреле-ваклы китапларны актаргалый башлады. Бераздан соң ул тышына буяулы рәсемнәр төшерелгән юка гына бер китапны алып Габдуллага тоттырды.

— Менә,— диде ул,— бу — русның зур шагыйре Александр Сергеевич Пушкин язган китап. Бу да бая син укыган этәч турында, тик бусы инде простой этәч түгел, алтын этәч...

Әйтерсең учитель китап тоттырмады, ә канат тагып җибәрде аңар! Ул очынып өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды...

* * *

Габдулланың үз гомерендә беренче тапкыр укып чыккан, укып кына түгел, төшенеп укып чыккан русча китабы шушы булды. Ул аны бер генә тапкыр түгел, кат-кат укыды, укыган саен, китап аңа үзенең яңа яклары белән ачыла барды.

— Габдулла акыллым, май бетереп утырма,— дип Гайниямал аңа кич саен диярлек юкка гына дәште. Габдулла аңа:

— Хәзер, Гайниямал апа, менә әз генә калды,— дип, ятарга вәгъдә итте һәм шундук китап эченә кереп китте дә тагын бөтен дөньясын онытты.

Заманнар үтәр. Галиәсгар байның подвалында яшәгән ятим малай егет булыр, үзе китаплар яза башлар. Шунда ул этәчнең уяну чорларында никадәр мәгънәви ишарә-символ булып хезмәт итүен, күп кенә халыкларның әдәбият тарихында этәч, таң иртәсе, кояшның беренче нурлары халыкның йокыдан уянуын күрсәтә

торган сурәтләү чаралары икәнен аңлар. Үзенең иҗат биографиясен ул Кольцовтан файдаланып язган «Ник йоклыйсың, мужик?» дигән шигыре белән башлар, йокыдагы мужикларын таң әтәче сыман үзе уятырга керешер, халык белән бергә:

Таң әтәче кычкырадыр,
Әллә таң ата микән? —

дип җырлар. Ниһаять, менә шушы Пушкин «Алтын әтәч»енең тавышын татар дөньясында татар телендә яңгыратыр!..

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдулланы ни өчен рус мәктәбенә бирергә булалар? Бу турыда нинди сөйләшү була?

2. Габдулла мәктәпкә барыр алдыннан нинди хисләр кичерә, ничек әзерләнә?

3. Укытучы Әхмәтша Габдулланы нәрсә өчен мактый, өенә нигә чакыра?

4. Әсәр ничек тәмамлана, Габдулла тормышының кайсы чоры турында сүз бара? Габдулла ятлаган шигырь белән зур Тукай булгач язган шигырьләре арасында нинди бәйләнеш бар?

5. Г. Тукайның нинди шигырен яттан беләсез? Сөйләп күрсәтегез.

БӘЛӘКӘЙ АПУШ НИЧЕК ЗУР ТУКАЙ БУЛДЫ?

«Тукай» романын тулысынча укып чыксак, аның шушы сорауга җавап рәвешендә язылганын күрер идек. Җаек (хәзерге Уральск) шәһәрендә Габдулла унике ел яши, гомеренең яртысы диярлек шунда уза. Биредә ул мәдрәсә тәмамлый, рус мәктәбендә белем ала, хезмәт юлын башлый һәм, иң әһәмиятлесе, шагыйрь булып җитлегә.

Без укыган өзекләрдә игътибарны җәлеп итә торган як — чит-ят җиргә, туган булса да, таныш булмаган кешеләр арасына килгәч, Габдулланың ниләр кичерүе.

Менә ул җизнәсе өендә. Биек түшәм, буяулы тәрәзәләр, яхшы җиһаз, Габдулла өчен ят булган зур бүлмәләр. Җизнәсенең елмаеп каравын күргәч кенә, аның

каушавы бетә. Өйнең аскы катында гади генә бер бүлмәдә яшәгән хезмәтчеләр Гыймади белән Гайниямал янында ул үзен иркенрәк, үз оясындагы кош баласы кебек тынычрак хис итә.

Габдулла Җаек мәдрәсәсенә зур өметләр белән килә. Матур итеп хыяллана белгән малай мәдрәсәне дә, хәлфәне дә Кырлай белән чагыштырганда күп яхшырак, күркәмрәк итеп күз алдына китергән иде. Ул бит биредә гыйлем җыячак, дөньяга иң якты тәрәзәләр булып уелган китаплар укып рәхәтләнәчәк. Авылда бит аны китап азлыгы тилмерткән иде. Габдулланың хыялы чынбарлыкка бәрелеп, җиргә егылып төшә: шыксыз гына йорт, шәп чапанлы, яшел чалмалы, мәһабәт буйлы, күкрәп чыккан тавышлы зур галим урынына шуның нәкъ киресе булган, исеме дә имгәтелгән Шәпеш (Шәфигулла) хәлфә. Бу хәлдән безнең дә күңелләр кителеп куя.

Мәдрәсәдә Габдулланың иң үзәгенә үткән нәрсә — Шәпеш хәлфәнең наданлыгы, тупаслыгы, гаделсезлеге. Бер гаепсезгә аның үзен яки башка шәкертләрне рәнҗеткәндә, Габдулланың сизгер күңеле, нәни йөрәге әрни. Әмма ул сабый җанында уянган горурлык хисенә таяна, гаделлекне якларга кирәк булганда икеләнеп тормый, үзенә әллә каян гына көч килә, хәйләсе дә табыла. Нәни Апушның әнә шулай холкы чыныга, рухы ныгый башлый.

Габдулла ялгызлыкны, иптәшләренең кырыс мөнәсәбәтен бик авыр кичерә. Ачлык-ялангачлыкны ятимлекнең юлдашы итеп табигый кабул иткән сабый үзенең тәненә түгел, җанына җылылык эзли. Ул җылылык иптәшләре аны чит иткәндә, туганнарының үзләре чакырып китергән ятим баланы ашаган ризыгы белән «әрәмтамак» дип битәрләгәндә аеруча кирәк. Безнең күңелләр дә Габдулланы кызганып әрни, рәхимсезлеккә нәфрәт уяна.

Белемнәре буенча үзеннән түбән булган шәкертләргә дә Габдулланың тиң итеп каравы, иптәшләренә теләктәш, ярдәмчел булуы әсәрдә бик әйбәт сурәтләнгән. Ярлыларны, кыерсытылганнарны яклап, тигезлек һәм гаделлек өчен баһадирларча көрәшкә күтәреләчәк зур Тукайның беренче адымнары шулай ясала. Ул, тугры Тукай булып танылгач та, Җаектагы тормышын онытмый. Сираҗетдин белән Әхмәтша хәлфәләренә рәхмәте дә гомере буена саклана. Халыкның сөекле шагыйре

булып җиткәч инде, Тукай остазларын үзе сайлап ала. Әкиятләре, җырлары белән балачактан күңелендә калган халкы турында, бөек Пушкин һәм Лермонтов хакында олылап шигырьләр яза. Ул әле үзенең бөтен татар шагыйрьләре өчен остаз булып әвереләчәген, үз исемендәге бүләкнең иң дәрәҗәле бүләк булачагын, туган көннәре шигырь бәйрәме итеп үткәреләчәген иң матур хыялларында да күз алдына китерми. Халык рәхмәте Тукайга, шул рәвешчә, тарихлар аша узып барып җитте.

Тукайның гомере яргы юлда өзелә. Аның турында зур әсәр яза башлаган Әхмәт Фәйзинең тормышы да яшәлеп бетмичә, әсәре тәмамланмыйча кала. Үләренә ике көн кала ул, Тукайга багышлап, шигырь яза. Бу юллар әйтерсең лә аның Тукай белән саубуллашуы була.

Белмим, кайсы таулар күкрәгеннән
Һәйкәлеңнең ташы, тимере,—
Тик син үзең — халык йөрәгеннән,
Халык мәхәббәте — синең исемең,
Халык гомере — синең гомерең!

Алдан сизәләрдер шагыйрьләр үз язмышларын! Алар безнең күңелләрдә яшәсен, без дә аларга рәхмәтле булыйк.



Шигърият әдәбиятта иң дәрәҗәле урында тора. Шуңа күрә чын шагыйрьләр халыкларының сөекле уллары булып танылалар, халык күңелендә мәңге яшиләр. Тормышның иң кыен вакытларында, тарихның хәлиткеч көннәрендә хак сүзне, иң кирәкле сүзне шагыйрьләр әйтә. Алар үз халкы исеменнән, аның намусы һәм җан авазы булып сөйлиләр.

Татар халкының йөз аклыгы булган, егерме җиде еллык гомеренә гасырлар гамен сыйдыра алган тугры Тукай... Яшьлекнең, яшәү яменең ялкынлы җырчысы, илһамчысы булган зәңгәр күзле Такташ... Кыска гомерле шагыйрьләр һәм мәңгелек шигърият!

Бу иҗатларда әдәбиятның тарихы чагыла, халыкның кайгы-хәсрәте, шатлык-өметләре гәүдәләнә. Үз тирәсенә башка шагыйрьләрне дә җыйган бу исемнәр янына тагын да бер гаҗәеп бай әдәби дөнья — Туфан шигърияте килеп ялгана.

Хәсән Туфан
(1900—1981)

Туфан искиткеч намуслы, иманлы,
кешелекле шагыйрьләрнең берсе иде.

Сибгат Хәким

Нәкъ Тукайча — халкының язмышын уртаклашкан, аны чын мәгънәсендә йөрәге аша үткәргән Туфан. Нәкъ Такташча — яңа хисләр белән, зур идеаллар белән рухланган, аның якын дусты булган Туфан. Әйтерсең язмыш аны үзе сайлап алган.

«Ничек, нигә шагыйрь булдым соң?» дигән сорауга җавап эзли башласам, минем күңел ирексездән кайдадыр еракларда калган балачакларга юнәлә.

Минем туган ягым борынгы Болгар ханлыгына кергән бер төбәк булган, күрәсең...

Әни минем, гәрчә язу белмәсә дә, халыкның бер баласы буларак, ифрат шигъри җанлы кеше иде. Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә иң әүвәл әнием өйрәтте мине. Белеп, максат итеп куеп түгелдер, әлбәттә, тумыштан ук нечкә күңелле, хискә бай кеше булгандыр...

Ул мине ишегалдына яки бәрәңге бакчасына алып чыга да дөньяны күрсәтеп йөри, кайткан яки киткән киек казлар, торналар белән генә түгел, куаклар, таллар, җилләр, йолдызлар белән дә сөйләшә башлый иде. Йолдызларны танырга, табарга өйрәтә, аларның исемнәрен әкиятләргә кушып сөйли иде...

Әти бүтән авылларга мич чыгарырга барган чакларда — офыкларның аргы якларындагы киң дөнья белән дә таныша башласын диптер инде — мине дә үзе белән алып китә торган иде. Шундый «читтә» йөрүләрдән мин арып түгел, ә баеп, әллә никадәр яңа җыр отып, табышмаклар, мәкальләр, яңа сүзләр отып кайта идем. Укый-язарга мин сабак укып түгел, бик кечкенәдән үк уйный-уйный өйрәнгәнмен. Китапларның төрле, матур төстәге аллы-гөлле тышкы кәгазьләренә, алардагы ниндидер серле сүзләргә соклануым ярдәм иткәндер бәлки».

Хәсән Туфан «Бәлки шагыйрь булмас та идем...» дигән истәлегендә шигъриятькә килүенең тәэсирләрен, әнисе, табигать, тормыш, дөнья биргән сабаклар турында менә шулай яза. Әлбәттә, сәбәпләр күптөрле, шулай да йолдызлар телен аңлап, табигать серенә төшенеп үсү шагыйрь хыялына канатлар куя.

Язмыш Туфанны урау юллардан йөртә: абыйлары янында Урал шахталарында эшли, «тернәкләнеп, баеп булмый» торган эштән коткарып, абыйлары аны Уфага «Галия» мәдрәсәсенә җибәрәләр. Анда ул яшьлек, әдәбият дөньясында яши, Галимҗан Ибраһимов дәресләрен тыңлый. Әмма укыр өчен акча кирәк, тагын — Урал заводлары, аннан соң — Казан каласы. Тынгысыз җаны Туфанны ил буйлап сәяхәтләрдә йөртә.

Ил язмышының кара җилләре килеп кагыла Туфанга — Сталин лагерьларында уналты ел буена гаиләсеннән, туган җиреннән, әдәбияттан аерылып торырга мәҗбүр итела ул. Хәер, әдәбияттан аерыла дию дөрес

булмас: 1956 елны Казанга әйләнеп кайткан шигырьләре аның бер генә ел, бер генә көн дә иҗаттан башка яшәмәгәнлеген раслыйлар. Шигырьләре белән бергә Туфан үзе дә кайтты. Татар әдәбияты өчен зур бәхет иде бу: ул әле, кеше рухының җиңелмәслеген, шигъри сүзнең бөеклеген исбатлап, тагын чирек гасыр иҗат итте.

КАЕННАР САРЫ ИДЕ

Кайгының ни сүз икәнен
Белмәгән сабый бала
Моңая, сагына, күрәсең:
Ал йөзе сарылана.

Әттәсе киткән тарафка,
Юлларга карый-карый,
Шәлләргә төренеп суыкта
Уйланып утыра сабый...

Көз иде... Җирнең шушындый
Күңелсез чагы иде;
Астралар, гөлләр кыраулы,
Каеннар сары иде...

Исән-сау диләр әтисен,
Сугышта йөри диләр...
Аңардан никтер сабыйга
Сәлам-хат китермиләр.

Килә ул зурлар янына
Сурәтле китап сорап,—
Шкафта — кызыл пичәтле
Ниндидер бүтән йозак.

Кайгының ни сүз икәнен
Белмәгән сабый бала!
Ни булды сиңа, гүзәлем,
Йөзләрең сарылана?

Синең дә бардыр, күрәсең,
Әрнүләр, җәлләүләрең:
Яшьләрең юа лабаса
Күзеңнең зәңгәрләрен...

1942 ел

Шигырьне укыгач, күңелдә моңлы җыр тыңлаганнан соң була торган сагыш, моңсу хисләр уяна. Әйдәгез, шуның сәбәпләрен эзләп карыйк. Җанлы булып, тышкы кыяфәте белән дә, кичерешләре белән дә күз алдына килгән сурәт — сабый бала. Тагын кем? Сабыйның хәлен аңлап, үзәге өзелеп, аны кызганган шагыйрь. Ул укучы өчен генә сөйләми, сабыйның үзе белән дә сөйләшә, аңа эндәшә.

Кайсы вакыт икәнлеге дә ачык әйтелгән — сабыйның әтисен сугышта йөри диләр. Сабый үз өендә дип күз алдына килә: мөгаен, тәрәзәдән карап, әтисен көтә, китап сорап, шкаф янына килә. Сугыш чорындагы гадәти күренеш кебек, бер караганда. Әмма шигырьдә безгә тәэсир итә торган тагын ниндидер серләр бар әле. Игътибар белән шигырьне тагын бер кат укыйк.

Шигырьгә исемне «Сабый бала», «Сугышка киткән әти», «Сугыш» дип тә куеп булыр иде. Ә менә Туфан «Каеннар сары иде» дигән, өстәвенә, беренче юлның беренче сүзе — «кайгы». Шунда ук халык җырлары, әйтемнәре искә төшә: сары каен — кайгы билгесе. Гомумән, сары төс — сагыш, кайгы-хәсрәт төсе. Шагыйрь гел янәшә куеп, чагыштырып бара: саргайган каен һәм ал йөзе сарылангaн сабый, сугыш чоры һәм көз, кыраулы гөлләр.

Бик моңсу күренеш тасвирлана, беренче дүрт юл шигырь ахырында җыр куплеты кебек тагын кабатлана. «Яшьләрең юа лабаса күзеңнең зәңгәрлеген» дигән сүзләр дә үзәкне өзеп куя: нинди ачы, олылар кайгысы кебек хәсрәтледер ул сабыйның күз яшьләре.

Ләкин хикмәт тагын да тирәнрәк яшерелгән сәбәптә әле. Сабыйның әтисен исән-сау диләр, сугышта йөри диләр, тик никтер аңардан сәлам-хат китермиләр. Китап шкафы да «кызыл пичәтле», анда да ниндидер бүтән йозак. Гомумән, сабый янында бер кеше дә юк кебек — әнисе дә, туганнары да. Зурлар аннан нидер яшерәләр, әйтмиләр кебек.

Шигырьнең язылу вакытына игътибар итик. Туфан бу елларда Себер далаларында, тоткынлыкта. Шагыйрьнең йөрәге ничә кат яралы: тугры улы булган Ватанын яклап сугышка катнашудан мәхрүм ул. Бердәнбер кызы, сабые ни хәлдә икән? Әтисен сагына микән? Юатучы бар микән? Ул аны да белми. Менә шушы тирәннән килгән сагыш, ярдәм итеп, юатып булмый торган үкенечле хәл тетрәндерә икән безнең күңелне. Туфан үзе һәм үзенең сабые турында яза, күңеленнән аның белән сөйләшә икән ләбаса! Хәер, шундый ук язмышны кичергән сабыйлар күпме иде бит ул чорда, шагыйрь җаны өчен алар барысы да — үз сабыйлары. Шуңа күрә дә бит дөньяның барлык кайгылары шагыйрь йөрәге аша уза дигән әйтем бар, шул бит инде шагыйрьлекнең чын билгесе!

Туфанның хәлен җиңеләйтергә тырышып, аны исән калдыру өчен, үз гомерен аямаган тугрылыклы хатыны турында да гүзәл шигырьләр яза шагыйрь. Менә шуларның берсе.

ИЛДӘ НИЛӘР БАР ИКӘН?

Тыштаниләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Боз тәрәзә алсулана —
Пожар микән, таң микән?
Тышта ниләр бар икән?

Бездә дә таң тугандыр,
Инде ул да торгандыр,
Бергә чаклар исенә төшеп,
Күңелләре тулгандыр...
Бездә дә таң тугандыр.

Уйлыйдыр ул: «Сау микән?
Эче тулы зар микән?
Хәсрәтләрен таратырга

Тәмәкесе бар микән?
Исән микән, сау микән?»

Аклы киемен кигәндер,
Бәлки, кайтыр дигәндер,
Зәңгәр карны ера-ера,
Вокзалларга килгәндер...
Бәлки, табылыр дигәндер...

Илдә ниләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Һавадагы алсу шәүлә
Пожар микән, таң микән?
Илдә ниләр бар икән?

1944 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Билгесезлек нинди чаралар белән белдерелгән?

2. Төсләрне белдергән сүзләрне эзләп табыгыз. Алар нинди сүзләрне ачыклап килә?

3. Нәрсәләр үзара чагыштырыла, нинди сүзләр кабатлана?

4. Шигырьдә сүз кем турында бара?

5. «Ил», «юл», «пожар», «таң» сурәтләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

ГӨЛЛӘР ИНДЕ ЯФРАК ЯРАЛАР

Гөлләр инде яфрак яралар,
Хәбәр итеп язлар җитәсен.
Язлар җиткәч, сугыш бетәсен
Көтеп утыра сабый балалар:
Гөлләр инде яфрак яралар!

Хәбәр итеп язлар җитәсен,
Кояш керә кайбер өйләргә
Утыны беткән ятим өйләргә.
Керә дә котлый алар иртәсен,
Хәбәр итеп язлар җитәсен.

Язлар җиткәч, сугыш бетәсен
Салют кыла «сугыш алласы».
Чү, елама, солдат баласы:
Туплар әйтә әнә, ишетәмсең,
Язлар җиткәч, сугыш бетәсен.

Көтеп тора сабый балалар
Аждаһаның башын өзгәнне.
Ә ул инде җиңелеп тезләнде.
Дар элмәге лаек та аңар,
Карап тора сабый балалар...

Гөлләр инде яфрак яралар,
Язы җитте, язы дөньяның!
Ас җәлладны, солдат туганым,
Беләләр бит барыбер балалар...
Гөлләр инде яфрак яралар!

1945 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу шигырьдә нинди сабый балалар турында сүз бара?
2. Шигырьнең интонациясен, яңгырашын билгеләп карагыз, алдагы шигырьләр белән чагыштырыгыз.
3. «Гөлләр», «яз», «кояш», «хәбәр» төшенчәләре нинди хис тудыра? Кайсы яз турында сүз бара?
4. «Аждаһа», «җәллад» сүзләрен аңлыйсызмы? Алар халык авыз иҗатының кайсы төрендә кулланыла?

Шигырьләргә игътибар итсәгез, аларның өлешләргә, кисәкләргә бүленгәнлеген күрерсез. Бу өлешләрне без халык җырларында куплет дип атадык. Икенче төрле аларны дүртьюллыклар дип тә әйтергә була. Әдәбият белемендә строфа дигән термин кулланыла. Ул дүртьюллык, куплет дигән мәгънәләргә генә туры килеп бетми, чөнки поэзия-шигърият — гаять бай күренеш.

Мәсәлән, Туфанның беренче шигыре җиде строфадан (кисәктән), икенче һәм өченче шигырьләре бишәр строфадан тора. Әмма бу строфаларның күләме бертигез түгел. «Каеннар сары иде» шигырендә һәр строфа дүрт юлдан, үз термины белән әйтсәк, тезмәдән тора. «Илдә

ниләр бар икән?» шигырендә исә строфалар бишәр юлны — тезмәне берләштерә. Ләкин хикмәт гади санда гына түгел, соңгы бишенче юлның нидән гыйбарәт булуында. Укып карагыз әле, бу тезмә сезгә танышмы? Әйе, ул — беренче юлның игезәге. Һәр строфа әнә шундый кабатлауга корылган. Ләкин бу гади, уйламыйча кабатлау гына түгел, киресенчә, уйның очына чыга алмыйча, күңелдәге сүзләрне әйтеп бетерә алмаганга гаҗиз булып кабатлау. Укыганда да без беренче һәм бишенче тезмәләрне төрле интонация белән, төрле мәгънә төсмерләре өстәп укыйбыз.

Строфа — шул ук вакытта мәгънә һәм яңгырашы буенча бербөтен, тәгәлләнгән өлеш ул. Мәсәлән, «Илдә ниләр бар икән?» шигыренең беренче строфасы:

Тышта ниләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Боз тәрәзә алсулана —
Пожар микән, таң микән?
Тышта ниләр бар икән?

Фикер тулысынча аңлашыла, өстәвенә, биш юлның дүртесе охшаш яңгырашлы сүзләргә тәмамланган (андый сүзләрне рифма дип атыйлар): бар икән — кар микән — таң микән — бар икән. Бу строфа үзе генә дә бер шигырь була алыр иде, хәтта аны халык җыры кебек итеп, берәр халык көенә җырлап йөреп тә була. Менә, шул рәвешчә, кайбер шигырьләрендә Хәсән Туфан бишенче юл өстәп, строфаны көчәйтеп, матур итеп йомгаклап куя. Бу — шигъриятькә Туфан алып килгән яңалык, аны башка шагыйрьләр дә яратып кулланалар.

Өстәмә юл куллану алымын Туфан тагын да үстереп җибәрә. «Гөлләр инде яфрак яралар» шигырен карыйк. Шагыйрь челтәр үргәндәй барлык строфаларны да үзара бәйләп куйган: беренче строфаның һәр юлын — тезмәсен — үзеннән соңгы строфаларның беренче юлы итеп кабатлап барган. Бу шигырь бер кәүсәдән тармакланып үскән агач кебек, строфаларын аерып алып булмый. Шигырь ул архитектор төзегән гаҗәеп гүзәл бина, зиннәтле сарай кебек. Андагы бизәкләрне — осталыкны күрә белергә кирәк. Хәсән Туфан шигъриятнең чын остасы, күп кенә шагыйрьләрнең остазы булганга, аның иҗатыннан иң матур үрнәкләрне табарга мөмкин.

Мөстәкыйль рәвештә тагын берничә шигырен укып, аңлатып карагыз.

АРАЛАГЫЗ МИНЕ

Дөньяның мин күрдем суын, күлен,
Урманнарын, тавын, чүлләрен...
Тик күрмәдем, Идел, синең кебек
Сагындырган ягын күрмәдем.

Читләтмәде мине, кимсетмәде
Җир йөзенең һичбер имәне;
Тик берсе дә, сезнең кебек итеп:
«Улым, бәгърем, бәбкәм»,— димәде.

Карагаен күрдем тайгаларның,
Усакларын күрдем Усаның;
Тик синең күк юксындырганны мин
Күрмәдем беркайда, усагым!

Ак каеннар азмы давылларда,
Япандагы олы юлларда...
Беркайда юк ләкин сезнең сыман
Сагындырган каен — беркайда!

Һәрбер гөле җирнең якын күрде,
Ят кеше син безгә, димәде;
Тик берсе дә, сезнең кебек итеп:
«И абыкаем, бәгърем, браматым[1],
Җанкисәгем»,— дия белмәде...

Арыды бугай сезне сагынып йөрәк,
Арыды бугай газиз башкаем.
Яшел шәлең белән күләгәләп,
Ял иттер бер, сеңлем ак каен.

---

[1] Б р а м а т — мишәр диалектында кулланыла: брат, сукбай мәгънәсенә якын, үз итеп эндәшү.

Аралагыз мине, ак каеннар,
Аралагыз, миләш, баланнар:
«Ул фанатик ватанчы»,— дип тирги
Экваторда мине бананнар...

1956 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне Хәсән Туфанның биографиясе белән бәйләп карап буламы?

2. Табигать күренешләрен шагыйрь нинди итеп, ничек тасвирлаган? Табигать образларын табып күрсәтегез.

3. «Күрдем — күрмәдем», «диде — димәде» сүзләре белән шагыйрь нәрсәләрне чагыштырып бара? Ни дип әйтергә тели?

4. «Аралагыз мине...» дип башланган соңгы строфаны ничек аңлыйсыз? «Мине бананнар тирги» дигән сүзләр туры мәгънәдәме?

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Кулмәк җиңен ертасымы? —
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

— Кайт!..— дип, хатлар килделәр...
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы алкалары,
Бусы — кабере...— диделәр.

Әгәр тагын килсәләр:
— Сау! — дип, хәбәр бирсәләр,

Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?
Бәйлисе бар йөрәкне...

1956 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Строфаларга игътибар итегез: соңгы ике строфа кебек алдагыларын да дүртьюллык итеп язып буламы? Ни өчен автор аларны алты, биш тезмәгә таркатып язды икән? Аңлашылсын өчен, тыныш билгеләренә басым ясап, укып чыгыгыз.

2. Кемнәр, нинди язмышлар турында сүз бара? Кайсы юллардан, нинди сүзләрдән чыгып, шундый нәтиҗә ясыйбыз? Үткән дәресләрдә укыган шигырьләрне дә исегезгә төшерегез.

3. Ни өчен шагыйрьгә кулы җылы булган кеше кирәк? Нигә аның йөрәген «бәйләргә» кирәк? Шагыйрьгә ничек ярдәм итеп була?

4. Соңгы дүрт юлны, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аңлатыгыз.

5. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез, ятлагыз.

ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ ТУКАЙГА

Әйләнәндә — гөлләр...
Сүзен гүя
Шулар аша әйтә күңелләр:
— Туган көнең беләні — дигән сыман
Елмаялар кебек бу гөлләр.

Килә, килә... Язлар саен сиңа
Илең килә туган көнеңдә,
Бетми торган гомерен кушкан сыман
Синең бөек, кыска гомергә.

Еракларден, йөзләп сукмаклардан
Килеп меңнәр һәйкәл каршына.
Еллар саен арта бара торган
Сәламнәрен сиңа тапшыра.

Әбиләр дә килә синең янга,
Ил улының хәлен белергә:
«Еллар үткән... Ләкин син һаман яшь,
Син һаман сау безнең күңелдә...»

Туган илнең тирән ихтирамын
Әверелдереп гөлгә, чәчәккә,
Туган көнең белән котлап килү
Керсен иде гомум гадәткә.

Без чәчәкләр аша тапшырырга
Тиеш тә бит сиңа сәламне...
Ел буена тик бер генә тапкыр
Күрәсең син, Тукай, аларны.

Ник кырларда чәчкә өзгән чакта
«Тукай өчен бусы» димәскә?
Ник кырлардан кайтып килгән чакта
Синең янга керә китмәскә?

Ил көнендә кырлар-болыннардан,
Урманнардан кайткан уңайда,
Ел эчендә тик бер генә тапкыр
Килеп китсә һәркем Тукайга,
Синең янда яздан кышка кадәр
Гөлләр балкыр иде көн саен...
Әйтер иде илләр: «Күрче, ничек
Сөя халык үзенең Тукаен...»

Килер илең
Меңләп сукмаклардан,
Килер иртән, килер кичләрдә,
Сәламнәрен чәчәкләре аша,
Гөлләр аша тәкъдим итәргә.

1966 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. «Әйләнәңдә — гөлләр...», «Илең килә туган көнеңдә», «Әбиләр дә килә синең янга, ил улының хәлен белергә» дигән юллар туры мәгънәдә әйтелгәннәрме? Бу җөмләдән нинди фикерне аңлыйбыз?

2. «Туган көнең белән котлап килү керсен иде гомум гадәткә». Туфанның бу теләге тормышка аштымы? Тукайның туган көне кайчан, кайларда, ничек билгеләп үтелә? Шул турыда сөйләгез. Сезнең ул бәйрәмдә катнашканыгыз бармы?

3. Шигырьдән чагыштыруларны, кабатланган сүзләрне, юлларны табып күрсәтегез.

4. Строфалар ничә юл-тезмәдән тора? Ни өчен алар төрле күләмдә икән? Чагыштырып укып карагыз.

Хәсән Туфан иҗаты турында сөйләшүне аның үз сүзләре белән йомгаклап куярга була: «Әдәбият кырларында, шигырь төбәкләрендә яшәлгән шактый озын гомерем юлында төп иманым — халыкның Тукай әйткән сыйфатларына ышануым — торган саен үсә, ныгый барды һәм ныгый бара.

...Тукайның: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»,— дигән үлемсез сүзләре искә төшә.

...гәрчә шигырь язмаса да, үзенең көндәлек тормышындагы кичерешләрен җыр итеп, бәет һәм мәкаль итеп әйтә ала торган халыкка, җырлый-җырлый яши торган җор халыкка, кулны күкрәккә куеп әйтелгән кыска гына сүз белән дә җитеп була...»

Бу юллар Хәсән ага Туфанның «Давыллы еллар лирикасы» исемле шигырьләр җыентыгына (Казан, 1970 ел) язган кереш сүзеннән алынды.

Хәсән Туфанның тормышы һәм иҗаты — тыйнак батырлыкның матур үрнәге. Аның ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнүе, мөгаен, үзеннән бигрәк аның талантына баш июче укучыларын шатландыргандыр.

1966 елда Хәсән ага Туфанга «Сайланма әсәрләр»е өчен Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе бирелде. Чын мәгънәсендә халык шагыйре булган олы җанлы бу шәхес әдәбиятыбызның үлемсез бер өлеше булып яши.

Әдәбиятның чишмәсе, юл башы, атлап киткән җирлеге — халык авыз иҗаты. Әдәбиятның үзендә дә башлап җибәрүчеләр, нигез салучылар бар. Мәсәлән, татар драматургиясенең түрендә Галиәсгар Камал исеме тора. Татар поэзиясенең көче, биеклеге Габдулла Тукай иҗаты белән үлчәнә. Татар прозасында исә аерым бер урынны зур талант иясе, барлык тугандаш халыклар тарафыннан остаз дип танылган күренекле шәхес — Галимҗан Ибраһимов алып тора.

Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

Талант ияләре безне һәрвакыт сокландыра. Алар белән горурланабыз, халкыбызның уллары дип атыйбыз, хезмәтләрен олылап, рәхмәт хисе белән искә алабыз. Галимҗан Ибраһимов—менә шундый шәхес. Аның кайсы өлкәләрдә хезмәт иткәнен, эшчәнлеген санап кына чыксак та хәйран калырлык — революционер һәм дәүләт эшлеклесе; ике гасыр әдәбиятлары арасына салават күпере салган кебек, ике чорда да гаять актив иҗат иткән, әдәбиятның алгы сафында барган әдип һәм журналист; әдәбият теориясен һәм тәнкыйтен үстерүгә күп хезмәт куйган кеше; тел, әдәбият, тарих фәннәре өлкәсендә эшләгән галим һәм укытучы. Үз чорының иң белемле фикер ияләреннән берсе, таланты безнең көн язучыларын һәм укучыларын рухландыра торган каләм иясе.

Каян килә бер кешегә шулкадәрле сәләт, зур эшләр башкара алырлык осталык, тырышлык, рухи көч? Җавап эзләп аның туган туфрагы, гаиләсе, белем учакла-

ры, гомер юлы һәм яшәү шартлары турында уйланасың. Сәбәпнең иң беренчесе, әлбәттә, табигать биргән сәләттә, бала чагында күңелгә салынган эзләрдә, шул чакта ук формалаша башлаган характерда.

Галимҗанның бала чагы Башкортстанның бик матур урынына, су буена урнашкан Солтанморат авылында башлана. Елга-тугайларның, урман-тауларның сихри матурлыгы нечкә күңелле Галимҗанның хәтерендә дөньяның иң гүзәл урыны булып кала, аны матурлыкны күрергә, сокланырга, хыялланырга өйрәтә. Шуңа балачакның бизәге, яме булып истә кала торган уеннар, урманга җиләккә, елга буена балык тотарга йөрүләр килеп кушыла. Галимҗанның туганнарыннан берсе Мохтар Ибраһимов болай дип искә ала: «Матур чаклар, күңелле чаклар!.. Әле дә хәтердә. Бервакыт без кечкенә арба ясау белән мавыгып киттек. Безгә аны зурлар да ясап бирергә әзер торалар, тик үзебезнең ясыйсыбыз килә. Без әле рәтләп пычкы да тота белмибез, шулай да үзебез ясыйбыз, үзебез эшлибез. Ниһаять, арбабыз эшләнеп бетте... Көпчәкләр юан колгалардан кисеп ясалган. Дүртесе дүрт эздән бара. Шулай да ул безнең өчен авылдагы иң матур, иң җыйнак арбалардан. Нигә матур булмасын, без ясаган бит аны!»

Талантның икенче шарты — белемгә омтылудыр. Әтисе Гыйрфан абзый, кырыс холыклы булса да, балаларын укыту өчен бөтен көчен куя. Ул үзе дә мәдрәсәләрдә белем алган, алдынгы карашлы, ачык фикерле кеше була. Муллалык дәрәҗәсен алган булса да, Солтанморатка килеп урнашкач, җирне, крестьян хезмәтен яратып, иген игү эшенә керешеп китә. Атларны бик ярата, үзе дә чабыш атлары үстерә. Галимҗанның әнисе Хәсәнә апа укымышлы шәһәр кызы була, балаларын да башлап ул үзе укыта.

Галимҗан хезмәт юлына иртә кереп китә. Хезмәтнең иң беренче чираттагысы (бала өчен) — белем алу. Аны юллар Оренбург, Өфе калаларына алып китәләр. Җәй көннәрендә ул авылда әтисенә, туганнарына кыр эшләрендә булыша, соңрак казакъ далаларына чыгып китә, балалар укыта, Урал заводларында эшли. Шулай итеп, хезмәт Галимҗан өчен тормышның нигез шарты, яшәү рәвеше булып әверелә.

Мәдрәсәләрдә укыганда ук, язган сүзнең, китапның көчен, тәэсирен тоеп алган, үзе дә мәкаләләр, хикәяләр

яза башлаган Галимҗанны Казан каласы үзенә тартып тора. 1909 елда, университетка керү теләге белән, ул Казанга килә, бу хыялы тормышка ашмагач, мөстәкыйль рәвештә, үзлегеннән фәннәрне өйрәнә башлый. Максатына тайпылмыйча, чигенмичә бара, гаҗәеп дәрәҗәдә күп эшли — талант иясе бу сыйфатлардан башка була алмый, гомере нәтиҗәле булмый, сәләте дә ярты юлда сүнеп, сүрелеп кала.

Галимҗан Ибраһимов зур, давыллы вакыйгалар эчендә кайнап яши, күп җирләрне, кешеләрне күрә. Без яратып укый торган әсәрләре дә менә шул бай, катлаулы, каршылыклы тормыш турындагы уйланулары һәм кичерешләре нәтиҗәсе буларак язылганнар. Аларда без язучының үзенә хас сыйфатларны да, аның карашларын, геройларына мөнәсәбәтен дә ачык тоябыз. Хәзер без өйрәнәчәк әсәр дә Галимҗан Ибраһимов иҗаты өчен бик хас булган сыйфатларны гәүдәләндерә, татар әдәбиятындагы иң гүзәл әсәрләрнең берсе булып санала.

КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР

(Әсәр кыскартып алынды)

«Кызыл чәчәкләр» хикәясе якты, азат көннәр өчен көрәш юлында һәлак булган иптәшләргә багышлана.

Автор

Башлангыч

(Кызыл орлыклар)

Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек.

Кем күтәрде? Кайчан? Ничек? Сезгә менә шул турыда сөйләп бирергә телим.

Мин яшь сабый идем әле.

Кайдан килеп, кайда баруы һичкемгә мәгълүм булмаган бер үткенче мөсафир[1] бабай бездә хәл җыярга туктаган вакытта үлеп калды. Ул бик карт иде. Бөтенләй ялгыз иде. Шуның өчен кызганып яшь түгүчесе дә булмады.

[1] Үткенче мөсафир — үтеп баручы юлчы, юлаучы.

Менә шушы бабай үләр алдыннан үзенә чакырды да миңа бер уч тутырып орлыклар бирде.

Болар — кызыллар иде, матурлар иде.

— Яз килгәч,— диде,— боларны чәчәрсең! Туфракларын йомшарта тор! Вакытында су сибәргә онытма! Өсләренә чүп-чар төшеп, кояш яктысыннан мәхрүм булмасыннар, яхшы кара! Әгәр мин кушканча эшләсәң, җәй көне кызыл чәчәкләрең булыр, көзгә матур кызыл орлыклар җыеп алырсың... Икенче елга тагын чәчәрсең, шулай итеп, бакчаң чәчәккә тулыр, синнән күрмәкче башкалар да шулай эшләрләр!

Мәрхүмнең сүзен тыңладым. Ләкин чәчкән орлыкларым өстенә үзем юкта тирес түккәннәр, нindидер бер явыз кара таш белән бастырып киткән — орлыкларым вакытында чыга алмый калганнар, кайберләре, томаланып, бөтенләй черегәннәр.

Моңа җаным бик әрнеде. Тиресне себереп түктем. Ташларны читкә алып ыргыттым. Җылы яңгырлар яуды, якты кояш карады, ни күрим: бер атнадан матур сабаклар, яшел яфраклар, җәй көне аллы-гөлле кызыл чәчәкләр бөтен бакчама ямь бирде; көз көне энҗе-мәрҗән бөртекләре кебек тигез, матур кызыл орлыклар җыеп алдым. Болар миннән бөтен авылга, бөтен тирәякка таралды.

Мин моны бөтенләй оныткан идем инде.

Тарихның яңа сафланган йомшак туфрагында үсеп килгән асыл ирләрне сөйли башлагач, ничектер, яңадан хәтеремә төштеләр.

I

Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә үзенең зурлыгы, йортларның төзеклеге белән кечерәк шәһәргә охшаплы бер авыл бар...

Диңгез сулары кебек зәңгәрләнеп уйный торган зур, матур күл буена утырганга, бу авылны «Зәңгәр Чишмә» дип атыйлар.

Зәңгәр Чишмәнең бакчаларында чәчәкләр адәм күзе карап туя алмас дәрәҗәдә куе төстә чибәр булып җитешәләр; болыннары елның-елында тирә-якны җәй көне яшел үлән белән, кышкы суыкта солыдан кадерле санала торган хуш исле коры печәннәр белән хәйран итәләр; өч яклап тезелгән таулары, катлау-катлау баскычланып, югары болытларга сузылалар: урманнарында меңәр еллык карт наратлар, чыршылар җәен-кышын яшәреп, шаулашып утыралар; елгалар, күлләр буеннан сөзәк сырт булып җәелеп киткән киң басулары шундый бәрәкәтлеләр ки, вакытында җылы яңгырлар яуса, кояшлы аяз көннәр булса, бу яланнарның мамык кебек йомшак, күзгә төн болытлары кебек куе кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр.

Авылның уртасында зур базар кайный: аның ике ягыннан биек матур сарайлар, зур тимер йозак белән бикләнә торган ак таш кибетләр тезелеп китәләр...

Боларга тоташып, бераз читкә таба урта хәлле кешеләрнең уртача зурлыктагы өйләре, уртача биналар үз дәрәҗәсенә күрә урын алалар.

Тагын бераз китсәгез, йортлар кечерәя, каралтылар, егылмасам ярар дип куркып, үзләренең иске черек терәкләренә таяна төшеп, һәр җилгә калтыранып, һәр яңгырны эченә алып, язмышның бөтен көчләре алдында ыңгырашып гомер итәләр. Иң ахыр барып, күпер башларында, басу капкасы буйларында чүплекләргә, тиресләргә салынган балчык өйләр, корымлы читән куышлар, үзләренең кайгылы йөзләре, сәләмә кыяфәтләре белән, каты җилләргә, көчле бураннарга каршы тора алудан өмет өзгән бер хәлдә дөнья кичерәләр...

Мин менә шул читтәге өйләрнең берсендә тудым.

Язмыш дулкыннары белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып үстеләр.

Арабыздан тик Шаһбазның гына кайда туганын белмиләр; минем бу газиз дустымның дөньяга килүе

анасының кабергә китүенә сәбәп булганга, атасының кем икәне һичберәүгә дә мәгълүм булмаганга, бу баланың гомереннән беренче сәгатьләрен һичбер өй үзенә алырга теләми. Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр.

Ни булса булган, Зөһрә апа бала тапкан да, үзе җан биргән.

Аның мәхәббәтенең җимеше үткен Шаһбаз үз гомерен чабата тукып, аркан ишеп үткәрә торган, ялгыз фәкыйрь бабасы Әхми карт кулына калган.

Күзге караңгы төннең нурлы йолдызлары Шаһбазны беренче мәртәбә менә шул картның авыл читендәге балчык өендә, агач сәкедә, юкәләр, мунчалалар арасында каршылыйлар. Ерак күк бу атасыз-анасыз баланың беренче шикаятьле[1] авазын менә шуннан ишетә.

Шаһбаз җиде яшькә җиткәч, чабатачы Әхми карт та үлә; шул зур авылда минем киләчәктәге дүрт дусымның берсе булган бу бала бөтенләй ятим, ялгыз кала.

VI

Атсыз гомер итү бик кыен иде. Әйбәт булды, безнең әткәй ат алды; кечкенә генә, ябык кына бернәрсә, быел гына сабанга кергән, ди.

Ат булгач, камыты, арбасы җиңел эш инде: әткәй, Ивановка русларына барып, берничә көн таш кисте дә кечкенә генә, җиңел генә камыт, ыңгырчак, дилбегә, дүрт тәгәрмәч, ике күчәр алып кайтты. Гыйрфан байдан башка вак-төяк кирәк-ярагын алып кайтты да җыйнак кына арба ясады.

Шулай итеп, без хәзер атлы-арбалы булдык.

Әткәй әйтә, син, ди, бераз эшли башласаң, яңа өй алырбыз да, ди, авылның уртасына таба, теге балта остасы Зарифлар янына күчәрбез, ди.

Их, тизрәк үсәсе, тизрәк әткәйгә эшләшәсе дә бу тирес оясыннан шул авыл уртасына, оста Зарифлар тирәсенә күчәсе иде!

---

[1] Шикаятьле — зарлы, ризасыз.

...Без әткәй белән, яңа атны, яңа арбаны җигеп, яланга ашлык карарга киттек. Җирән кашкага ашатырга печән чабып алып кайту өчен, чалгы да алдык.

Их, егет! Нәрсә бит, быел ашлыклар, карасаң, исең китә: шулай әллә кайдан әллә кая җәелеп, Зәңгәр Чишмә кебек, үзеннән-үзе дулкынланып утыралар иген басулары!

Басуны әйләндек, арба тутырып яшел печән төядек тә иң еракка — борчак җирләренә килеп чыктык.

Их, малай, борчагы нәрсә бит! Инде бөтенләй кузакланып беткән, сырга кебек сабакны сыгып утыралар. Санап карадым: кайбер кузакларда сигезәрдән ике рәт тезелгән. Күрше Сафа бабай әйтә, бер кузакта уналты борчак булса, ул инде бик уңган була, ди.

Озакламас өлгерер дә инде: урыны-урыны белән әле дә саргая башлаган.

Чү! Тукта!

Тегендә кемнәр ул безнең борчак эченә кереп ятканнар?

Әткәй нидер кычкырып калды, мин аңа карамастан чыбыркыны алдым да бар көчем белән шул безнең борчак эченә кереп яткан малайларга йөгердем.

Ни күрим?

Берсе — теге базарда минем белән сугышкан сары башлы, черек тешле, әйбәт киемле малай. Аның белән янәшә тагын берәү яткан — таза, нык, төптән юан үскән, сабыр гына бер ир бала. Өченчесен азрак таныйм. Бу — Гыйрфан бай мәхәлләсенең, Заһит хәзрәт улы Фазыйл мәгъзүм[1] бугай: чибәр генә киенгән, озынча йөзле, зур күгелҗем күзле, нечкә кара кашлы, минем чамалы бер малай.

Ачуымнан нәрсә әйтергә белмәдем:

— Ник безнең борчакны урлыйсыз? — дидем дә чыбыркы белән малайларга берәм-берәм селтәнә башладым.

---

[1] Мәгъзүм — мулла баласы, укымышлы.

Теге Фазыйл мәгъзүм акыллы күзләре белән миңа текәлеп карады да, ничектер, гаҗәп бер осталык белән чыбыркымны тотып алды, һаман шулай текәлеп карап:

— Солтан, син нигә һаман безгә бәйләнәсең?.. Беркөн тимерлек янында менә Гыйлаҗиның күзен чыгара яздың... Без сиңа тигәнебез юк бит! — диде.

Бу малайның күз карашы йөрәгемә төште, тавышы, акыллы сүзе бөтенләй хәлемне бетерде. Эчтән шулай җиңелсәм дә, тыштан һаман киреләндем:

— Ник бәйләнмәскә? Ник Шаһбазны рәнҗетәсез? Нигә безнең борчакны таптап, ашап йөрисез? — дидем.

Фазыйл, әллә нинди бер җирәнү белән:

— Харап булган икән! Имеш, борчакны ашыйсыз! Әнә янәшәдә безнең ике дисәтинә борчак ята: бик кирәк булса төя дә алып кайт! — диде дә капкан борчагын төкереп ташлады.

Безнең талашны эткәй ишеткән, ахрысы.

— Солтан, син нигә алай акылсызланасың?.. Кемнәр икәнен танымыйсыңмыни? Килегез барыгыз да монда! — дип кычкырды.

Бардык.

Фазыйл мәгъзүм атны мактады, сары башлы малай минем өстемнән тел сөйләде[1]:

— Без, ялан карап йөреп, сезнең борчак эченә хәл җыярга утырган идек, улың безгә бәйләнә,— ди.

Эткәй көлде:

— Солтан, син боларны танымыйсыңмыни? Нигә алай сугышып йөрисең? — диде. Сары башлы, әйбәт киемле малайга карап:

— Бусы Гыйрфан бай улы Гали була,— дип өстәде, аннан соң теге озын, аксыл йөзле, күгелҗем күзле, акыллы Фазыйл мәгъзүмне күрсәтеп:

— Бусын танымаска бер дә ярамый, бу — байлар мәхәлләсенең мулласы Заһит хәзрәт улы мәгъзүм Фазыйл... Ә менә бусы — оста Зариф бабаңның төпчеге,—

---

[1] Тел сөйләде — зарланды, әләкләде.

дип, таза, калын, сабыр малайга күрсәтте. Аннан соң барыбызны да кочагы белән борчак җиренә таба этәргәләп:

— Йә, барыгыз, юкка сугышып йөрмәгез, саргайганрак җиреннән борчак җыеп китерегез... Мин ут ягып куырырмын,— диде.

Без бергәләп киттек. Бергә борчак җыйдык. Шаярашаяра сөйләнеп, талашкалап алдык.

Гали һаман миңа бәйләнә, Шаһбазны сүгә:

— Солтан,— ди,— нәрсә шул уйнаштан туган хәерче малай өчен минем белән сугышып йөрисең? — ди.

Фазыйл мәгъзүм, безнең белән яшьтәш булса да, чыннан зурлар кебек акыллы сөйли. Минем кулдан тота да:

— Йә, Солтан, моннан соң безнең белән сугышмассың бит инде,— ди.

Теге Зариф оста малае Гыйлаҗи дәшмәде — җыйды да җыйды; дуңгыз нәрсә икән, без юкка суган сатып йөргәндә, ул менә дигән кипкәннәрен бер кәләпүш тутырып та өлгергән.

Арба янында төтен күренде, ул арада әткәй дә:

— Җитәр инде, кайтыгыз,— дип кычкырды.

Барсак, без бөтенләй хур булдык. Әткәй көлә:

— Сез, ахрысы, эчегезгә җыйгансыздыр. Менә Гыйлаҗи егет, ичмасам!.. Ул атасына охшаган: күп сөйләми, эшли дә эшли,— ди.

Борчак тиз куырылды, кәләпүшләргә тутырып алдык та арбага биек итеп төялгән яшел печән өстенә атланып утырдык.

Кайтыр юл түбән таба иде.

Җирән кашка, яшь булса да, көчле икән: шулчаклы печән белән биш кешене бертуктаусыз йөгертеп алып кайтты.

VIII

Без, бер авылда туып, бер суны эчеп үскән булсак та, төрлебез төрле урамнарда, төрле өйләрдә торгангамы, холыкларыбыз, һөнәрләребез бик төрлечә иде.

Фазыйлдан башка безнең компания әллә кайчан таралган булыр иде. Кайбер вакыт юк-бар өчен талашып китәбез. Бәргәләшеп алган чаклар да була. Менә мондый заманнарда Фазыйл әллә кайдан акыл таба, кызык сүз әйтә,— яңа уен чыгара да, әле биш минут элек кенә бугазга-бугаз килгән малайлар, гөрләшеп, кочакланышып, яңадан уйнарга тотыналар. Талашны, сугышны бөтенләй оныталар.

Мин бөтен компаниягә балык тотуларда, урманга, тауга җиләккә йөрүләрдә командир булдым. Минсез мондый эшләр башланмый, башласалар да, очлап чыгара алмыйлар.

Зариф карт улы Гыйлаҗи сугыш-талаш вакытларында безне коткара.

Без, үзара бик артык якынаеп киткәч, авыл малайлары өстеннән башлык кебек булдык. Теләсәк, язгы ат чаптыруларда, теләсәк, базарларда, теләсәк, башка уеннарда — без һаман үзебез теләгәнчә алып барабыз. Моңа башкаларның эчләре поша. Безнең дошманнар көннән-көн күбәя. Шуңа күрә, атна саен диярлек, бәрелешләр була. Менә мондый вакытларда Гыйлаҗи булмаса, без лачыннан качкан чәүкәләр кебек таркалабыз да бетәбез... Тик ул гына үзенең курку белмәс йөрәге, таза беләкләре белән безнең дошманнарыбызга каршы тора алуыбызга сәбәп була.

Аның өстенә тагы Гыйлаҗи бөтен авыл малайлары эчендә бердәнбер балта остасы санала. Яз килсә, ул безгә менә дигән көймәләр ясап бирә. Кошлар килеп җиткәндә, безнең һәркайсыбызның кечкенә өй кебек матур, җыйнак итеп ясалган сыерчык ояларыбыз әзерләнеп, биек киртәләр башына утыртып куелган була. Боларны да ул ясый.

Җиләк җитсә, кечкенә-кечкенә тубаллар, көз керсә, авылның бер башыннан икенче башына ишеттерерлек яңгыратып суга торган биек, текә какмалар — болар һәммәсе шул атасына охшап туган Гыйлаҗи кулыннан ясалып килә.

Галине әйтәсе дә юк. Нәрсә ясарга: агачмы, нечкә тактамы, калайлармы, кадакламы — һәммәсен Гали ташый. Акча дигәнең аңардан өзелми. Конфетлар, клиндерләр, прәннекләр белән аның үзенең тешләре череп беткән. Без дә болардан ара-тирә авыз итәргә кире тормыйбыз.

Шаһбаз иң соң килеп кушылса да, ул тиз арада безнең компаниянең үзәге булып алды.

Бер җиргә уенга барасымы, җиләккә, балыкка бару өчен җыярга кирәкме яки берәребезне кыйный башлаганнармы — янында Шаһбаз булса, бер дә аптырамыйсың! Ул, ике бармагын тешләренә куеп, берничә сызгырып җибәрә икән, безнекеләр хәзер сизеп алалар да, кайда, нинди эштә булса да, чабып килеп җитәләр. Әйтерсең әкияттәге җеннәр инде! Бу сызгыруда авылда гына түгел, тирә-якта да аның тиңдәше юк, диләр. Ул әллә ничә төрле сызгыра. Без инде аның сызгыруыннан нәрсә әйтергә теләгәнен тел белән сөйләп биргән, сүз белән кычкырган кебек аңлыйбыз...

Сугыш вакытларында да аның кирәк чаклары була.

Ул көчле түгел, ләкин бик үткен, бик хәйләле: кайбер вакытларда һич көтелмәгән җирдән килеп, берничәсен бәреп ега да, дошманнар хур булып качалар.

Йөгерүдә, суда йөзүдә дә аңа чыккан кеше юк.

Җырлауга, моңлануга, көлке сүз әйтеп башкаларны мыскыл итәргә туры килсә, ул инде дошманнарга гына түгел, безнең йөрәкләребезгә дә еш-еш агулы укларын кадый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрнең исеменә һәм башлам өлешенә игътибар итегез: «Кызыл чәчәкләр» һәм «Кызыл орлыклар». Бу төшенчәләр арасындагы бәйләнешне аңлатыгыз, кызыл төскә без, гомумән, нинди мәгънәләр салабыз?

2. «Башлангыч» бүлектә чынлап та тормышта булган вакыйга тасвирланганмы, әллә автор безгә нindидер чагыштырулар әзерләп куйганмы? Алдагы бүлекләрне укыганда кызыл чәчәкләр (һәм гомумән чәчәкләр), туфрак образлары белән

кабат очрашачакбыз, аларга нинди мәгънәләр салынган икәнлеген ачыклап, дәфтәрегезгә яза барыгыз.

3. Зәңгәр Чишмә авылының исеменә игътибар итегез. Ни өчен ике сүз дә баш хәреф белән язылган икән? Авылның табигате тормышта була алганча, ягъни реаль итеп тасвирланганмы? Шулкадәр арттыру, әкияттәгечә гүзәл итеп тасвирлау авторга нигә кирәк булган?

4. Авылның үз күренешен язучы нинди итеп тасвирлый? Бу өйләрдә яшәүчеләрдән иң башта кемнәр белән танышабыз?

5. Солтанның әтисе улының күңеленә нинди хыял орлыкларын салып куя?

6. Биш малай ничек дуслашып китәләр? Солтан аларны нинди итеп сурәтләп күрсәтә, нинди детальләрне басым ясап, кабатлап бара? Бу бер төркем малайларны кем һәм нинди сыйфатлар берләштереп тора, холыклары төрле булган малайлар ничек дуслашып китә алалар? Аларның дуслыгы сезгә ошыймы?

X

Шаһбаздан соң башкалар да берәм-берәм тарала башладылар.

Фазыйл мәгъзүм Казанга китә. Ул русча да, мөселманча да укый, ди. Аны мактап сөйлиләр. Галим булыр, зур кеше булыр, Зәңгәр Чишмә буен яктыртыр, диләр.

Җитмәсә тагы, Гали дә кышларда әллә кайларга китеп югала торган булды. Ул да укый, ди. Сату-алуга өйрәтә торган гыйлемлекләр артыннан йөри, имеш, ди.

Гыйлаҗи моны ишеткәч көлә:

— Анысы юк эш инде,— ди.— Акчаң булса, сату-алу эшен, укымыйча да, бик шәп йөртә белер идем әле,—ди.

Нәрсә сөйләп торырга?! Гали укыр өчен түгел, байлыкка, симезлеккә чыдаша алмаганнан гына йөри инде!

Моңарчы һичкая кузгалмаган Гыйлаҗи да аякланды.

Быел яңгыр аз яуды. Игендә өмет зур түгел, авылның байтак егетләре, эш бетәр-бетмәс, читкә кәсеп эзләп чыгып киттеләр. Безнең иптәш тә:

— Бер бәхет эзләп кайтыйм әле! — дип, шуларга иярде.

Зәңгәр Чишмә буенда мин ялгызак калдым.

XII

Ятсам да йоклый алмадым.

Таңнан торып, Зәңгәр Чишмәдән су китердем, арыш көлтәсе тападым, чоланнан көрпә алып чыктым да, улак тутырып, җирән кашкага бутап бирдем.

Әле өйдәгеләр тормаганнар.

Минем башымда һаман бер уй. Атай картаеп бара. Гомере шул тирес башында үтә. Мин инде җиткән егет булдым, менә берничә елдан патша хезмәтенә чакырырлар. Өч ел анда үтәр. Ул вакытта тагы ялгыз калалар. Тагы йорт-җир төзәтеп йөри алмаслар.

Юк, болай ярамый!

Бу эшләр миңа оят: мин хәзер атайдан шәбрәк таш кисәм, башкаларга селкенмәгән авыр ташлар минем кулда уйнап йөриләр. Егетләр арасында сугыш-ни булса, минем беләкләргә чыдаучылар сирәк чыга.

Юк, болай ярамый! Хәзергә үз көннәрен үзләре күрерләр. Мин китәм, бүген үк китәм дә алты почмаклы өй, кечерәк бер келәт алып, шуларны Зариф осталар янына күчерергә җитәрлек акча табып кайтам. Һәр ел бездә заводларга, шахталарга өчәр-дүртәр йөз минем кебек егетләр китәләр. Акча табалар, өс-баш ясыйлар, йорт-җир төзәтәләр, чәчәргә җирең җитмәгәч, чабарга тугаең булмагач, өстеңә капланырга торган урманнан бер чыбыркы сабы да ала алмагач, нәрсә дип монда гомер буенча Зәңгәр Чишмә саклап ятасың!

Иртәнге чәйгә утыргач, шул турыда сүз ачтым:

— Әткәй,— мин әйтәм,— алты почмаклы өй белән кечкенә бер келәт алып, шуларны теге Зариф осталар янына күчереп салу өчен күпме акча кирәк булыр? — дим.

Әткәй дә, әнкәй дә миңа аптырап карадылар. Әткәй бераз елмая:

— Нәрсә син, Солтан, берьюлы зурдан күтәрәсең? — ди.— Әле бу елга бүрәнәсен генә алып куярга көч җитсә дә, ару булыр иде! — ди.

Мин кырт кистем:

— Юк, мин әйтәм, әткәй, син ачык әйт: мин дигәнчә эшләгәндә күпме акча кирәк булыр? — дим.

Карт бераз уйланды:

— Йөз тәңкәсе табылса, эш башларга ярар иде,— ди.

Мин дога кылып тордым да киенергә тотындым:

— Сез, мин әйтәм, миңа фатиха бирегез, мин бүген үк чыгып китәм. Иң күбе миңа бер ел вакыт бирәсез, мин сезгә, санап, ике йөз сумны менә шул икмәк янына китереп куярмын,— дим.

Әнкәй куркып калды, йөзләре агарды, яшьле күзләре белән миңа кадалды:

— Чү, балакаем, ник ул чаклы ашыктың соң? — ди.

Мин ике сүзгә урын калдырмаслык итеп әйтәм:

— Миңа фатиха бирегез, мин бүген үк китәм... Бер ел дип әйткәнем — иң күп куеп әйтүем. Күңелем сизә: мин алты-җиде айдан кайтырмын... Хәзер сентябрь икән, язгы сабанга улыгыз сезнең каршыгызда булыр,— дим.— Әткәй, син берәр алты почмаклы өй белән кечкенә келәткә күз сала йөр... Теге Зариф оста янындагы буш урынны берәрсе эләктермәсен... Старостаны майлаштыра тор: мин аның белән былтыр сөйләшкән идем... Ярар, бер тутырган тавык белән бер бөтен кызыл башны кызганмасаң, урын синеке булыр, дигән иде,— дим.

Әткәй миңа туры карады, аның күзләрендә: «Бу бала акылдан шашмыйммы?» — дигән бер сорау бар иде.

— Солтан, син чынлап ук бүген китәсеңме? — ди.

— Китәм, әткәй, китәм. Сезне бу тирес башында үтерәсем килми. Үземә дә типсә таш ярырдай егет булып, бу чүплектә сасып яту хурлык! — дим.

Риза булдылар. Ләкин икесендә дә ниндидер эчке бер өмет катнаш курку сизелә иде.

Былтыр «Восьмой прииска» дигән шахтага авылдан өч йөз егет киткән вакытта, мин дә дәртләнеп куйган

идем. Шулвакыт алынган еллык билетым да сандык төбендә яткан икән. Әнкәй ашыгып күлмәкләремне юды, ямады, кечкенә капчык ясады, өй башыннан бер пар яңа чабата алып төште, миңа юлга дип, азрак ит, азрак бәрәңге пешерде. Шуларның шулпасын ашадык, чәй эчтек. Киендем. Утырып дога кылдык, хушлаштык. Мин, кечкенә капчыкны аркага асып, ялгызым Урал тауларына карап, сәфәргә чыктым.

Алты ай эшләдем. Җиденчегә киткәндә минем эчке күлмәгемнең култык астында кечкенә бөти кебек әйбәтләп тегелгән йөзәр сумлык ике кәгазь һәрвакыт тәнемне кытыклап рәхәтләндерә иде.

Моның өчен ниләр генә күрмәдем, кайларда гына булмадым.

Башта «Восьмой» дигәннәрендә эшләдем. Хезмәт каты, хак начар, эш вакыты хәлләреңне бетереп аяктан егарлык озын иде. Түздем. Дөньяның рәтенә бераз төшеним, башка җирдән табышлы кәсеп эзләргә җитәрлек акча ясыйм дип түздем.

Аннан соң, болардан китеп, бер француз компаниясенең шахтасына ялландым.

Сүземдә тордым. Тартмадым, эчмәдем, картага якын бармадым...

Тагын берничә атналар эшләгәч, ике йөз тәңкәне тутырып, аның өстәвенә юллык, өйгә вак-төяк бүләклек тә арттырдым.

Вак акчаларны бөтен ике йөзәрлеккә алмаштырып, йөрәк өстенә бөти ясап тектем дә, Уралның тирән шахталары белән бәхилләшеп, Зәңгәр Чишмә ягына таба юл тоттым...

Яңгырлы-болытлы көз, аның артыннан карлы-буранлы каты кыш үткән: минем баштан әллә ничаклы хәлләр кичкән, ләкин Зәңгәр Чишмә аз гына да үзгәрмәгән.

Ул һаман да элеккечә зур, мәһабәт булып, әллә кайдан җәелеп, һаман элеккечә матур кояш нурлары белән уйнап яши икән әле.

XXI

Сиксән биш сумга югары оч Галәвинең алты почмаклы өен алдык. Үзе ике генә ел торган. Бүрәнәләре яңалар, корылар. Ишек, тәрәзә, идән, түшәм — бары да бик бөтен.

Тик, бераз биегрәк булсын өчен, нигезгә берәр бүрәнә салырга туры киләчәк.

Утыз сумга Садыйк байның бер келәтен алдык. Зур гына, иркен генә. Өсәкләре дә бик яхшы икән. Булгач-булгач, ак келәт булсын дип, моңа кечерәк кенә бер тәрәзә дә куйдырырга исәплим.

Әткәйнең көздән чыгарып калдырган ташы бар икән. Алты сажин, ди.

Насыйп булса, өйнең дә, келәтнең дә астына тирән итеп нигез салырбыз, юкса су китеп чери, фәлән итә башлый.

Өй кузгаткач, аның кирәге күп була икән. Кыегы, ишегалды, тагы әллә нәрсәләре өчен егерме тәңкәлек төрле бүрәнәләр, киртәләр, такталар алдык...

Иптәшләр: «Үзең маташсаң, озакка китәр, әйдә өмә ит!» — диделәр. Әткәй дә риза булды.

Өйне, келәтне, таудагы ташны да өмә белән ташыдык.

Икенче көнне күрше-күләнне җыеп, өмә сымаграк ясап, өйне мүкләп күтәрдек. Бусына инде Зариф оста берничә сәгатькә кайтып үзе дә булышты... Яңа күрше Гайнияләр аш-су белән ярдәм иттеләр.

Берничә көннән мич тә өлгерде.

Шулай итеп, бер атна дигәндә, без бу яңа урынга, яңа өйгә бөтенләй торырга да күчтек — күпер башындагы чүплектән мәңгегә-мәңгегә котылдык.

Сораулар һәм биремнәр

1. Дуслар Зәңгәр Чишмәдән ни өчен тарала башлыйлар, алар кайларга китәләр? Бу таралу аларның дуслыкларына бәйләнгәнме әллә башка сәбәпләр бармы?

2. Солтан үзалдына нинди максат куя? Аның сәяхәте ни белән тәмамлана? Ул хыялын тормышка ашыра аламы, аңа кемнәр ярдәм итә?

3. «Фатиха» дигән сүзнең мәгънәсен аңлатыгыз. Аны нинди очракларда кулланалар? Бүген дә ул сүз урынлымы, кирәклеме? Ни өчен? Бу турыда әти-әниләрегез, әби-бабайларыгыз белән дә сөйләшегез.

XXXI

...Игеннәр, безнең бәхеткә каршы, искиткеч дәрәҗәдә шәп булып җиткәннәр.

Халык шат иде. Һәркем быелгы иген белән үзенең тереклеген төзәтеп калырга өмет итә. Бурычлылар бурычларын түләргә, атсызлар ат алырга, өйсезләр өй салырга, улы җиткәннәр килен алырга, кызы җиткәннәр кыз биреп туй ясарга,— һәркем шулай бу байлыктан үзенең дөньясын рәтләп калырга уйлый.

Шундый дәртләр, шундый уйлар белән һәркем, бил баглап, җиң сызганып, изү чишеп, уракка төште...

Шундый өметләр, шундый уйлар белән янып, рәхәтләнеп, шатланып, шаулашып эшләп йөргән заманда, көпә-көндез һәммә халык яланда уракта чакта, патшадан фәрман килеп төшә:

— Герман белән сугыш!

— Һәммә ир җаны коралланырга, фронтка китәргә тиеш!

Аяз көндә, димәк, һич көтмәгәндә яшен сугу ничек тәэсир итсә, патшаның бу фәрманы аңардан яманрак булды.

Халык аптырый кала. Картлар бөтенләй шашалар:

— Бу ни эш бу?

— Патша хәзрәтләре безнең хәлне белмиме икәнни?

— Аңа әйтәсе иде: бераз кичектер, иген-таруны җыйыйк, аннан соң да сугышка өлгерерсең! — диясе иде.

— Юк шул, аның тирәсен әллә нинди боярлар чолгап алганнар. Болар дөрес хәлне сөйләмиләр булыр!

— Патша хәзрәтләре бездән ерак... Безнең сүзләр, безнең хәлләр аңа барып ирешә алмый! — диешәләр.

XXXIII

Ашыктырып куалар. Бүген кич калага барып җитәргә, ди. Аннан иртәгә таңда ук каядыр еракка озатачаклар, ди. Кая булсын, сугыш авызына, кан, үлем эченәдер инде!

Хәерле булсын! Ни язган булса, шуны күрербез!

Сугышка алалар, үлемгә куалар дип, хатын-кыз шикелле елап торып булмый инде.

Куалар — барасың!

Сугышка кертеп, туп авызына куялар,— үләсең!

—...Хуш, эткәй-энкәй! Картайган көнегездә сезне хөрмәт итә алмадым — бәхил булыгыз, рәнҗемәгез, бу эшләр миннән түгел бит!

Таңнан ук олаулар әзерләнгәннәр. Старосталар өйдән өйгә кереп куып йөриләр.

Бөтен авыл кайный, чабалар, йөгерәләр, кычкырышалар, елыйлар, елыйлар, елыйлар!..

Нindидер бер бәйрәм,— кайгылы бәйрәм, кара, бик кара бәйрәм!

Кәрван-кәрван булып, Зәңгәр Чишмәнең уртасыннан — байлар мәчете яныннан басу капкасына чаклы тезелгән арбалар безне алып китәргә әзер торалар.

Бала-чага гөж килә. Әткәй минем арба яныннан үзенең актык сүзләрен әйтә-әйтә бара... Аның йөзендә тирән кайгы җыерчыклары күбәйгән, чәч-сакалы бу көннәрдә агарып бетә язган.

— Сау бул, балам, шатлыклы хәбәрләреңне ишетик,— ди. Әнкәй елап, һушыннан язган кебек, капка баганасына сөялеп катып калды.

Башкалар да күрешәләр, бәхилләшәләр, елыйлар,— бөтен авыл шулай гөж килә, шаулый, кайгы белән шаулый; бөтен кешеләр, бөтен өйләр өстеннән әйтерсең кара сөрем күтәрелә...

Атлар кузгалды...

Кемдер, егетләрдән берсе, гармун тартып җибәрде, кемнәрдер бераз исерек, шулай да матур, моңлы, кайгылы тавыш белән озын көйгә сузды:

Сандугачлар килгән безгә,
Китмәсләр микән күзгә?
Язгы Сабантуйларына
Кайтырбыз микән без дә?

Бу кайгылы аваз ничектер йөрәк тамырларына төшә, арка-үзәкләрдән, аяк буыннарыннан йөреп, күңелгә җыелып тулып килә дә күзләргә яшь китерә...

Сау бул, Агыйдел буйлары, сау бул, Зәңгәр Чишмә!..

XXXIV

Шаһбаз, Гыйлаҗи, Фазыйл, Гали һәм мин — без барыбыз яшьтәшләр дип йөри идек. Әнкәйләр дә безне бер елгы балалар дип әйтәләр иде, без үзебез дә бер елда каралабыз, бергә солдатка китәбез, бергә-бергә патшага хезмәт итәбез, аннан соң бергә-бергә өйләнәбез, туй ясыйбыз дип уйлый, шулай сөйләшә идек.

Ничектер, башкачарак булып чыкты.

Шаһбаз Зәңгәр Чишмәгә кайтмады — ул үзенең эшләгән җирендә каралган да шуннан ук сугышка киткән... Фазыйл да Казанда иде. Авылга күренмәде, шунда каралып алынганмы, ничектер, Мәскәүгә барган да лашманчыларга башлык сыман булып урынга кергән. Ул да үзенең Мәскәүдәге дуслары, байлары аркасында шунда барып сыенган, ди. Аның бу эше күңелемә бер дә, бер дә ошамады! Әллә кайдан китерелгән бичара колларны, чыбыркы тотып, кара, пычрак хезмәткә куып, шуңа башлык булган булып йөрү егетлекмени ул! Алай иткәнче, үзең солдат бул, үзең сугышка кит тә үз язмышыңны үзең күр!

Әдрисен белсәм, берсеннән бик оста хат яздырып, бик нык шелтәлим әле Фазыйлны!

Әйтермен: без кара кеше, надан кеше, шулай булсак та, бөтенләй җүләр түгел: яхшы-яманны аера беләбез, диярмен. Ул бичараларны изеп, кол кебек куып йөрергәялланып, лашманчы булу синең кебек зур укыган, тирәякның йолдызы булган бер кешегә килешә торган эш түгел, диярмен...

Гали дә чарасын тапты.

Байларга нәрсә? Акча күп, танышлык зур. Алтын булгач докторын да... патшасын да сатып алып була икән шул: ике мең тотканнар, диләр... Бәлки, артыграк та булыр — күпме чыкса чыккандыр, Гали шәһәргә барып каралды,— ахрысы, бөтенләйгә котылды...

Шулай итеп, безнең Галигә бәхет ачылды: сугыштан да калды, үзенең күптәнге уйларына да барып җитте: шәһәргә күчеп, анда беренче кеше булды.

Шаһбаз бер хат яздырган иде. Ул анда: «Дөньяны җимерәбез, малай, хәзер чит патша җирләрендә йөрибез. Карпат дигән тау бар икән... безнең Урал моның янында бала гына... Без хәзер менә шул карлы тауны кичеп төшеп барабыз...» — дигән иде...

Шуннан соң хәбәре юк...

Ни хәл булгандыр, бик озакка мәгълүм булмады.

Без Гыйлаҗи белән бергә алындык, бергә уйнадык. Бергә фронтка киттек.

Башкалар аяк-кул бозалар, күзгә, колакка агу салалар. Без моңа якын бармадык. Үлсәм үләрмен, үз кулым белән үземне гарип ясап, имгәтеп маташыр хәлем юк. Ни язган, шул булыр...

Гыйлаҗи да минем кебек, бозуга каршы булса да, ул, никтер, казармадан казармага, фронттан фронтка куылып йөрүне яратмый иде.

Баштан ук күңеленә утыртып куйды:

— Мин,— ди,— Ярманга пленга китәм... Анда дөнья күрәм, эшкә өйрәнәм,— ди.

Эт нәрсә икән! Сүзендә торды, тугыз ай хәбәрсез гаиб булып[1] йөргәннән соң, Ярманның зур бер шәһәреннән хат килде: мин исән-сау, ди; сохари җибәрегез, ди; үзем балта эшенә керештем, ди.

Мин үзем Польша дигән җирдә, әллә нинди сазлыкларда салкын окопта ятам.

---

[1] Гаиб булып — юк булып, күзгә күренмичә.

Шулай Агыйдел буенда бергә уйнап, бергә үскән егетләр җир йөзенең әллә кай якларына таралдык та беттек...

Аннан соңгы елларда дөнья кайнады, моңарчы гел бертөсле генә, тыныч кына агып торган тормыш диңгез кебек дулкынлана башлады. Бу дулкыннар, бу өермәләр эчендә еллар үтте, хәлләр үзгәрде, мәңгелек дуслыкта кырыгар мәртәбә ант итешкән безнең иптәшләр үзләре генә таралып калмадылар, күңелләре дә үзгәрде, юллары шулчаклы бер-беренә каршыла́нды, без бер-беребезнең бугазларыбызга килеп сарылыштык. Бер-беребезнең күкрәкләренә мылтык төзәп атышу дәрәҗәсенә җитештек. Араларда упкыннар ясалды.

XXXV

Петроград. Зур хастаханәләрнең[1] берсе. Киң, биек тәрәзәләрдән язгы кояш яктысы безнең залга агылып тора. Паркетлы идәннәрдә, майлы буяулы диварда аның нурлары уйныйлар. Безнең залның ак, пакь караватларында авыру солдатлар буй-буй тезелеп ятканнар. Баштанаяк ак киенгән кызлар ара-тирә кереп чыгалар...

Болар матурлар, әйбәтләр, йомшак күңеллеләр: иркәләп сүз кушалар, ни әйтсәң дә, минуты белән эшләргә тырышалар. Чирлеләр өчен тынычсызлык булмасын диптер инде, акрын сөйлиләр, кергән-чыкканда аяк очлары белән генә басып йөриләр...

...Көннәрме, айлармы, атналармы үткәндер, мин менә шул һәйбәт хастаханәнең ак залында каты авыруларның газаплы ыңгырашулары эчендә уянып китәм...

Ләкин һаман ышана алмыйм...

Бу төшме?.. Саташумы?.. Әллә мин чыннан да Гатчинода контрларга каршы сугышканда каты яраланганмынмы?

XXXVI

Кемдер, аяк очы белән генә басып, яныма килгән кебек булды.

---

[1] Хастаханә — дәвалау йорты, больница.

Күземне ачсам, безнең палатаның докторы Анна Федоровна каршымда тора.

— Хәлең ничек? — ди...

...Кулымны карады, култык астына градусник куйды, ридикюленнән кечкенә бер записка чыгарды.

— Синең авылдашың булса кирәк,— ди.— Шаһбаз Фәхриев дигән бер бик үткен командир бер атнадан бирле һәр көн килә дә керергә талаша. Хәлең авыр булганга кертмәдек, менә бүген ул миңа записка калдырган. Укып бирегез, дигән,— ди.

Кай арада укырга-язарга өйрәнгән бу егет — мин бераз гаҗәпсенәм.

Доктор укып бирде: «Дускай, Солтан, ун көн инде иртә-кич синең лазаретны таптыйм. Кертмиләр. Хушына килде дигәч, бүген сиңа записка калдырам. Без тиздән фронтка китәбез. Шуңарчы ничек кенә булса да сине күрәсе иде. Бик сагындым! Зәңгәр Чишмә — Агыйдел буйларын бер сөйләшеп утырыр идек.

Шаһбаз, 1918, март».

Белмим, шатландым, белмим, нәрсәгәдер тагы җаным әрни иде, нидер булды, култык астымдагы яра чәнчеп-чәнчеп ала башлады. Бу чәнчү күкрәгемә, кулбашларыма менде. Аннан соң бөтен тамырларым буенча билемә, аякларыма төште — тагы хәлсезләндем, тагы артыграк өзелдем... Бу газап белән тагын арып, йоклапмы, онытылыпмы киттем...

XXXVII

Адәм җаны — эт җаны, диләр. Бик дөрес сүз.

Дөньяның җәһәннәмнәрен кичтем. Герман штыкларыннан яраландым. Керенский, Краснов казачийларының, Петроград юнкерларының бомбаларыннан газапландым... Өч мәртәбә ярдылар...

Мин һаман тере. Мин тагы аякта.

Рәхмәт инде докторларга да: яшермәделәр, куркыныч зур, диделәр; теләмәсәң, көчләмибез, диделәр;

ярдырмасаң, барыбер рәхәтләнеп йөри алмассың, диделәр.

— Ни булса, шул булыр... Казачий пулясын йөрәк астында асрар хәлем юк! Гомер буенча елап-сыкрап яшәгәнче, гарип-имгәк булып кеше күзенә карап көн иткәнче, үлгәнең мең мәртәбә артык! Йә, үтерегез, йә, мине яңадан адәм ясагыз,— дидем.

Ярганнан соң өч ай вакыт үтмәде, мин акрынлап йөри башладым.

Докторлар әйтәләр: шулай даруланып, тыныч кына ятсаң, язгы Сабантуйларына чаклы элекке кебек таза егет булырсың, диләр. Болар мине никтер яраталар, күңелемне күтәрергә тырышалар, шаярталар. Шундый күңелле сүзләр, матур өметләр белән үзалдыма шатланып, яңа дөньяга килгән бала кебек, башымдагы хыялларга, тәрәзәдән төшкән кояш нурларының паркетлы идәннәрдә, шома диварларда, түшәмнәрдә уйнавына сокланып, рәхәт кенә ята идем, кемдер тиз-тиз безнең палатага килде, ишекне ачып туктады да:

— Солтан Уразбаев иптәш бу палатада булса кирәк, аның ятагы кайда икән? — дип, бераз ватып, шулай да җиңел русча тел белән сорады.

Төрле яктан авырулар, баш күтәреп:

— Солтан, синең якташ килгән, тор! — диярга өлгерә алмадылар, мин, атылып барып, дустым Шаһбазны кочакладым.

Их, дөнья! Адәм бу чаклы үзгәрсә үзгәрә икән!

Әгәр юлда очрасам иде, каршымдагы кызыл фуражкалы, шпорлы, яхшы френчлы, баштанаяк кораллы, йөзе әллә ничә җирдән яралы бу егетне минем Зәңгәр Чишмәдәге дустым Шаһбаздыр дип, ялгыш та уйлый алмас идем.

Шатлыгым башыма сыймый. Иптәшне биленнән кочаклап алам да ятагым янына урындыкка китереп утыртам. Үзем аңа каршы утырам.

Ашыгып исәнлек-саулык турында сөйлибез. Мин күземне аңардан ала алмыйм.

Безнең күрешмәгәнгә дүрт ел үткән иде. Шул заман эчендә егетем камил ир булып, чыныгып җитешкән, йөзендә акыл төсе арткан. Күзләрендә әллә ничаклы көрәш, әллә ничаклы гайрәт ялтырый...

...Без иркенләп сүзгә керештек.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сугыш башлану хәбәре Зәңгәр Чишмәдәге тормышны ничек үзгәртеп җибәрә, нинди хыяллар җимерелә? Кешеләрнең кичерешләре ничек тасвирланган?

2. Биш егетнең язмышлары нинди юллардан китә? Алар арасындагы характер төрлелегенең тигезсезлеккә, гаделсезлеккә әйләнгәнен ничек аңлатып була?

3. Сугышта яраланган Солтанның госпитальдәге хәле, аның Шаһбаз белән очрашуы турында сөйләгез.

4. Шаһбаз ничек үзгәргән? Ул үзгәреш аның бала чагындагы сыйфатларына туры киләме?

XXXVIII

Барыннан да бигрәк Гыйлаҗи хакындагы хикәя миңа кызык тоелды.

Иптәшем үзе дә аны көлке итеп сөйли. Миңа бигрәк тә күңелле булып чыкты.

— Германия тубыннан сындырылган кулын төзәтеп, авылда ята идем, дип әйтеп әйтә, ди, бер базар көн, дип әйтә, ди, телеграм алынды. Бөтен тирә-як шау күтәрде... Патша төшкән, имеш, сугыш бетә, имеш, байлар, боярлар кулындагы барлык җирләрне крестьянга бирәләр, имеш, диделәр. Халыкны волость конторына җыеп алып бардым да бунт күтәрдем... Урядникны, канга батырганчы изеп, салкын бүлмәгә яптым... Старшинаны, эт итеп кыйнап, урыныннан төшердем. Николайның сурәтен алып, тәрәзәдән ыргыттым да малайларга таптарга, ерткалап, таратып атарга бирдем.

Аннан соң, дип әйтеп әйтә, ди Гыйлаҗи, ни барын, ни булачагын аңлар өчен, калага киттем, дип әйтә, ди.

Шәһәр гөж килә. Губернаторлар, исправниклар бары да очкан! Кайсы ябылган, кайбере качкан, ди.

Казармага барып керсәм, дөньяның асты өскә килеп бара.

Элек борынын күккә күтәреп йөргән офицерлар хәзер шым булганнар. Элекке кебек аяк тибеп кычкыруларның исе дә калмаган. Алар хәзер безнең солдатка да, ничектер, кыенсынып, оялыбрак булса да, «әфәнде» дип, «господин» дип эндәшәләр. Ә, шулаймы, дим, хәзер без дә господамы, дим. Җитәр, мин әйтәм, сез бик күп заманнар үзегез генә әфәнде булып йөрдегез, дип әйттем, дип әйтә, ди.

XXXIX

Озаклап сөйләшергә вакыт юк иде. Аерым-аерым сораша бардым.

— Гыйлаҗи шуннан соң ни эшләгән?

Шаһбаз яңадан көлде:

— Ул бит зирәк егет. Тиз аңлаган. Монда безнең Петроградта эшләрнең үзгәрүен көтмичә үк, тирә-як крестьяннарын җыеп барган да боярларның җирләрен сөреп чәчкән... Өйләрен мәктәпләргә, фәкыйрьләргә өләшкән. Шунда безнең Галиләрнең дә мең дисәтинәгә якын җирләре киткән бугай...

— Хәзер ни эшли Гыйлаҗи?

— Эш безнең кулга күчкәч, аны тотканнар да, көчләп, безнең өязгә җир комиссары ясаганнар.

— Әйттем, дип әйтә, ди: мин ул эшләрне булдыра алмам... Мин җүнләп кул да куя алмыйм бит, дип әйттем, ди.

— Юк, дип әйтәләр, диде, ди, без сиңа доклад хәзерләтергә, кирәгеңне язарга галим урыслар бирәбез. Кул куя белмәсәң, тамга салырсың, дип әйттеләр, дип әйтә, ди.

— Ярар, дип әйттем, ди, боярларның тамырын корытканчы, мин комиссар булам. Аннан соң комиссар-

лыктан мине коткарырсыз да зур йортлар, зур күперләр салу эшенә җибәрерсез, дип әйттем, ди.

Риза булдылар, ди.

Шаһбаз сүз арасында Гали белән Фазыйлны телгә алса да, ничектер, аларга чәнчеп үткән иде. Бу дуслар хакында сүз кузгаткач, аның кашы җыерылды.

— Нәрсә булсын, иптәш! Акрынлап асылларына кайталар. Гали ачыктан-ачык байларны безгә каршы оештыра, ди. Дутовка[1] яшертен акча җыя, имеш, диләр...

— Фазыйл?

— Ул да калышмаска тырыша бугай — әллә нинди оешмалар корып, төрек-татар байрагы дип, дин, милләт өчен бергә барыйк, аерылмыйк дип лаф ора, шулай дип гәзит яза, съездларда кычкыра бугай... Әмма эшләгән эше бөтенләй байлар файдасына таба бара, ди.

— Менә ничек, ди, безнең губернада Учредилка[2] вакытында ике список чыккан. Берсе халыкныкы — ...нче номер, берсе байларныкы — ...нче номер. Болар арасында зур талаш булган, урыны-урыны белән сугышка да җиткәләгәннәр бугай... Галиләр, Фазыйллар, кара мөфтиләр бары да байларныкы —...нче номерны яклаганнар. Безнең Гыйлаҗилар бары да —...нче номер ягында булганнар.

— Кем җиңгән икән?

— Билгеле, кем җиңгән: Фазыйллар — бер кеше, Гыйлаҗилар өчме-бишме кеше үткәргәннәр.

Шаһбазның Гыйлаҗи хакындагы хикәясе шул җиргә җиткәч, нәүбәтче кыз яңадан керде:

— Тиздән докторлар керә. Сез чыгыгыз инде! — ди.

Без карышмадык, өстемә аксыл-соры халатны салдым, аякка йомшак башмакны кидем дә, коридор башына кадәр озатыйм дип, Шаһбаз белән мин дә чыктым.

---

[1] Дутов — аклар армиясенең генералы.

[2] Учредилка — гражданнар сугышы вакытында оештырылган идарә итү комитеты.

XL

Мин көрәшне яратам.

Көрәшсез үткән көннәрне әрәм саныйм. Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала, гайрәт ала.

Авылда бер ай тыныч кына хәл җыйсам, камил тазарып җитәрмен дә, яңадан шул канлы көрәш өермәләре мине үз эчләренә тартып алырлар дип, Идел ярына басар-басмас, үз алдыма уйлап куйган идем.

Ай түгел, атна түгел, бер көн, бер сәгать көтәргә дә ирек бирмәделәр.

Мин Зәңгәр Чишмәгә җәяүләп, аркама әйберләремне асып килеп кергәндә, кояш батып бара иде инде.

Күперне чыккач та, ниндидер зур гаууга, шау-шу ишеттем.

Кемнәрдер кычкыралар, талашалар, кемнәрдер елыйлармы, үзләрен үзләре яклап әрләшәләрме,— белмим, нидер бар, нидер кузгалган, нидер дулкынлана.

Түбән оч тыкрыкларын үттем. Базар мәхәлләсенә, байлар урамына якынлашып барам.

Алдымда, минем юлыма буе белән, безнең Гыйлаҗи дуслар эшләгән зур мәчет утыра. Зәңгәр Чишмә күле ягыннан килгән шәфәкъ кызыллыгы фарыз бүлмәсенең тәрәзәләренә төшкән, ерактан ут кебек кызарып яналар. Алда тавыш көчәйгәннән-көчәя бара.

Чү! Бу ни эш?

Кемдер, нәрсәдер рәттән өч мәртәбә атып җибәрде.

Моны ишетүгә кулларым кобурама[1] сузылды.

«Наганым исәнме икән, урынындамы икән?» — дип капшап карадым.

Бу миңа кадерле нәрсә: бер казачий батальонны аз көч белән юкка чыгарган өчен, командир иптәшнең фәрманы буенча бүләк иткәннәр иде. Егермегә якын пулясы бар.

---

[1] Кобура — наган яки револьвер салып йөртелә торган күннән ясалган чехол, кап.

Эшләве гаҗәп дәрәҗәдә яхшы. Иске режим вакытында төз ату өчен медаль алган кулларымда бу наган булса, бернәрсәдән дә курыкмаска мөмкин.

Шул уйлар белән алга барам.

Күңелемә кинәт бернәрсә килде: тукта әле, кайдадыр юлда, пароходтамы, берәр станциядәме, чех дип, словак дип, нидер лыгырдаганнар иде түгелме соң?.. Йөз мең кеше, имеш, баштанаяк кораллылар, имеш, Самараны алганнармы, алалармы, имеш, аннан башка калаларга китәләр, имеш... Белмим, тагы шундый имеш-мимешләр сөйләгәннәр иде...

Мин:

— Без андыйларны күп күрдек инде! — дип кенә куйган, ул турыда бер дә уйлап тормый үткән идем.

Мин пароходлардан урап кайтканчы, әллә шундый бер этләр тагы безнең кәрванга өрә башлаганнармы? Каным кыза, йөрәгем суга, аякларым үзләреннән-үзләре ашыгалар.

Бу чатта миңа өй ягына — уңга китәргә тиеш иде. Уйлап-нитеп тормадым, сулга борылдым да базар мәйданы ягына киттем.

Мәчетне, Гыйрфан байның зур таш кибетләрен үтсәм, бөтенләй шаша калдым. Көтелмәгән, уйга килмәгән, килми торган бер күренеш!

Базарның уртасында печән үлчи торган баганаларга берничә кеше аякларыннан югары асылганнар. Боларның берсе безнең авылда дүрт ел буе балалар укыткан мөгаллимә Хәдичә иде. Болар тереләрдерме, үлеләрдерме, белеп булмый. Куллары салынып төшкән, йөзләре адәм карагысыз булып яраланган... Кан тамчылары җиргә тамалар... Бу асылганнар тирәсе кара болыт кебек, туфан кебек халык көтүе белән кайный. Кычкыралар... талашалар... Нәрсәдер берсеннән-берсе тарткалап алырга тырышалар... Белмим, һәммәсе акылдан шашкан, белмим, кыямәт булган: кешеләр ни эшләгәннәрен белмиләр, күзләрен кан баскан. Ниндидер бер көч белән әле бер якка, әле икенче якка кузгалып, шау-шу

белән, гауга белән дулкынланалар. Боларның башында зур бер командир кебек безнең Гали йөри. Аның да күзләре канлы, тавышы карлыккан, үзе анда йөгерә, монда йөгерә, шул бозык гырылдавыклы тавышы белән бертуктаусыз акырына:

— Җәмагать, көткән көннәрегез килеп җитте. Сез котыласыз... Форсатны качырмагыз...

Аптырап Галинең өстенә карадым, башында офицер фуражкасы, аякта шпорлы ялтыр итек, беләктә ак тасма, кулында менә дигән маузер!

Үземне үзем белмәдем:

— Гали, синме? Бу ни эш? — дип кычкырып, аңа барып тотындым.

Халык тынды, минем билдәге наганны күргәч, бераз куркып икегә аерылдылар.

Ләкин Гали үзен үзе югалтмады, канлы күзләре белән миңа бер генә мәртәбә карады да, бераз кире чигенеп, әллә нинди зәһәрле, каһәрле тавыш белән:

— Ә... алаймы? Асыл кош үзе килеп аягыннан эләктеме? Җәмагать, менә сезгә Солтан Уразбаев!.. Дөньяны туздыручыларның иң яманнарыннан берсе! Тотыгыз да бәйләгез моны! — дип кычкырды.

Үземне үзем сизмәстән, наганымны суырып алдым да:

— Кем миңа кагыла?..— дип, рәттән дүрт мәртәбә як якка аттым.

Халык, лачыннан качкан чәүкә көтүе кебек куркышып, читкә таралды. Урталыктагы ачыклыкка карасам, ниндидер гәүдә ыңгырашып ята. Йөрәгемне нидер чәнечте, таныш кебек булды, дөньяны онытып, шул ыңгырашкан гәүдәгә ташландым.

Ни күрим?

— Су, бер генә тамчы су! — дип, чак-чак ишетерлек бер тавыш белән саташып, ыңгырашып, минем дустым Гыйлаҗи ята.

Күтәреп алыйм дип иелсәм, муеныма аркан салдылар. Шунда ук кул-аягымны бәйләргә азаплана башладылар.

Кайдандыр безнең күпер башында торган чактагы күрше Сафа бабай килеп чыкты да мине якларга теләде:

— Җәмәгать, моның ни гөнаһысы бар? Бу бит ата-анасын күрергә кунакка кайтып килә,— диде.

Ул арада Гыйлаҗиның атасы Зариф оста белән минем әткәй килеп чыктылар. Шау-шу яңадан күтәрелде. Шаһбазның агасы, аның артыннан башка вакытта җыеннарда сирәк күренә торган безнең иске күршеләр, авылның читләрендә, балчык читән өйләрдә яшәүчеләр, атасыннан, төп йорттан куылып чыгып, читләрдә өйдәш торучылар телгә килделәр:

— Көпә-көндез адәм үтерәсез!

— Бу ни эш!.. Чех дип, ул чаклы масаймагыз!..

— Безнең очта да яңадан бәйрәм булыр әле! — дип кычкыра-кычкыра, мине коткардылар.

Гыйлаҗины, аркылы агачка салып, өенә алып киттеләр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шаһбаз Солтанга нинди хәбәрләр сөйли? Бу вакыйгалар егетләрнең бала чагын тасвирлагандагы кебек җентекләп сурәтләнәме әллә хәбәр итеп, әйтеп кенә кителәме? Автор ни өчен бу соңгы бүлекләрдә өзеп-өзеп, ашыгыбрак сөйли башлый икән?

2. Шаһбаз белән очрашу, ул сөйләгән хәбәрләр Солтанда нинди кичерешләр кузгата? Дусларына аның мөнәсәбәте ничек һәм ни өчен үзгәрә?

3. Гыйлаҗиның фаҗигале үлеме ничек тасвирланган, бу вакыйгага Солтан ничек килеп катнаша, үзе ничек котылып кала?

4. Дуслык хисенә, мөнәсәбәтенә нинди хис килеп кушылды? Балачакта малайлар күңеленә нинди орлыклар салынган булып чыкты? Тормыш аларны ничек үзгәртте, ул орлыклар нинди чәчәкләргә әйләнделәр?

XLIII

— ...Инде тындык!

— Инде сабан-сукага!

— Инде җимерек өйләрне төзәтергә! — дигәндә, иң ышанычлы саналган Кронштадтның кызыл туфрагын кайдандыр искән җилләр белән ниндидер кара корым, тузан каплады, кызыл әләмне таплады.

Түзмәдем, җаным әрнеде, үзем теләп киттем.

Бөек крепостьларның тишекләреннән авызлары безгә каратып куелган зур тупларның өзлексез яудырган утларына каршы боз өстеннән күкрәк белән шуып бара идек... Өстебезгә ут ява иде... Ләкин без һаман шуа идек...

Кинәт янымда нидер җенләнеп шартлады. Карасам: уң аягым үземнән дүрт таяк җирдә, читтә, ялгызы канап ята.

Петроградта ике, Мәскәүдә биш,— барысы җиде ай лазаретта яттым. Өзелгән аякларымның, түгелгән каннарымның билгесе булсын дип, күкрәгем Кызыл Йолдыз белән зиннәтләнде. Бу — йөрәгем өчен иң кадерлесе булды. Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар.

Зарарлы түгел, култык таягы белән йөрергә уңай булачак.

Озатырга бер юлдаш бирделәр.

Лазаретларда күп ятып, буш араларда ике телдә дә укырга-язарга өйрәнеп җиткән идем инде, мондый җирләргә тиз арада әллә килеп була, әллә юк дип, бик күп китап җыйдым.

Шулай итеп, юлга чыктым.

Мәскәүдән кузгалгач, өч атна дигәндә, урманнар, болыннар, матур яшелләкләр белән киенеп, аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәнеп җиткән, иген басуларында яшелле-көрәнле солылар, тарылар арасында карабодайның ак чәчәкләре җирне каплап, тирә-якны бал исе белән хушландыра башлаган, биек тау итәкләрендә кыйбла кояшының нурларына йөзе белән караган

җирләрдә каен җиләкләре, җир җиләкләре тулып, кызарып пешеп килгән чакларда, матур аяз көннәрнең берендә, мин тагы үзебезнең Агыйдел буена — Зәңгәр Чишмәгә кайтып төштем.

XLIV

Соңгы атлар алмашкан Ивановка чувашы:

— Кызыл инвалидны ярты сәгатьтә илтеп җиткерим әле,— дип шаяра-шаяра, иң яхшы күк юргасын төпкә, алмачуар чабышкысын мичәүгә җигеп, минем каршы торуыма карамастан, кыңгырау да таккан иде.

Зәңгәр Чишмәгә җитеп, күпердән тузан туздырып чабып чыгуга, төрле урамнардан, төрле өйләрдән миңа баш иеп, кул селкеп калдылар. Безнең иске чүплек башындагы күршебез Сафа бабай, танырга тырышкан кеше кебек, кулларын күз өстенә куеп карады да шатлыгыннан ботларына кулларын чапты. Берничә җирдә балалар, мине танып:

— Солтан абзый килә!.. Солтан абзый! Һу... Әлләлә... әлләә!..— дип йөгереп, чыбыркы шартлатып озаттылар.

Шулай балаларны шаулатып, карт-корыга сәлам биреп, баш иеп бара торгач, базар мәчете ягыннан уңга, үзебезнең урамга борылыйм гына дигәндә, кемдер арттан кычкырды:

— Солтан туган, син бугай... Ялгыш китәсең, әнкәң хәзер Гыйрфан бай йортында,— диде.

Зур урам белән туры киттек.

Гыйрфан байның зур капкаларын ачтырып, ике ягы яшел түбәле келәтләр, лабазлар, складлар белән әйләндерелгән киң ишегалдына барып кергәндә, урам ягындагы ике катлы биек сарайдан, нидер сөйләшеп, көлешеп, бик күп яшьләр, кызлар, егетләр чыгып киләләр иде...

Арбадан төшкәнне дә көтмәделәр:

— Солтан абзый, Солтан абзый!..— дип, мине сырып алдылар. Бер-берсен бүлә-бүлә, үз хәлләрен сөйләргә, миннән бер-бер артлы сорашырга тотындылар.

Әйберләремне, ясалма аягымны, таягымны төрле кулга тараттылар да, арада тазарак ике егет, үземне ике яктан култыклап, җилтерәтеп:

— Әйдә, менә монда синең әниең,— дип, бакча эчендә, кайчандыр безнең әткәй белән Зариф бабай мәрхүмнәр эшләп биргән алты почмаклы өйгә алып киттеләр.

Баягы кыска чәчле, сандалилы шадра кыз, без арбадан төшмәс борын, алдан әнигә:

— Галимә әби, сөенеч, улың кайтты!..— дип йөгергән икән.

Без бакчага керүгә, өй эченнән әни килеп чыкты.

Аны күргәч, мин хәйран калдым. Бичаракаем, бу соңгы өч ел эчендә ун еллык картайган: чәчләре ап-ак, яңаклары эчкә суырылган, күзләре әллә кая төпкә батканнар, йөзендә тирән-тирән җыерчыклар буйга-аркылыга сузылганнар, биле бөкрәеп, буе кечкенә генә булып калган, җитмәсә, куллары да да калтырыйлар.

Ахрысы, догада, намазда утырган чагы булгандыр, бармак араларында озын тәсбих асылып тора.

Мине күрүгә:

— Ай, балам... Бу җирләрдә ризыкларың бетмәгән икән әле...— диде дә кочаклап катты. Елый да, артык сүз дә әйтә алмады.

Өй чибәр генә, пөхтә генә күренә. Рәхмәт инде, карчыкны урамга ташламаганнар.

Әткәйнең вафатын, Колчак сугышы вакытында туп төшеп, безнең өйнең янып бетүен ишеткән идем, әнинең кайда урнашуын белә алмый идем.

Байның үз заманыннан калган нәрсәләрдер инде: бер почмакта зур карават, ике тәрәзә арасында зур гына көзге, ике өстәл, берничә урындык, идәндә безнең теге өйдән килгән киез, караватта да безнең элекке түшәкястыклар, мендәрләр, юрганнар өелеп торалар.

Мин әнинең хәлен сорашып бетерергә өлгерә алмадым, яшьләр каяндыр май, йомырка, сөт, икмәк тә табып китерделәр. Үзләре һаман бер-бер артлы сөйлиләр, сорашалар иде.

Баягы кыска чәчле шадра кыз миңа туры карап торды да:

— Әткәй сине бик ярата иде... Исән-сау кайтсын дип, һаман тели иде,— диде. Мин аны танымадым:

— Сез кем кызы буласыз, сеңлем?

Кыз үпкәләгән тавыш белән бераз иркәләнде:

— Абау! Харап икән! Үзегезнең борынгы күршегезне шулай истән чыгарырга ярыймыни?.. Мин сезне бер дә онытмадым... Кечкенә булсам да, мин, сезгә ияреп, җиләккә йөри идем,— диде.

Мин дә төсмерләдем:

— Хәзер таныйм: сез Сафа бабай кызы Миңҗамал бит.

Комсомол кыз шатланып китте.

— Ярый, бөтенләй хәтердән чыгармагансыз икән әле без яшьләрне,— диде дә, һичкемнән сорамыйча-нитмичә, камил хуҗа хатыны кебек, өстәлгә чәйне әзерләде, безгә ясап эчерә башлады.

Сүз акрынлап эзгә керде.

Гыйлаҗины сагындылар. Бик тырышып эзләсәк тә, каберләрен таба алмадык. Халык сөйләве буенча, атылган җирләренә «Яшьләрдән — Зариф бабай белән Гыйлаҗетдин абзыйга» дип, таш яздырып куйдык, диләр.

Кемнәр киткән, кемнәр үтерелгән, кемнәр Себердән хур булып кайткан — шуларның барын берәм-берәм сөйләделәр, үтерелгән мөгаллимәләрне сагындылар...

Әллә кемнәр, әллә нәрсәләр турында төрле тавыш белән сайрадылар-сайрадылар да:

— Без сезгә күңелсезләнергә ирек бирмәбез... Һәрвакыт тик тә яткырмабыз... Дүшәмбе көн безнең уртак кичәдә өзелгән аягыңның тарихын сөйләрсең. Зәңгәр Чишмә буйлары мондый хәлләрне ишетергә бик сусаганнар... ярыймы? — дип, миннән кат-кат вәгъдәләр алгач, шаулашып чыгып киттеләр.

Ләкин, никтер, Гайнияне берсе дә телгә алмады.

Күрәсең, шулай мин дә Зәңгәр Чишмәдә калдым инде.

Бусы озакка — гомергә калу булыр.

Бер аяк белән чит илләргә чыгып йөрү мөмкин булмаганга, мин инде калган көчемне шушы Агыйдел буйларына багышлармындыр, ахрысы. Эшләрмен, Гайния минем юлдашым булыр.

XLVIII

Өемә кергәч, каршыма килгән кешедән аптырап калдым.

Кем булыр дисез?

Яңа гына кайтып, минем булмамда, өсләрен дә чишенмичә көтеп утыручы сезгә бик якыннан таныш, минем балалык, яшьлек дустым, революциядә дошманым булган Фазыйл иде.

Күңелемдә ике катлау, ике дулкын туды, шулай да тыштан сер бирмәскә тырыштым. Беренче сәламнән, беренче сүзләрдән соң үзеннән дә яшермичә:

— Кая, егет, күп үзгәрдеңме? — дигән кебек, йөзенә, өс-башына озак карадым.

Үзгәреше бик зур да, бер дә юк та...

Күп сүздән соң мин аңа мәсьәләне туры куйдым:

— Партиягә кандидат икәнеңне беләм... Мәскәүдә байтактан эшләвеңне дә ишеттем... Ачыгын әйт: Гыйлаҗи белән аның атасы Зариф картның каны синең кулдамы, түгелме? — Бу бер. Хәзерге үзгәрешең ихлас күңелдәнме, әллә җан саклау өчен, тагы элекке кебек халыкның башына менеп утыру өченме? — Менә бу ике.

Фазыйл яшермәде, күзләремә туры карап:

— Хәзер атып үтерсәң дә, мин синең кулыңдамын, дөресен әйтәм: Гыйлаҗи белән Зариф бабай мәрхүмнәрнең газраиле мин түгел, ләкин теләсәм, вакытында ул газраилне туктата ала идем мин,— диде.— Ихластанмы, баш саклау, халык җилкәсенә яңадан атлану өченме, дисең... Син бит мине беләсең!

— Бик яхшы беләм.

— Беләсең син: миндә иман белән гамәл бервакытта аерылмый...

— Аны да беләм...

— Аларны белсәң, син, минем шикелле йөзләрчә, меңнәрчә укымышлы Фазыйлларның, Иваннарның, Петровларның авыр трагедияләрен бер-ике сүз белән аңлаячаксың...

XLIX

...Шаһбазның ахыр фаҗигасен тик китәргә дип атлар җигелә башлагач кына сөйләде.

— Безнең уртак кайгы бар,— ди.— Шаһбаз хакында якын арада күңелсез хәбәр яздылар,— ди.

Сүз аз, хәбәр кыска:

— Минем дөньяда калган бердәнбер дусымны басмачылар авыр бер газап белән ике ай элек Фирганәдә үтергәннәр!

Фазыйл аның хакында байтак нәрсә белә икән: «Соңгы ел ярым эчендә ара-тирә хаты килгәли иде, ди. Миңа түгел, безнең белән бергә эшли торган бер хатынга килә иде, ди. Кайбер җирләрен миңа да укыта иде, ди. Ул мәктүпләрендә: Донны, Кубаньны тазарттык, ди торган иде, ди. Кавказның биек карлы таулары арасында дошманның җанын алдык. Азәрбайҗан, Каспий аша Төркестанга юл тотабыз, дип яза торган иде, ди. Сырдәрья, Амудәрья буйларында кара болытлар күренә. Шуларны тазарткач, дөньяның кай җирләрендә, нинди канлы көрәшләрдә йөзәргә насыйп булыр — хәзергә белмим, дип яза иде, ди. Бохарада, Фирганәдә булган кара көчләр өчен куркыныч кызыл батырларның берсе безнең Шаһбаз икәнен ул җирләрдән кайтучылар сөеп сөйлиләр иде, ди.

Актык хәбәр яңа алынган: «Шаһбазның башы өчен меңнәрчә алтыннар вәгъдә кылынган икән. Бер хыянәт белән кулга төшергәннәр дә, басмачыларның кара ояларында биек баганалар белән югары асып, түбәннән җәһәннәм кебек ут якканнар, ди. Дошманнар үзләре качкач, безнекеләр аның гәүдәсен шул күмер хәлендә асулы тапканнар. Олылап күмгәннәр».

Шулай Гыйлаҗины аттылар, Шаһбазны утка яктылар, болар — кадерле корбаннар, революция корбаннары. Инде Зәңгәр Чишмә дус-ишләреннән кемнәр кала? Фазыйллармы? Безнең түгелгән каннар эссесендә кайнап кына яңа «өлгерә» башлаган шул гыйлем егетләрме? Революциянең канлы, утлы көннәрендә чех, Колчак яклап, Советка каршы сугышкан ул Фазыйллармы?

Әлбәттә, түгел. Әнә кызыл инвалидны шаулап каршы алган яшьләр, ячейка массалары, комсомолка Миңҗамаллар бармы? Әнә шулар эченнән тагын исәпсез Шаһбазлар туып күтәреләчәкләр.

Мондый укымышлы ирләрнең безгә файдасы, бәлки, зурдыр, ләкин болар менә авыр көрәш көннәрендә бер Гыйлаҗиның, бер Шаһбазның кисеп ташланган тырнагына да тормыйлар бит; моны мин күз алдымда күрдем. Фазыйл, бәлки, яхшы да булыр, әмма Гыйлаҗилар, Шаһбазлар бөтенләй башка егетләр алар!

...Ара-тирә Фазыйл искә төшкәли. Аны да бик аз гына яратам бугай... Ләкин бу өстән генә, акыл белән генәярату булса кирәк.

Әмма йөрәгемне яңадан һичбер вакыт үзенә ала алмас инде, ахры... Шаһбаз белән Гыйлаҗи бервакытта да күңелемнән чыкмыйлар. Бу ике иптәшем йөрәгемдә революция белән бергә багланып кереп утырдылар.

Менә шулай булып бетте безнең язмышлар.

1922 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Солтан тагын нинди вакыйгаларга катнашып китә, нинди юллар үтә?

2. Ул Зәңгәр Чишмәгә кайтып төшкән вакыт нинди итеп сурәтләнгән, шул урынны табып укыгыз. Әсәрнең башында шуңа охшаш тасвирлау бар идеме?

3. Зәңгәр Чишмәдә нинди үзгәрешләр булган, авыл Солтанны ничек каршылый?

4. Егетләрнең язмышлары ничек тәмамлана, кемнәр исән кала?

5. Тасвирланган яки хәбәр булып килеп ирешкән үлемнәр төрле шартларда, төрле сәбәпләр аркасында була. Һәр үлемне каһарманлык дип әйтеп буламы? Ни өчен?

6. Солтан үз иптәшләренең язмышларын сөйләп бирде. Шуның белән ни дип әйтергә теләде? Сез үзегез нинди нәтиҗәләр ясар идегез?

7. Әсәрдә тасвирланган төп геройлар һам башка персонажлар янында тагын нинди образларны күрә алдыгыз? Язучының урыны белән шактый кырыс, рәхимсез рәвештә яңгыраган, урыны белән ягымлы, сагышлы булып ишетелгән сөйләм рәвешенә, сурәтле теленә игътибар итегез. Кайсы очракларда һәм ни өчен интонация үзгәрә?

ӘСӘРДӘ ГӘҮДӘЛӘНГӘН ФИКЕРЛӘР ҺӘМ ХИСЛӘР

«Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек». Әсәр шулай башлана. Нинди түбәнлек һәм биеклек турында сөйләргә җыена икән язучы? Без уйлана, чагыштыра башлыйбыз. Әсәрдә нинди күренешләр, вакыйгалар тасвирлана, нинди язмышлар турында сүз бара соң?

Вакыйгалар башланып киткән урын — Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан бормаланып аккан җиренә урнашкан Зәңгәр Чишмә авылы. Исеме хыялларны уята торган, табигате дә гадәттән тыш гүзәл: диңгез сулары кебек зәңгәрләнеп уйный торган зур, матур күл; карап туя алмаслык матур чәчәкләр, тирәякны хәйран итәрлек яшел үлән, хуш исле коры печән, югары болытларга сузылган таулар, меңәр еллык наратлар, мамык кебек йомшак, көзге төн болытлары кебек куе кара туфрак, ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр. Табигатьнең чиксез матурлыгы, киңлеге, биеклеге. Кешеләрне дә зур, мактаулы эшләргә, матур тормышка, бөек хыялларга, гомер буена җитәрлек дуслык һәм мәхәббәт хисләренә рухландыра торган табигать. Кешеләр күңеленә ул шәфкатьлелек, рәхимлек орлыкларын сала, аларның җанын сафландырып тора.

Баштан ук игътибарны җәлеп иткәне — Зәңгәр Чишмә авылының табигате Галимҗан Ибраһимовның туган авылы Солтанморат табигатенә охшаган булуы. Язучы юкка гына сөйләүче-хикәяләүче исеменнән туган авылын шулай күкләргә күтәреп мактатмый, моның

белән туган туфракка булган чиксез мәхәббәт, аның кадере-газизлеге ачыла, туган җиргә мөнәсәбәт белдерелә. Өстәвенә, автор әсәрнең төп героена да туган авылының исемен биргән: Солтанморат — Солтан.

Зәңгәр Чишмә авылында биш малай табигатьнең ягымлы җылысын тоеп үсәләр. Өйләре авылның төрле урыннарында, тормыш хәлләре төрле дәрәҗәдә булса да, табигать каршында алар — бертигезләр. Малайларны дуслаштырган, берләштергән тагын бер сәбәп бар, бу — балачакның эчкерсез законнары. Балачак дуслыктан башка була алмый, шул дуслык хисе тигезлекне, гаделлекне саклап тора. Башта аларның сугышып йөрүләре дә уен кебегрәк, йә олыларга ияреп, йә үз өстенлегеңне күрсәтү рәвешендә. Бу сугышулар аларны дошманлаштырмый, Солтан әтисенең, «юкка сугышып йөрмәгез» дип, олыларча киңәш бирүе, аларны үзара таныштыруы җитә — малайлар дуслашып китәләр.

Дөрес, үзен югары куярга ярата торган Гали юк-бар өчен дә Шаһбазга бәйләнергә тора торуын. Әмма мондый вакытларда акыллы Фазыйл әллә каян кирәкле сүзен таба, кызык уен уйлап чыгара. Көчле Гыйлаҗиның Шаһбазны яклавы да, Солтанның беренче көннән үк ятим малайны башкалар кыерсытуыннан саклап, үз канаты астына алуы да Галигә бик «үсеп» китәргә ирек бирми. Чөнки аның үзенә дә уйнарга, аралашырга иптәшләр кирәк.

Менә шундый дуслык орлыклары малайлар күңелендә матур булып бөреләнеп килә. Үсмер егетләр булып, тормыш йөген үз җилкәләренә күтәрә башлагач та, алар әле дуслар булып калалар. Җәй көннәрендә Зәңгәр Чишмәдә җыелалар, кайтуга бер-берсен эзләргә керешәләр, сагынып очрашалар. Солтанга өй салышырга да иң зур ярдәмне алар күрсәтә.

Әмма егетләрнең тормыш юллары инде аларны берләштереп торган туган туфрактан читкә алып чыгып китә, төрле якларга тарата. Бу әле алар арасында каршылыклы мөнәсәбәтләр тудырмаса да, тормыштагы урыннары ягыннан аларның аермалары күбрәк, кискенрәк күренә башлый. Бәлки алар шулай үзләре теләгәнчә, бер-берсенә ант биргәнчә, гомерлек дуслар булып калырлар да иде, ләкин араларына бик кискен һәм рәхимсез вакыйгалар килеп керә. Беренче бөтендөнья сугышы егетләрнең өчесен утлы өермәләр эченә алып

кереп китә. Гали белән Фазыйл, байлыкларына таянып, сугышка бармый калалар. Бөтен ил белән бергә дуслары кичергән язмыштан читтә калалар. Менә шунда инде алар арасында каршылык башлана.

Бер-берсенә ялганып киткән революцияләр, гражданнар сугышы, ике ярда калган егетләр арасында үтеп чыга алмаслык упкын хасил итә. Упкынны тудырган сәбәп — төрлелекнең тигезсезлеккә һәм гаделсезлеккә әйләнүе. «Аннан соңгы елларда дөнья кайнады, моңарчы гел бертөсле генә, тыныч кына агып торган тормыш диңгез кебек дулкынлана башлады. Бу дулкыннар, бу өермәләр эчендә еллар үтте, хәлләр үзгәрде, мәңгелек дуслыкта кырыгар мәртәбә ант итешкән безнең иптәшләр үзләре генә таралып калмадылар, күңелләре дә үзгәрде, юллары шул дәрәҗәдә бер-беренә каршыланды, без бер-беребезнең бугазларына килеп сарылыштык. Бер-беребезнең күкрәкләренә мылтык төзәп ату дәрәҗәсенә җитештек. Араларда упкын ясалды».

Сугыш елларында аеруча баеп, башкалар газап чиккәндә рәхәтлектә яшәргә, башкалардан өстен булырга күнегеп җиткән Гали күңелендә дошманлык хисе кайный башлый. Ул үзе яклы булмаган һәркемне, гаеплеме-юкмы икәнлеге белән исәпләшеп тормастан, дошман күрә, аларны җәзалап үтереп йөри. Рәхимсезлек, явызлык Галинең төп сыйфатына әйләнә. Аның кешелек дәрәҗәсеннән түбәнгә, упкынга тәгәрәве дә коточкыч рәвештә ясаган хыянәтеннән — үз кулы белән балачак, яшьлек дусты Гыйлаҗины җәзалап үтерүеннән башлана. Шаһбазны да бит нәкъ Гали кебек үк кансыз кешеләр тереләй утта яндыралар. Бу вәхшилекне ишеткәч, Солтан: «Минем йөрәгемә кара кан сауды, мин йөз еллык картайдым»,— ди. Гали дошман итеп күргән яңа тормышны кабул итә алмый, үзен үзе үтерә. Әйтерсең лә Зәңгәр Чишмәдә Гыйлаҗины җәзалаганда ук ул үз җанын, кешелеген үтереп куйган иде инде.

Солтанга күп газаплар кичерергә туры килә. Ул әллә ничә тапкыр яралана, бер аягын өздерә. Шулай да тән газапларын ул җиңелрәк кичерә. Ә менә дусларының үлеме аның үзәген өзә, йөрәгендә мәңгелек сагыш, моң булып кала. Галине ул тере чакта ук күңеленнән күмеп куя, аның ерткычлыгыннан җаны өши. Шулай да тормыш рәхимле; Зәңгәр Чишмә үз урынында, Солтан әйләнеп кайтканда, анда тагын ямьле табигать хакимлек

итә. Тормышка яңа кешеләр, яшьләр хуҗа булып алганнар. Солтанның мәхәббәтенә тугрылыклы булып, аны яшьлек дусты Гайния көтеп торган...

Кызыл орлыклар, язучы әйткәнчә, тарихның уңдырышлы туфрагына төшкәннәр: авыл яшьләренең күңелендә Солтанга һәм бер-берсенә карата дуслык, хөрмәт һәм тормышка ышаныч хисләре чәчәк аткан.

Әсәрдә, күреп үткәнебезчә, фаҗигале хәлләр, вакыйгалар турында сүз бара. Геройларның кайсы чорда, нинди шартларда яшәгәнлеген ачык күрәбез — тормыш җиңел түгел. Шулай да әсәр буеннан-буена яктылык һәм матурлык белән «сулап тора», безнең күңелдә канәгатьләнү хисе кала. Димәк, яшәү — аеруча кеше гомеренең балачак һәм яшьлек чорлары — үзе матурлыктан тора. Балачак — өметләр, хыяллар, дуслык, тугрылык, эчкерсез ышанулар чоры. Кешелек сыйфатлары да шундый мөнәсәбәтләрдән, хис-кичерешләрдән башлана. Гаделлек, кеше кадере — теләсә кайсы чор өчен дә иң әһәмиятле яшәү кагыйдәләре.

Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе һәм башка әсәрләре дә шул турыда сөйли. Тормыш авырлыгын җиңә торган көч чыганагы — кеше күңеле, аның характеры, рухи ныклыгы. Күзгә күренмәгән күңел дөньясы турында без гомеребез буе уйланабыз, аны җимермичә сакларга тырышабыз.



Халкыбызның тарихы зур вакыйгалар тезмәсеннән гыйбарәт. Әдәбият ул вакыйгаларны кешеләр язмышында тасвирлап күрсәтә. Тарих фәнен өйрәнгәндә, без революция, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы турында кайсы елларда, нинди җирләрдә барганлыгын, меңнәрчә һәм миллионнарча кешеләр катнашканлыгын белеп калабыз. Әдәбият шул меңнәрдән бер яки берничә кешенең тормышын, кичерешләрен аерып ала да шуларга ияртеп безне дә тарихи вакыйгалар эченә кертеп җибәрә. Әгәр дә әсәрнең төп герое бала булса, катлаулы һәм каршылыклы дөньяны без аның күзе белән күреп, аның аңлавынча кабул итә башлыйбыз. Әлбәттә, ул герой янәшәсендә шул бала күңелен бик яхшы сиземли торган өлкән «юлдашы» — әсәрнең авторы да була. Әсәрләрен балачакларында сезнең әти-әниләрегез дә яратып укыган һәм хәтерләп калган язучылардан берсе —

Гариф Гобәй
(1907—1983)

Гариф Гобәй иҗатының бер үзенчәлекле ягы бар: балалар өчен, балалар турында язганда, ул, аларның үз дөньяларын гына аерып алып, аларга гына кагылган вакыйгаларны тасвирламый. Геройларын ул аерылгысыз рәвештә ил язмышы белән бәйли, зур иҗтимагый тормышның кайнап торган чорларына илтеп куя, катлаулы сынаулар аша үткәрә. Гражданнар сугышы чорының катлаулы да, фаҗигале дә, шул ук вакытта романтик та булган вакыйгаларын гәүдәләндергән «Каланча», «Без әле очрашырбыз», «Маякчы кызы» повестьлары яки Бөек Ватан сугышына багышланган «Замана балалары», «Маратның язмышы» әсәрләре...

Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: геройларының күбесе — төрле сәбәпләр аркасында төрле дәрәҗәдә ятим калган балалар.

Казанның Бишбалта бистәсендә һөнәрче гаиләсендә туган Гариф белем мәктәбе белән хезмәт мәктәбен бергә үтә: типографиядә хәреф җыючы, трамвай йөртүче, соңрак балалар йортында тәрбияче булып эшли. Менә шунда ул үзенең булачак геройлары белән таныша, төрле язмышлы характерлар белән очраша да инде. Әсәр язганда хыял көче белән ул аларны йә Агыйдел буйларына, йә урмандагы ялгыз йортка күчереп куя, яки сугыш елларының бормалы сукмаклары буйлап йөртә. Казан педагогия институтын тәмамлагач, мәктәптә укыткан еллары аны шулай ук балалар дөньясына якынайта.

Гариф Гобәй китап укучылар өчен тагын бер игелекле хезмәт күрсәтә әле — «Мең дә бер кичә» исемендә гарәп әкиятләре китабын, Марк Твенның «Том Сойер маҗаралары», Бичер-Стоуның «Том агай алачыгы» әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Дөнья әдәбиятының бу гүзәл үрнәкләре шулай ук берничә буын укучыларны мавыктыргыч маҗаралар дөньясында сәяхәт иттерде.

Гариф Гобәйнең иң танылган әсәрләреннән берсе белән танышырбыз.

МАЯКЧЫ КЫЗЫ

(Әсәрдән өзекләр)

Агыйделдә таң ата

Рухны күтәрә, дәрт уята, тәнгә көч бирә торган салкынча таң. Агыйдел таңы.

Тын. Бик тын. Күктә соңгы йолдызлар сүнә. Куаклар артындагы түгәрәк күлдә ана үрдәк, бак-бак килеп, балаларын йокыдан уята.

Әнә Агыйдел — үзе турында бик күп җырлар җырлаткан, әкиятләр сөйләткән ямьле Агыйдел! Аның өстеннән акрын гына сыек томан күтәрелә. Су читендә ялгыз көймә. Ул салмак кына чайкала. Ә әнә тегендә, Агыйделнең аргы як читендәге сирәк камышлыкта,

түшен тәкәббер киереп, шул ук вакытта бик сакланып, аккош йөзә.

Илсөяр шуларның барысына да сокланып карап торды да әкрен генә әйтеп куйды:

— Шундый матур, әти, шундый матур тышта...

Бу вакытта Мәрдән абзый киенеп беткән иде инде. Ул, әкрен генә килеп, тәрәзәдән карады һәм кызына эндәште:

— У-у, матур икән шул,— диде ул,— әйдә, акыллым, минем белән маяк сүндерергә...

— Әйдә, әти.

Минут үтүгә, алар Агыйдел ярына чыгып бастылар. Илсөяр, шатланып, иркен сулады. Иркәләнеп, әтисенең биленә башын куйды.

— Таң атканда бигрәк тә матур инде безнең бу Агыйдел, әти, әйеме?

— Әйе шул, кызым.

— Ә-әнә теге буйлар нинди матур булып кызарып килә. Кояш шуннан чыга, әйе бит, әтием?

— Әйе, кызым.

— Кәмәш әби ялганлаган. Аны солдатлар күсәк белән каерып чыгармый, әйе бит, әтием?

Мәрдән абзый көлде. Илсөяр дә көлде; аннан әтисен ярның куерак чирәмле урынына җитәкләп килде дә сөенеп әйтеп куйды:

— Шунда утырып торыйк, әти... Бераз гына...

Ата белән кыз куе үләнле текә ярдан аякларын салындырып утырдылар да сөйләшеп табигатьнең ямен җибәрүдән курыккандай тынып калдылар.

Әнә ничек сизелер-сизелмәс кенә таң сызыла. Офык читендә, бер карасаң, бөтерелеп килгән диңгез дулкыннары төсле, бер карасаң, эрүсәгән[1] кар өемчекләре төсле чал болыт. Болыттан арттарак — түгәрәк ай, аңардан әз генә өстә, күктәге йолдызлар арасында, иң зур, иң якты йолдыз — Чулпан йолдызы. Аның тын Идел

---

[1] Эрүсәгән — эреп, кечерәеп калган.

өстенә төшкән шәүләсе, алтын багана булып, су төбенә сузылган. Әз генә җил исеп, су өсте шадраланып киткәндә, шәүлә киртләч-киртләч булып сына, әллә ничә җирдән өзелә. Су өсте тынгач, шунда ук бик шома алтын багана булып, тагын Агыйдел төбенә сузыла.

Көнчыгыш ягы алсулана, торган саен агара бара ул. Агыйделнең ике ягы буйлап тезелеп киткән яшел, кызыл маяк утлары хәзер тоныграк булып күренәләр. Ай батып барган яктан һавага ике көтү үрдәк күтәрелгәне күренә. Үрдәк көтүенә каршы бер йолдыз атыла. Йолдыз, күз ачып йомганчы үтеп китеп, офыкта югала. Аның эзе берникадәр вакыт һавада сызылып тора. Ә үрдәкләр, канатларын шапылдатып, үзара әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, камышлыкка карап очалар. Баягы аккош, чакырылган кебек кинәт борылып, камышлык эченә кереп югала.

Агыйдел өстендәге төн пәрдәсе юкара. Агыйделнең сыек яшел суы инде үз төсенә керә. Аның борылыштагы ташларга бәрелә-сугыла агуы хәзер аеруча матур булып күренә башлый. Берсен берсе кабатламый торган ямьле күренешләр берсен берсе әнә шулай алмаштырып торалар. Аларның һәр үткәне кызганыч, һәр яңасы үткәненнән матур.

Әз генә җил исеп китә.

Илсөяр җиңел генә дерелдәп куя һәм, әтисенең куенына сыена төшеп, әкрен генә эндәшә:

— Әти!

— Нәрсә, акыллым?

Илсөяр бик текә ярдан түбәнгә күрсәтә:

— Әти, менә бу су ага да ага. Ничек бер дә бетми соң ул, әти?

— Ничек бетми? Һем-м... Ничек әйтергә соң сиңа? Бакчы, безнең тирәдә генә дә ни тикле чишмә бар. Ә бөтен Агыйдел буенда! Тагын елгалар бик күп. Шулар барысы, барысы Агыйделгә агып төшәләр дә бер су булып — зур су булып агалар.

— Ә кая ага соң бу Агыйдел, әти?

— Камага, кызым.

— Ә Кама кая ага?

— Иделгә.

— Ә Идел?

— Идел... Идел — диңгезгә.

— Ә ул кая коя?

— Анысын инде син, кызым, Андрей дәдәңнән[1] сора. Ул — укыган кеше, белә. Ә мин, кызым, укымаган, белмим. Менә әле син Совет чыккач, бер кыш булса да укып калдың. Кызыллар илдән акларны сөреп чыгаргач, тагын укырсың...

Кыз әтисенә елыша төште һәм, берәрсе ишетмәсен дигән сыман, авызын әтисенең колагына якын китереп пышылдап куйды:

— Ә акларны кайчан сөреп чыгарырлар соң, әти?

— Тиз, кызым, тиз...

Кызын тынычландырыр өчен генә әйтмәде Мәрдән абзый. Агыйдел буеннан аклар табан ялтыратырга күп калмаган иде инде. Туп тавышлары гел якыная баралар һәм: «Аклар бүген-иртәгә Агыйделдән шыла икән»,— дигән хәбәрләр дә йөри башлаган иде.

Мәрдән абзыйның тавышы тынып та бетмәде, хәбәрне дөресләргә ашыккан шикелле, еракта, бик еракта ике-өч тапкыр туп гөрселдәде. Илсөяр, күтәрелеп, әтисенә карады:

— Кызыллар, әйе бит, әтием?

— Шулар, кызым.

— Монда киләләр, әйе бит, әтием?

— Әлбәттә, кызым.

Әле генә төн караңгылыгын тишеп, су өстен яктыртып торган яшел һәм кызыл утлы маяклар көчсезләнеп калдылар. Хәзер аларның утлары түгел, кызыл һәм яшел буяулы воронкалары гына күренә, шәүләләре агым суда җиңел генә чайкала иде.

Мәрдән абзый әкрен генә урыныннан торды:

---

[1] Дәдә — русча дядя (абзый) сүзен татарчалатып әйтү.

— Әйдә, кызым, ишкәкләрне ал. Маякларны сүндереп меник. Әле дә тикмәгә яналар. Бөтен төнгә бер пароход үтми. Ә менә сугыш беткәч, күрерсең... О-о... анда, кызым, эш бүтән булыр, түбәннән пароход күренеп өлгермәс, югарыдан икенчеләре килеп чыгар. Ул да түгел, дөпдөп буксир, көймәләр... тагын пароход, тагын көймәләр.

— Ә аннан соң гел кызыллар гына булып торырмы?

— Гел, кызым.

— Әйдә, эти.

Илсөяр, сикерә-сикерә ярдан төшеп, көймәгә керде дә көзгедәй тигез су өстенә ишкәкләрен әкрен генә салып ишә башлады.

Мәрдән абзый белән Илсөяр берничә маякка кадәр сөйләшмичә бардылар.

Икенче маякны сүндергәч, көймә агымга түбән борылды. Илсөяр, ишкәген ташлап, маңгаена төшкән чәч учмаларын яулык читенә кыстырды. Тагы бер тапкыр ište дә ишкәкләрен кулларыннан җибәрде.

Соңгы маякны сүндерергә килгәндә, кызарып чыккан кояшның беренче алтын нурлары тын Агыйдел өстенә җәелде. Нәкъ шул чакта Илсөяр көн дә шушы вакытта ишетә торган ягымлы, иркә тавыш ишетте:

— Илсөяр-әр!

— ...Әнә бабаң да торган, кызым.

Илсөяр, күтәрелеп, биек ярга карады...

— Баба-кай-й,— дип тавыш бирде Илсөяр һәм, ашыгып-ашыгып, ярга таба ишә башлады. Көймә озын борыны белән бик тиз ярга килеп бәрелде. Илсөяр, көймә туктап җитәр-җитмәс атылып чыгып, текә ярдан өскә таба үрмәләде.

Менеп җиткәч, Мәрдән абзый шикелле үк кара күзле, ләкин шактый кечерәк буйлы, көләч йөзле кешенең муенына сарылды.

— Әйбәт йокладыңмы, бабакай?

— Аю кебек, кызым.

— Балыкка, әйе, бабакай?

— Тоттырса...

Бикмүш бабай — Мәрдән абзыйның атасы. Карт инде ул — җитмешкә җитеп килә. Ул шул гомереңнең күп өлешен Урал шахталарында күмер чабып үткәрде. Картаеп эшкә ярамый башлагач, аны хуҗалары куып чыгардылар... Йөри-йөри менә шушы Агыйдел ярларына килеп чыга ул. Шул көннән башлап Мәрдән абзый, Илсөяр, Бикмүш бабай — өчәү бергә яши башлыйлар. Шул көннән башлап Илсөяр белән Бикмүш бабай, Мәрдән абзыйга булышып, җәен балыкка, кышын ауга йөреп үткәрәләр. Бикмүш бабай Илсөяргә шахта турында, шахтадагы йөзләрчә күмер тузаны сеңгән кешеләр, аларның хуҗаларга каршы баш күтәрүләре турында сөйли. Шулай үтә аларның соңгы еллары.

Сораулар һәм биремнәр

1. Табигатьне тасвирлаган урыннарны аерып алып укыгыз, чагыштыруларны табыгыз. Алар әдәби әсәрдә ни өчен кулланылалар икәнен аңлатып карагыз.

2. Илсөяр «Су кая ага?», «Ул ничек агып бетми?», «Кояш ничек чыга?» дип сораулар бирә. Бу аның нинди сыйфаты турында сөйли? Ә сез үзегез Илсөяргә ничек җавап бирер идегез?

3. Илсөяр, аның әтисе, бабасы турында ниләр аңладыгыз? Аларның үзара мөнәсәбәтләре ничек тасвирланган?

4. Сезнең таң атканны күргәнегез бармы? Ул нинди булып исегездә калды?

5. Табигатьне тасвирлаган урыннарны ятлагыз.

Кунак бабай

Илсөяр өйгә йөгереп килеп кергәндә, анда ниндидер бер ят бабай утыра иде.

Кыз аны күрүгә бусагада туктап калды. Ят бабай да, сүзен бүлеп, бер мизгел Илсөяргә карап торды. Аннары, тагы Мәрдән абзыйга таба борылып, ярар дигән мәгънәдә, чак кына ияк кагып куйды. Мәрдән абзый да какты ияген, Илсөя бу ымлашуларда ниндидер сер барын сизде. Бу сернең бая бабасы белән әтисе арасындагы пышылдашуларның дәвамы икәнен дә сизде

ул, тик мәгънәсенә төшенә алмады. Менә ят бабай тагы Илсөяргә таба борылды:

— Йә, нихәл, тәти кыз?

Илсөяр эндәшмәде.

— Абау, әллә инде су кергәндә телен чуртан балык тешләп алган?..

Илсөяр, уңайсызланып, башын түбән иде.

— Тешләмәгән.

— Алай, яхшы...— дип елмайды бабай һәм, билендәге путасын бушатып, куеныннан зур гына бер кызыл алма чыгарды.

— Мәле, акыллым. Йә, кил инде, тартынма,— диде ул һәм алманы Илсөяргә сузды.

Илсөяр ят бабайның кулына күз кырые белән генә карап торды да, кыюсыз гына атлап килеп, алманы алды.

— Рәхмәт, бабай...

Ләкин Илсөяр шулхәтле әкрен әйтте, ят бабай аның сүзләрен бөтенләй ишетмәде, бары тик авызы кыймылдавын гына күреп калды.

— Йә, Илсөяр... Балык шәп чиртәме?

Чиртми дисәң, булдыксыз дип көләр, чиртә дисәң, ялган була. Шуңа күрә Илсөяр ни дип тә җавап бирмәде. Әйбер эзләгән булып, өстәлгә таба китте.

Ят бабай:

— Белдем инде, мин килгәнне яратмаган икән, шуңа сөйләшми... китәм, алайса,— дигән булды һәм, менә сиңа кирәк булса, чыгып та китте.

Илсөяр, уңайсызланып, идәнгә ашъяулык җәеп торган әтисе янына тезләнде.

— Әтием...

— Юк, кызым, шаярта ул. Хәзер керә...

— Ә нинди кеше соң ул?

— Юлаучы. Каенсарга бара. Юл адашып кергән. Менә чәй эчкәч, үзен урманга, Каенсар юлына тикле озатып куярсың.

— Абау, шунда хәтле дә бара белмимени?

— Белми. Бу як кешесе түгел ул, ерактан килә.

— Ә-ә... алайса, мин аны Каенсарга ук илтеп куйыйм, әти, тау аша гына.

— Ярамый... Таулар аша йөрергә йөрәгем шәп түгел, ди.

— Ә-ә,— диде Илсөяр һәм, әтисе кулындагы икмәкне алып, ашъяулыкка турый башлады.

Чәй өлгерде.

Чәй өлгерүгә китмәдем инде, берәр ай торгач, бәлки сөйләшә башлар әле дигән булып, кунак бабай да әйләнеп керде. Ул да түгел, Бикмүш бабай кайтып җитте. Тәрәзә төбендә битен юып маташкан соры песи — Фатыйма, сикереп төшеп, Бикмүш бабайны гадәтенчә мыраулап каршы алды.

— Шул синлек кенә булды да...— Бикмүш бабай җепкә тезгән кечкенә-кечкенә өч чабакны идәнгә ыргытты. Балыклар тыпырчынырга тотындылар. Песи, песиләргә генә хас осталык белән, балыклар өстенә ташланды.

— Чиртми, шельма[1],— диде Бикмүш бабай. Ул киез эшләпәсен чөйгә элде дә табын янына тезләнде.— Чиртми... Кунакны балык белән сыйлармын дигән идем. Булмады инде, бигайбә[2], кем...

Кунак, икмәк телеменә тоз сибә-сибә, Бикмүш бабайга таба борылды:

— Зарар юк...— диде ул һәм чәен тәлинкәгә салды да ашык-пошык шопырырга тотынды.

Бар да сүзсез калдылар. Ә Илсөяр кунакның да, әтисенең дә, бабасының да һәрбер хәрәкәтен күзәтеп утырды.

Ник әти үзе дә эчми, нигә кунак бабайга шулхәтле исләре киткән? Әти нигә бертуктаусыз керә-чыга йөри? Ә кунак бабай нигә шулай ашыга?

---

[1] Шельма — шайтан (шаярту катыш ачуланып әйтү).

[2] Бигайбә — гаеп итмә.

Әйе, кунак бик ашыга иде. Ул, авызын пешерә-пешерә, тагын бер чынаяк чәй эчте дә, тиз генә торып, чөйдән котомкасын алды.

Мәрдән абзый да, Бикмүш бабай да никтер кунакны кыстамадылар. Илсөяр өчен монысы да сәер иде. Ә Мәрдән абзый, кунак артыннан ук торып, аның белән чыгып киткәч, Илсөяр тагын да аптырый төште.

Һәрбер нәрсәне күрергә, белергә яраткан Илсөяр, алар артыннан чыкмакчы булып, ишеккә килде. Тик, ят бабайдан уңайсызланып, кире борылды. Ләкин бу аның тынычлануы түгел иде әле. Кыз, шул турыда сораштырырга дип, бабасы янына килде, әмма өлгерә алмый калды. Кунак белән әтисе бик тиз әйләнеп керделәр. Кунак чәй эчкәндәге шикелле ашык-пошык тәмәке төрде дә путасын кысып бәйләде.

— Вакыт,— диде ул,— Илсөяр озатыр дисең, Мәрдән?

— Озата, озата...— диде Мәрдән абзый. Аннары Илсөярнең башыннан сыйпап көлемсерәде.

— Кунак бабаңны бик әйбәтләп озат, яме, кызым.

— Җә, әти.

— Җә булса бар, чабаталарыңны ки, аннан туры өйгә кайт. Андрей дәдәңә кереп торма. Соңга калырсың.

— Җә, әти.

Бикмүш бабай, башын тәрәзәдән сузып, кояшка карап алды да:

— Бераз ял итеп алсаң да була иде әле. Бик иртә кузгалдың, кунак,— диде.

— Вакыт. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

— Анысы да дөрес. Болай сез иртәнге салкын белән урманга да җитсәгез кирәк.

— Илсөяр атын ничек куар бит...

Нинди сәер бабай соң бу? Нинди ат булсын безнең?

Ул арада кунак эшләпәсен басып киде дә тиз-тиз атлап өйдән чыкты.

— Ярый, хушыгыз, сыегыз өчен рәхмәт. Әйдә, акыллым...

— Хәерле юл, туган.

Кунак башта әкрен генә барды, өй яныннан ераклашкач, хәйран тибеш[1] атлый башлады, ә инде өй күздән югалганда, яшенә карата искиткеч җиңел атлый иде. Гәүдәсе кармак шикелле бөгелеп килгән. Чәче дә, сакалы да җитен төсле ак. Кашларына хәтле агарып беткән. Бикмүш бабайдан бик күп карт булса кирәк. Ә ничек җитез! Илсөяр, бабасы белән берәр җиргә барырга чыкса, аны көтеп ала-ала аптырап бетә, ә моның артыннан тиз-тиз атлап та өлгерүе кыен.

Кунак бабай урманга кергәнче сөйләшмичә барды. Тик, урманга кереп, Илсөяр юлдан читкә өстери башлагач кына, тавышы чыкты аның.

— Юл сулда калды ич, Илсөяр!

— Моннан турырак...

— Әһә. Ә адашмабызмы соң?

Илсөяр кунак бабайга ияләнеп килә иде инде. Шуңа күрә ул, иркенәеп, әтисе һәм бабасы белән сөйләшә торган телдә җавап бирүдән дә тартынмады.

— Фу,— диде ул. Бу Илсөярнең: «Мондый гына юллардан йөргәне бар инде апаңның, мин монда күземне бәйләп җибәрсәләр дә адашмыйм»,— диюе иде. Кунак бабай да бу «фу»дан шундыйрак мәгънә аңлады булса кирәк, бер дә шикләнмичә, юлсыз җирдән атлый башлады. Тик алда алан күренгәч сорап куйды:

— Еракмы әле, акыллым?

— Әти, биш чакрым, ди.

— Ул да шушыннан йөримени?

— Әһе.

— Син монда еш буласыңмыни?

— Әһе.

— Нишләп?

— Андрей дәдәләргә киләм.

— Кем соң ул Андрей дядя?

— Каравылчы, урман каравылчысы.

— Ул да сезгә киләме?

---

[1] Тибеш — кызу, тиз.

— Әһе.

— Ә монда, урманда, бер ялгызың йөрергә курыкмыйсыңмы соң?

— Фу...

Урман эче караңгыланганнан-караңгылана барды. Аланның бу ягында тагы да караңгылана төште. Хәзер урман шулкадәр куе иде, безнең юлчыларга аллы-артлы барырга туры килде. Илсөяр — алдан, бабай — арттан. Өстә агач тармаклары бер-берсе белән шулкадәр чәлмәшеп[1] беткән, аларның куе яфраклары арасыннан көн яктысы урыны-урыны белән генә үтә алган иде. Шуңа күрә юлчылар каяндыр килеп чыккан болытны да сизмәделәр, бары күле корыган икенче бер аланга килеп чыккач кына күрделәр.

Кунак бабай, урман өстенә тияр-тимәс йөзгән тоташ соры болытка карап:

— Оһо... Бөтенләй каплап алган ич бу,— диде һәм шунда ук Илсөярне юатырлык берәр сүз әйтмәкче булды. Чөнки ул, Илсөярне яңгырдан куркып борчыла башлар, дип шикләнде. Ә Илсөяр юеш көл шикелле соры болытларга күтәрелеп карады да шатланып куйды:

— Әй, күңелле була да соң хәзер!..

— Яңгыр? Күңелле?

Җил исеп китте, агач башлары шаулашып куйдылар.

— И-и, алайса, яңгыр яуганда урманда булганың юк икән әле синең. Мин бит яшенле яңгырны әйтәм...

Кунак бабай гаҗәпләнүеннән берникадәр вакыт эндәшми торды, аннан әйтеп куйды:

— Юк шул.

— Ә минем бар... Бик күп.

— Булган кыз икәнсең син, алайса.

— Һе.

Юлчылар, шулай бара торгач, кайчандыр яшен сугып сындырган, кәүсәсенең бер ягы күмергә әйләнгән

---

[1] Чәлмәшеп — чуалып, чәбәләнеп.

юан имән янына килеп чыктылар. Имән яныннан сулга таба бер сукмак киткән иде. Ят бабай шул сукмакка чыкты да таныш әйберсенә караган кук карап торды һәм Илсөяргә болай дип эндәште:

— Минем юлга шушы сукмак чыгамы?

— Шушы сукмак.

— Ә каравылчы йорты әнә шундамы?

— Әйе, бабай,— диде Илсөяр һәм тагын нидер әйтергә теләп авызын ачкан иде, ят бабай аны бүлде.

— Бик шәп,— диде ул.— Рәхмәт, кызым. Мин хәзер юлны үзем дә табармын инде. Бар, кайт, күгәрченем.

Әбә-әү... Илсөяр бит әле кунакның исемен дә, яшен дә, Каенсарга нишләп баруын да белмәде. Балаларын, аларның исемнәрен дә сораша алмый калды. Бу турыда ул, яшен яшьнәп, күк күкрәп яңгыр ява башлагач, берәр имән куышын эзләп кереп утырганда сорашырмын дип уйлаган иде. Күк күкрәмәде шул, яшен яшьнәмәде, яңгыр да рәхәтләндереп яумады.

Кунак бабай Илсөярнең йомшак сары чәчләрен сыйпады да, куеныннан алып, аңа тагын бер алма бирде һәм тиз-тиз атлап китеп барды.

— Хуш, күгәрченем.

Әллә ничек күңелсез, моңсу булып китте Илсөяргә. Ул берникадәр вакыт аптырап карап торды да сәер бабайга дәште.

— Нәрсә, күгәрченем?

Илсөяр, тагын бераз озатыйммы әллә, димәкче булган иде дә, уңайсызланып:

— Адашмассыңмы соң, бабай? — диде.

— Юк, юк, кызым... Бар, кайт инде, кайт...

Илсөяр каравылчы өенә бик якын булса да кереп тормады, чөнки әле аның Салавычка барып, катык алып кайтасы бар. Аннан, бүген иртәрәк ятып йокларга кирәк. Иртәгә бит аны әтисе тауга алып менә. Анда әтисе нindидер серле нәрсә күрсәтергә булды. Илсөяр шуңа күрә ашыга-ашыга кирегә атлады. Шулай да, каравылчының кызы күренмиме икән дип, артына борылып

карады һәм... Менә сиңа кирәк булса... Кунак бабай як-ягына каранып алды да сакланып кына кире борылды. Һәм... Каенсарга таба түгел, каравылчы өенә таба китте. Илсөяр яшен сугып көйдергән имән төбенә чүгәләде. Кунак бабай тагын як-ягына каранып алды да йөгерергә үк тотынды.

— Менә сиңа кирәк булса,— диде Илсөяр үзенә үзе,— нинди сәер кеше соң бу? Юлбасармы әллә югыйсә? Юлаучы диюе ялган булдымы? Андрей дәдәдә үче бармы әллә моның? Үтерергә килгәнме әллә ул Андрей дәдәне?

Илсөяр курыкты, шулай да беләсе килү куркуны җиңде. Ул, агачларга яшеренә-поса, шикле бабай артыннан күзәтеп бара башлады.

Ләкин бабай урман каравылчысы өчен, Илсөяр уйлаганча, куркыныч кеше түгел икән. Ул, каравылчы өенә җиткәндә, үз ишегалдына кайтып кергән хуҗа шикелле, иркен атлый иде. Каравылчы да, тәрәзәсен ачып, бабайга дусларча елмайды. Менә алар өй түрендә очраштылар да, күптәнге дуслар шикелле, кул кысышып күрештеләр, ашык-пошык нәрсәдер сөйләштеләр, аннан әкрен генә урман куелыгына кереп югалдылар. Илсөярдә курку кимеде кимүен, ләкин сәер бабай тагын да серләнә төште. Һәм Илсөяр, аучы җәнлек артыннан күзәткән шикелле, бабай белән Андрей дәдәне күзәтә башлады.

Илсөяр алардан егерме-утыз адым гына калып бара. Аптырый, йөди ул, башында төрле сораулар туа һәм аларның берсенә дә җавап таба алмый. Ул бары бер генә нәрсәне белә:

— Каенсарга бармый бу. Безне алдаган. Андрей дәдә белән аның берәр яшерен эше бар... Әһ-һәәә, белдем инде... алар берәр күмелгән хәзинә беләләрдер... Шуны казырга баралар.

Илсөярнең исенә кайчандыр бер узгынчы әби сөйләп киткән әкият төште. Анда да бит, шушындый ук бер кара урманда, агач төбеннән ике кеше җиде сандык алтын казып алалар. Аларның да бит берсе нәкъ шушындый үзе бөкре, үзе җитез карт була, икенчесе...

Ләкин менә сиңа кирәк булса... шикле бабай путасын чиште, чиште дә иске чикмәнен, озын киндер күлмәген салды. Һәм... (Илсөярнең йөрәге бер тын тибүеннән туктап торды, аннан бик еш тибә башлады. Башын саклап калырга теләгән сыман, иңбашларына яшеренде.) Шикле бабай шомырт кара чәчле, озынча алсу яңаклы, типсә тимер өзәрдәй таза бер егеткә әйләнде. Аның ак чәче, ак сакалы, чал кашы парик булган икән. Ә бөкресе бер иске бүрек, имеш...

Менә Андрей дәдә ул салып ташлаган сәләмәләрне җыеп алды да өйгә таба китте. Әлеге кеше исә бераз барды да, җирдән бер таяк алып, корган наратка бик каты итеп ике тапкыр сукты... Шунда ук әллә кайдан мылтыклы бер башкорт килеп чыкты. Башында кырпулы[1] бәрхет бүрек, ак күлмәк өстеннән җиңсез казаки[2] кигән. Аякта читек, тез астыннан нечкә каеш белән кысып бәйләнгән. Башкорт сәер кеше белән кочаклашып күреште. Аннан тиз генә башкорт килгән якка таба китеп югалдылар.

Илсөяр куркуыннан бер мизгел кузгала алмыйча торды; тынычлана төшкәч, кача-поса чигенергә тотынды. Бераз чигенгәч, тагын туктап калды. Артта, бабай булып йөргән кеше белән мылтыклы башкорт киткән якта, ат кешнәгән тавышлар ишетелде. Илсөяр тагын берничә адым чигенде, аннан, бөтен көчен биреп, олы юлга таба йөгерергә тотынды...

...Менә ул йөгереп килгән уңайга бөтен гәүдәсе белән өйалды ишегенә килеп бәрелде. Һәм ике куллап дөбердәтергә тотынды.

— Кем бар?

Илсөяр дөбердәтә генә алды. Һәм ишек ачылуга Бикмүш бабайның алдына капланып елый башлады.

— Чү, нәрсә булды сиңа? — диде Бикмүш бабай, ә Илсөярнең бите тырналган, күлмәк җиңе ертылган икәнен күргәч, бөтенләй куркуга төште.

---

[1] Кырпулы — чите мех белән әйләндереп алган.

[2] Казаки — кечерәк кенә утыртма якалы өске кием.

Тавышка будкадан чыккан Мәрдән абзый да шул сорауны кабатлады:

— Ни булды? Сөйлә тизрәк!

Илсөяр әле һаман сөйләшерлек хәлдә түгел иде.

— Куркытканнар баланы,— диде Бикмүш бабай. Ул Илсөяргә чүмеч белән су китерде. Илсөяр салкын су эчкәч, бераз җиңеләеп киткән шикелле булды. Ул башта, тотлыга-тотлыга, аклар турында сөйләп бирде, аннары «кунак бабай» турында сөйләргә кереште.

— Теге «кунак бабай» безне алдаган, чистый юлбасар икән ул.

Билгеле, Илсөярнең сүзләренә берсе дә ышанмады. Шулай да кызның ни өчен шулай дип әйтүен беләселәре килә иде.

— Ник алай дисең, кызым?

Илсөяр ул кеше белән үзенең кая кадәр барганын, аның белән ниләр сөйләшкәнен, ниләр күргәнен сөйләп бирде һәм сүзен шулай бетерде:

— Юлбасарның да юлбасары... Сакал-мыегы, чәче — бөтенесе алдау булган. Йолкуына җыенысы кубып чыкты... Анда алар бик күп, унлап, йөзләп бардыр. Безгә килгән кеше башлыклары, ахрысы. Көтеп торалар икән үзен, күренүенә күтәреп кенә алдылар.

Мәрдән абзый Илсөяр сөйләгәндә чыдарга тырышып караса да, булдыра алмады, көлеп җибәрде. Бабасы да көлде. Алар көлгәч, Илсөяр өчен сер тагын да тирәнәя төште. Карады да катты ул аларга. Әтисе исә, көлүеннән туктап, һәрвакыттагыча уйчан кыяфәткә керде. Һәм, Илсөяр каршысына тезләнеп, болай диде:

— Син — акыллы кыз, мин сиңа ышанам. Минем монда сөйләгәннәремне дә, урманда күргәннәреңне дә беркемгә, һичкайда әйтмәссең, яме. Тынычлан. Бернәрсә дә юк, кызым. Безгә килгән кунак та, аның иптәшләре дә начар кешеләр түгел, яхшы кешеләр... Ә калганын соңыннан сөйләрмен...

Ата шулай диде дә тиз генә өйгә кереп китте. Ишек ачылып ябылганда Илсөяр өй эчендә биш-алты кеше

күреп калды. Аларның берсе — кыек якалы кара сатин күлмәк кигәне, озын сары чәчлесе, әкрен генә нидер сөйли, башкалар йотлыгып тыңлый иделәр. Илсөяр өчен өйгә күпләп-күпләп кеше җыйналу да, аларның кайчакларда төннең төн буена шулай сөйләшеп утырулары да яңалык түгел иде. Шуңа күрә ул аларга артык әһәмият бирмәде. Аны хәзер икенче бернәрсә — кунакның үзе өчен һаман да серле булып калуы һәм атасының әйтеп бетермәгән сүзләре кызыксындырды.

Яхшы кешеләр... ә кемнәр соң алар — яхшы кешеләр? Кыяфәтен алыштырып йөрүче яшь егет кем ул? Алар анда — урманда нишлиләр? Әти нигә анысын әйтмәде?

Сораулар һәм биремнәр

1. Кунак бабай ни өчен башта ук Илсөяргә сәер булып күренә?

2. Әтисе ни өчен кунак бабайны үзе озатмый, бу эшне кызына куша икән?

3. Кунак бабайның «сере» нәрсәдә? Сез аны аңладыгызмы?

4. Илсөярнең гаять кызыксынучанлыгы, һәрбер нәрсәне күрергә, белергә ратуы бүлекнең кайсы урыннарында ачык күренә? Шул урыннарны табып укып күрсәтегез.

5. Илсөяр өчен җавапсыз калган сорауларга сез ничек җавап бирер идегез? Кемнәр ул — яхшы кешеләр? Кунак бабай кем булып чыга?

Урманга, партизаннарга

— Әйдә, кызым, будкага керик әле...

Мәрдән абзый Илсөярне будкага кертеп җибәрде. Аның артыннан үзе дә кереп, тәрәзәгә килде. Бераз карап торды да кызына болай диде:

— Мин сиңа бер эш тапшырырга уйлыйм, кызым. Зур эш... Бик зур. Сиңа хәзер урманга барырга туры килә. Теге «кунак бабаң» янына...

Илсөяр җиңелчә генә калтыранып куйды. Мәрдән абзый аны тынычландырырга ашыкты.

— Ә син курыкма, кызым, «кунак бабаң», инде сиңа дөресен әйтергә була, партизан ул — партизаннар командиры. Урманда аны каршы алган иптәшләре дә — партизаннар, кызылармеецлар шикелле үк, ярлы халык өчен сугышып йөрүче кешеләр...

Мәрдән абзый, сүзен бүлеп, тиз генә тәрәзәгә килде. Узып баручы солдатларга карап алды да киң җилкәсе белән тәрәзәне томалады.

— Бар... Бүген үзең күргәннәрнең барысын да «кунак бабаңа» сөйләп бир. Дүрт йөз солдат диген. Тирә-як авыллар ярдәмгә киләчәк диген. Бар, кызым, ашык,— диде.

Илсөяр тагын калтыранып куйды. Бу юлы «кунак бабай»дан куркып түгел, йомышның артык җаваплы булуыннан, әтисенең урманга шундый зур сер алып барырга кушуыннан куркып калтыранды ул. Аның күзләре зур булып ачылдылар, кыз ни дип тә җавап кайтара алмады. Мәрдән абзый Илсөярне тынычландыру өчен елмаеп куйды. Һәм, кызының биленнән тотып, башы түшәмгә тигәнче күтәрде:

— Йә, кызым, нигә бик уйга калдың?

Илсөяр җавап кайтармады. Мәрдән абзый, аны идәнгә төшереп, йомшак чәченнән сыйпады.

— Кыюрак, кыюрак бул, кызым.

Илсөяр аяк очларына карады.

— Мин... мин кыю, әти. Мин хәзер...

— Менә шулай... Бар, хәерле юл. Кулыңа кечкенә тырысыңны ал. Солдат-мазар очрап сорашырга тотынса, урманга гөмбәгә барам диярсең. Синең өчен иң кирәклесе — үзеңне тыныч тоту, каушамау. Ләкин кара, бик тиз йөр, кызым. Әз генә соңга калуның да бөтен эшне бозуы мөмкин.

Илсөяр өстенә йөкләнгән бурычны ничек үтәргә, партизаннарга нәрсә сөйләргә, юлда кеше очраса, ничек узып китәргә кирәк икәнен күз алдына китерә-китерә ишектән чыкканда, кояш кызуы сүрелеп килә иде инде...

Илсөяр, будка почмагыннан борылып чыккач та, ике солдатның, штыклы мылтыкларын алга каратып, тар сукмак буйлап кара-каршы йөреп торганнарын күрде. Күрде дә кинәт туктап калды. Аның аяклары бик озак авырып яткан кешенеке кебек хәлсезләнеп киттеләр. Илсөяр алга атларга теләде, ә аяклары буйсынмадылар.

Курыкты Илсөяр. Кая барганымны сизгәннәрдер дип уйлады. Әнә аяклары Илсөяргә таба атлау өчен күтәрелделәр дә бугай... Әнә берсе, эләктең бит, кызый, хәзер, күлмәгеңне салдырып, шомпол[1] белән ярабыз да, кул-аягыңны бәйләп, трюмга[2] төшереп ташлыйбыз, дияргә авыз ачты бугай... Илсөяр каушады, аның колак яфракларына кадәр кызышты... Юк, ул түзә алмас, менә хәзер кычкырып елап җибәрер дә будкага йөгереп керер...

Шул чакта, кулындагы кечкенә тырысы исенә төшеп, Илсөяр иркен сулап куйды һәм артына яшерелгән тырысны беләгенә киде. Болай иткәч, куркуы басыла төште. Тагы бераздан, гөмбәгә баргандагыча, иркен атлап кузгалып китте. Солдатлар тотып алу түгел, кая барасың дип сорап та тормадылар.

Илсөяр башка вакытларда гөмбәгә килсә, беренче гөмбәне тырысына салганчы, җиләккә килсә, беренче җиләкне өзеп капканчы, урман каравылчысының кызы Аня янына кереп, соңгы көннәрнең яңалыкларын сөйләшеп чыга, аның белән уйный иде. Тик бүген Илсөяр бу турыда уйлап та карамады. Урман каравылчысы үзе өйдә юк, ә кызына очрап юл бүленүдән куркып, читтәнрәк үтте.

Беркөн «кунак бабай» белән аерылышкан җирдә ул әкрен генә сызгырырга тиеш иде. Илсөяр, туктап, якягына каранды, аннары сул кулының ике бармагын иреннәренә китерде:

— Фю-у!..

---

[1] Шомпол — винтовка көпшәсен чистарта торган махсус тимерчыбык.

[2] Трюм — пароходның әйберләр тутыра торган аскы өлеше.

Илсөярнең баш очында гына тырышып-тырышып агач чукып маташкан кызгылт түшле тукран, чукуыннан туктап, акыллы күзләре белән аска карады. Әллә Илсөярне күрмәде, әллә күреп әһәмият бирмәде, шунда ук озын томшыгы белән яңадан чукырга тотынды. Ә сызгыруга каршы җавап кайтаручы булмады.

— Әкрен чыкты,— диде Илсөяр,— ишетмәделәр. Ул бер-ике адым алга атлады да тагын сызгырып җибәрде. Көчле нечкә тавыш, агачларга бәрелә-сугыла, еракларга китеп тынды. Тукран, бу юлы аска карап та тормады, канатларын киң җәеп, югары күтәрелде дә бик тиз күздән югалды. Ә җавап кайтаручы тагын булмады...

Илсөяр, артык тавыш чыгарудан куркып, әкрен генә унбиш адым алга атлады. Тагын тынып калды. Һаман бер тавыш та юк. Әллә арып туктады, әллә тамагы туйды — тукран тавышы да бетте инде. Әйтерсең Илсөяр бөтен урманда берүзе калды, әйтерсең барлык кошкортлар да, җәнлекләр дә дәррәү йокыга талдылар, ә партизаннарның барысын берьюлы җир йотты...

Илсөяр шулай уйланып барган җиреннән кинәт туктап калды, җиргә кадәр иелде дә, ашыга-ашыга, нидер карый башлады. Нечкә озын бармаклары бертуктаусыз кыймылдадылар. Әллә баягы, әллә бүтән бер тукран якында гына, тук-тук итеп, агач чукый башлады. Тик Илсөяр моны ишетмәде. Ул тезләре белән шуыша-шуыша нидер эзләде, тикшерде...

Менә ул, иге-чиге булмаган ком сахрасында озак эзләп йөргәннән соң, яланаяклары белән салкын чишмәгә баскан юлаучы шикелле, шатланып кычкырып җибәрде:

— Эз!..

Һәм, янында кеше булып, шуны ышандырырга тырышкан сыман сөйләнеп куйды:

— Эз! Эзләр! Яңа эзләр, болайга таба киткәннәр! Ә менә болары — ат аягы эзләре...

Илсөяр эз буенча алга йөгерде. Бераз йөгергәч, җиргә ятып тыңлады. Бу юлы ул үзеннән ерак түгел аяк

тавышлары ишетте. Һәм сызгыру өчен бармакларын иреннәренә китерде. Нәкъ шул чакта аның алдына, җир астыннан үсеп чыктылар диярсең, ике кеше килеп басты. Илсөяр, сизмәстән елан койрыгына баскан кеше кебек чытаеп[1], артына чигенде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Илсөяргә әтисе нинди эш тапшыра? Ни өчен аны зур эш дип әйтә?

2. Илсөярнең кичерешләрен сөйләгез: ул нәрсәдән курка, ничек итеп үзен тынычландыра? Аның батыр йөрәкле булуын ничек исбатлар идегез?

3. Илсөяр партизаннарны ничек эзләп таба?

4. Ә сез урманда курыкмыйча һәм адашмыйча йөри аласызмы? Аның өчен нәрсәләр белергә кирәк?

Әти ашыгырга кушты

— Тукта, кулларыңны күтәр!

Илсөярнең йөрәге, күкрәген бәреп чыгарга җыенган кебек, дөп-дөп тибәргә тотынды.

— Беттем,— диде ул эченнән генә һәм шунда ук тынычланып китте. Бу кешеләрнең озынча йон бүрекләрендә югарыдан түбәнгә таба кыеклап сузылган өряңа кызыл тасмалар күрде. (Сәер дә инде: кызыл лента, мылтык, ә аякта чабата.) Кызыл тасмалылар бер-берсенә карашып алдылар да Илсөяргә таба сузылган штыкларын кырыйга бордылар.

— Син кем? — диде аларның берсе һәм, Илсөярнең куркырлык кеше түгел икәнен күреп, тавышын түбәнәйтте.

— Нишләп син, туташкай, берүзең урманда сызгырып йөрисең?

---

[1] Чытаеп — сискәнеп, куркып.

Икенчесе, «сак булу зыян итмәс» дигән сыман, Илсөярне тагын бер кат күзләреннән кичерде дә сорауны кабатлады.

Тәмам тынычланып җиткән Илсөяр:

— Миңа Костин абый кирәк иде...— диде.

Кешеләр тагын бер-берсенә карашып алдылар.

Кешеләрнең берсе, колакларына ышанасы килмәгән кебек, бик гаҗәпләнеп сорау бирде:

— Костин иптәш кирәк?

— Әйе, абый.

— Ә нигә ул сиңа?

Илсөяр, күптән таныш кешеләр белән гади нәрсәләр турында сөйләшкәндәгечә, тыныч кына әйтеп куйды:

— Шулай, кирәк инде... Мине тизрәк Костин абый янына алып барыгыз әле.

Кешеләр тагын бер-берсенә карашып алдылар. Аларның берсе башын чайкап куйды да тәмәке янчыгын чыгарды. Илсөяр, боларның бик үк ашыгырга уйламауларын күргәч, тагын әйтеп куйды:

— Миңа бик тиз кирәк... Мин ашыгыч эш белән...

— Ашыгыч эш белән?

Кызыл тасмалылар күз карашлары белән үзара сөйләшеп алдылар. Тәмәке янчыгы чыгарганы төрүеннән туктап тамак кырды, моны ишетеп, күз ачып йомганчы каяндыр тагын ике кеше килеп чыкты. Боларның аркасында кыска мылтык булып, билләрендә кылыч, кулларында камчы иде. Алар Илсөяргә карап алдылар да килгән юлларына ашыгып китеп бардылар...

Озак та үтмәде, ат аягы тавышы ишетелде. Илсөяр һәм кызыл тасмалылар борылып карадылар. Атлылар икәү булып, икесе дә ун-унбиш адым читтә туктап калдылар. Шомырт кара ат өстендә килгән кеше, тиз генә төшеп, Илсөяргә таба атлады.

— Һи, һи, мин кемне күрәм!

Илсөяр әле кайчан гына үзе чәй ясап эчергән һәм урманга озатып куйган «кунак бабай»ны бик тиз таныды. Аның өстендә хәзер күн пиджак, билендә киң

каеш, аягында күн итек. Киң каешына наган кыстырылган. Тик теге юлы, иптәшләре янына җиткәнче, бу киемнәрнең барысын да яшереп торган сәләмәләре һәм ап-ак чәче белән сакалы гына юк иде.

Илсөяр, шатланып, аның каршына йөгерде. Кул биреп күреште дә, аның колагына үрелеп, атасы әйтергә кушканнарны пышылдады һәм, ишетмиләрме икән дип шикләнеп, як-ягына күз йөртеп чыкты да, аяк очларына басып, тагы Костин колагына үрелде.

— Нәрсә?! — диде гаҗәпләнгән Костин.

Илсөяр тагын пышылдады һәм шуннан соң барысы да ишетерлек итеп әйтте:

— Әти ашыгырга, бик тә ашыгырга кушты.

Бандäны тар-мар итәргә!

Костинның йөзе үзгәреп китте, күзләре усалланды, маңгае җыерчыкланды. Ул Илсөярне, әйдәп, атлар янына алып килде һәм башыннан сыйпады.

— Рәхмәт, Илсөяр, рәхмәт, акыллым. Без бер сәгатьтән анда булырбыз,— диде һәм: — Кил, мин сине атландырыйм, арыгансың,— диде.

— Мин үзем...— диде Илсөяр һәм Костин аты шикелле үк шомырт кара атка менеп атланды да аяклары белән ияр өзәңгеләрен эзләргә тотынды. Аяклары җитмәгәч, каушап, әле уңга, әле сулга янтайды. Илсөяргә карап торган партизаннар үзара елмаешып алдылар. Берсе сөйләнеп куйды:

— Бик аз гына үсәсең калган икән, тәти кыз.

Илсөяр ялт итеп иелеп аска карады. Анда, Илсөяр атланган ат янында, бик яшь башкорт егете басып тора иде. Ул яшьлеге белән генә түгел, кием-салымы белән дә башкалардан аерылып тора иде: өстендә кыска гына кара пиджак, төймәләре җиз, ялтырап торалар, башында кара козыреклы зәңгәр фуражка. Озынча күзләре капкара, чәче дә кара, кашы да. Егет бераз елмаеп торды да, тиз генә килеп, Илсөяр атланган атны авызлыклады.

Аннан соң өзәңгеләрен Илсөяр аякларына җайлап кыскартты.

Костин яшь партизанга эндәште:

— Сиңа бераз тәпиләргә туры килер, Өметбаев. Күрәсең, кунак...— диде ул һәм атына сикереп менде.

— Есть тәпиләргә!

Атлар кузгалып киттеләр. Берникадәр араны юлсыз җирдән баргач, сирәк үскән нарат агачлары арасыннан үтә башладылар. Алда коры агач ботаклары шартлап сынган тавышлар һәм тәртипсез атлаган аяк тавышлары ишетелде.

— Һоп-лә-ә!

Костинның аты, сөлек шикелле сузылып, тавышлар ишетелгән якка ыргылды. Һәм, бер минут үтүгә, алар отряд янына килеп чыктылар. Костин отрядка туктарга кушты.

Урманга сибелеп баручы җәяүле партизаннар һәм алар алдындагы атлылар туктап калдылар.

Костин, ияр өзәңгеләрендә бераз күтәрелә төшеп, бер карауда бөтен отрядка күз йөртеп алды да:

— Иптәш Храбрый, иптәш Солтанов, минем янга! — диде.

Ике кара ат, отрядтан аерылып, бик тиз генә Костин янына килеп җитте.

— Тыңлыйбыз, иптәш командир.

Партизаннар отрядының командиры Костин Илсөяр китергән яңалыкны кыска гына итеп аңлатты да, әле Храбрыйга, әле Солтановка карап, алардан җавап көтте.

— Ничек уйлыйсың, иптәш Храбрый?

— Барырга кирәк.

— Иптәш Солтанов?

— Барырга! Банданы камап алып тар-мар итәргә!

— Дөрес уйлыйсыз, командирлар...— диде Костин һәм агач кобуралы зур маузерын терсәге белән барлап алды да атын отрядка таба борды:

— Шаһи абзый!

— Әү-ү!

— Монда кил!

Отрядтан аерылып, Костин янына бер карт крестьян йөгереп килде. Костин аңарга, шыпырт кына:

— Әйдә, Шаһи абзый, отрядны олы юлга алып чык,—диде. Һәм шунда ук команда бирде: — Отряд, минем арттан!

Отряд, берьюлы кузгалып, командиры һәм Шаһи абзый артыннан китеп барды.

Ярты чакрым чамасы баруга, отряд олы юлга чыкты.

Монда Костин партизаннарга поход юнәлешенең үзгәргәнлеген аңлатты һәм өчәрләп тезелергә команда бирде. Үзе җиде-сигез адым алга чыкты. Аның бер ягында — пехота командиры Храбрый, ә артында, ярсыган атын көчкә-көчкә тыеп, атлы взвод командиры Солтанов тора иде.

— Отряд, смирна-а!..

Бу вакытта Илсөяр эскадрон командиры аты төсле үк ярсу ат өстендә отряд эченнән үзе атланган ат иясен — җиз төймәле яшь партизанны эзли иде...

Гомуми команда белән йөрергә өйрәнгән Юлбарыс отряд артыннан ыргылды; ул, пехотаны тиз генә узып китеп, атлы взвод белән бер сафта чаба башлады.

— Беттем,— диде Илсөяр,— ташлап калдыра инде...

Ләкин акыллы Юлбарыс Илсөярне ташламады. Атлы взводны узып, Костин янына — һәрвакытта йөри торган урынына җиткәч тә, тыныч кына юырта башлады...

Менә Илсөярнең шәрә аякларына, бөтен гәүдәсенә салкын җил килеп бәрелде. Кыз ат ялына тияр-тимәс барган башын әкрен генә күтәреп карады. Бу инде урман авызы булып, алда, кичке эңгер-меңгергә төренеп, Агыйдел буеның киң яшел кыры җәелеп ята иде. Илсөяр өенә — әтисе, бабасы янына кайтып җиткән кебек шатланып куйды:

— И-и... ничек тиз...

Урман эчендә лап-лоп басып килгән аяк тавышлары ишетелде. Костин, тиз генә сикереп торып, урман авызына таба китте. Илсөяр дә аның артыннан йөгерде.

Урман авызыннан пехота килеп чыкты. Костин команда бирде:

— Стой! Ялга! Тәмәке тартмаска!

Костин, бөтен отрядны үз янына җыеп, алда торган бурычны аңлатып бирде:

— ...Дошманның нинди алдында торганыбыз, ничек хәрәкәт итәргә кирәклек аңлашылгандыр, иптәшләр. Үзебездән дүрт-биш өлеш күп һәм яхшы коралланган, явызлыкның чигенә чыккан банда белән очрашырга туры килә. Шуңа күрә һәр партизанга тапкырлык һәм, хәзер мин сезгә сөйләгәнчә, хәйлә белән эш итәргә туры киләчәк. Ярдагы сакны юк итүгә кадәр булган план һәм шартлы сигналлар сезгә билгеле. Хәзер юлга чыгабыз. Иптәш Өметбаев, минем янга!..

Сораулар

1. Партизаннарны Илсөяр нинди билгеләре буенча танып ала? Аларның киемнәре, кыяфәтләре ничек тасвирланган?

2. Илсөяр «кунак бабай» — Костин белән ничек очраша, ул кем булып чыга?

3. Илсөяр партизаннар арасында үзен ничек хис итә? Партизаннарның аңа мөнәсәбәтләре нинди? Илсөярнең тагын нинди осталыгын күрдегез?

4. Отряд нинди максат белән, кая юнәлә? Сез партизаннар турында ниләр беләсез?

Һөҗүм алдыннан

Будкага җитәрәк, йөз-йөз илле адымда бик күп тармаклы, куе яфраклы бер карт имән бар. Ярты сәгать үтүгә, шул имән төбенә ике кеше шуышып килде. Кешеләр имән ышыгында башларын күтәреп як-якка карап алдылар да, корбаны өстенә барган мәчеләрдәй, сакланып кына имән буйлап өскә үрмәләделәр. Боларның берсе — Костин, икенчесе Илсөяр иде.

Илсөяр куе яфраклы ботакларны як-якка аерды да командирның колагына пышылдады:

— Менә моннан кара, Костин абый, моннан бөтенесе дә күренә,— диде.— Әнә безнең өй. Әнә, әнә часовойлар[1] да. Әнә тегендәрәк тагын өчесе. Күрдеңме? Чүгәләгәннәр бугай. Берсе әрле-бирле йөреп тора...

Костин Илсөяр күрсәткәннәрне бинокль аша карап алды да картасына нидер сызгалады.

— Яхшы. Бар да яхшы,— диде ул, аннан картасын сумкасына салды.— Син бередә кал, акыллым, тирәюньне күзәтә тор, күргәнеңне миңа сөйләрсең; мин хәзер киләм,— дип өстәде. Һәм, тиен шикелле ботактан ботакка күчеп, тиз генә төшеп тә китте. Төшүенә, күләгәдәй тавышсыз иелеп, җиргә ятты һәм килгән якка таба шуыша башлады.

Костин киткәч, Илсөяр, күзләре талганчы, часовойларны күзәтеп торды. Керфеккә керфек какмады ул. Аннан әз генә түбәнге тармакка төште дә күкрәге белән кәүсәгә сөялде. Бары шунда гына үзенең бик каты арыганлыгын сизде. Күзләре ихтыярсыз йомыла башладылар. Җитмәсә (ул бит әле бүген бернәрсә ашамаган), ашыйсы, бигрәк тә эчәсе килә иде.

Башка вакыт аңа игътибар итмәс иде. Хәзер аның колагына көмеш тавышлы чишмә чылтыраганы ишетелде. Бу шул инде, Илсөярнең иң яраткан чишмәсе. Илсөяр аны карап кына тора. Берәр җәнлек-фәлән килеп пычратмасын дип, былтыр аңа бабасы белән яшь каеннардан киртә тоттылар. Бик матур. Тирә-ягы шәрә иде, кәс җәйделәр. Сукмагына ком сиптеләр.

Илсөяр, авызын шул чишмәгә куеп торгандагы кебек итеп, иреннәрен ялап куйды. Ай, бигрәк салкын, бигрәк тәмле чишмә шул ул... Аннан соң Илсөяр будка морҗасыннан төтен чыкканын күрде һәм, йокысы килүдән күзе әчетсә дә, озаклап шул якка карап торды. «Кичтән бабай ипи изгән иде, шуны пешерә торгандыр... Кабартмасы да була инде аның, алайса...» — дип уйлады ул һәм аның күз алдында әле генә мичтән чыккан зур-

---

[1] Часовой — сакта торучы.

зур кайнар ипиләр, зур чуен эчендә зур-зур бәрәңгеләр гәүдәләнеп, тамагын кытыкладылар... Менә Илсөяргә бабасы күпереп, кызарып пешкән зур бер арыш кабартмасы алып бирде. Илсөяр, үз кулы белән тыгылып, чуеннан зур бер бәрәңге алып тоз сипте дә иреннәренә китерде... Илсөяр, чыннан да, ашагандагы шикелле итеп, авызын чәпелдәтеп куйды. Ләкин бу, әлбәттә, хыял гына иде. Илсөяр, төкереген йотып, күзләрен йомды һәм, хыял эчендә йоклап китүдән куркып, күзләрен ачты. Часовойларга карап алды ул, әле чүгәләде, әле басты, ничек кенә булса да, Костин килгәнче йокламыйча түзәргә тырышты. Ләкин йокы барыбер үзенекен итте. Йокы Илсөяргә әле болай, әле тегеләй һөҗүм итте — күзен йомдыртты, иснәтте, ниһаять, кызны җинде.

Аның күз алдында әллә нинди аңлашылмаган әйберләр, ике башлы кешеләр, тагын әллә нәрсәләр йөри башлады. Теге кызыл сакаллы кечкенә офицер, кабан тешләрен ыржайтып көлеп торды да, кинәт кашларын җыерып, Илсөярнең маңгаена штык[1] белән кадады, Илсөяр штыкны тиз генә тотып алды һәм... чак кына егылып төшми калды: уянып киткәндә, аның бер аягы имәннән ычкынган, ә сул кулында, әлбәттә, Кызыл сакал штыгы түгел, озынборын иде.

Нәкъ шулчак имән төбендә нидер кыштырдады. Илсөяр күзләрен уып ачты да аска карады. Анда Костин һәм тагын бер кеше менеп килә, бу бер кеше, Илсөяр аның атына атланганга күрә, урман буенча җәяү чапкан яшь партизан Өметбаев иде.

Командир, күзләрен бинокленнән алып, иркен сулап куйды. Аннан соң, шыпырт кына:

— Чиста, чиста эшлиләр егетләр! Молодцы! — диде дә тиз генә сикерде.— Әйдәгез!

---

[1] Штык — мылтык башына беркетелгән хәнҗәр, үткен очлы тимер.

Илсөяр имәннән төшүенә сузылып ятты. Командир, иелеп, аның иңбашыннан сөеп эндәште:

— Тор,— диде ул, көлемсерәп,— хәзер инде сезнең өйгә кадәр җырлап барырга була. Часовойлар юк ителде, сеңлем.

Илсөяр һичнәрсә аңламады. Ничек юк ителде, кем юк итте аларны?

Командир, кесәсеннән ак яулык чыгарып, югары күтәрде. Имәннән унбиш-егерме сажинда түш белән шуып килүче отряд җирдән калыкты һәм, эре-эре атлап, имән төбенә таба килә башлады.

— Минем арттан,— диде Костин аларга һәм, Илсөярне әйдәп, будкага таба китеп барды.

Будкага җитәрәк, отрядны Мәрдән абзый каршы алды. Аның кулында өстенә казаки каплаган фонарь иде. Мәрдән абзый, кызын кочып сөйгәннән соң, командир белән исәнләште дә:

— Тугыз йөз төтенле[1] дүрт авыл күтәрелде. Халык моннан өч чакрымдагы Сазлы күл буена җыйналды. Сигнал булуга килеп җитәчәк,— диде.

— Ничә кеше?

— Дүрт йөзгә тулмыймы икән...

— Шәп, шәп. Ә корал ягы ничек?

— Корал... Анысы юграк шул, иптәш командир.

— Зарар юк. Сигнал бир!

Мәрдән абзый пароходка арты белән әйләнде дә фонарь өстендәге казакины ачып җибәрде. Зәңгәр ут берәр секундка тирә-якны яктыртып торды, аннары сүнде.

— Шаһи абзый, Ивашин, Хәсән! Барыгыз, авылдашларыгызны каршы алыгыз,— диде командир һәм инде будка янына җитеп килгән отрядка җиргә ятарга кушты, үзе Мәрдән абзый белән өйалдына кереп китте. Бу вакытта Илсөяр бая будка тирәсендә калган сакчыларны карап йөри иде.

---

[1] Төтенле авыл — морҗалы, ягъни кеше яши торган йортлы авыл.

Часовойлар кырылып җирдә яталар. Барысының да куллары артка каерылып бәйләнгән. Кайсының авызында үзенең фуражкасы, кайберсенекенә дыңгычлап чирәм тыгылган иде. Һәркайсының янында, мылтыклар, наганнар тотып, таза-таза партизаннар басып тора иде...

Һөҗүм

Хәрәкәтсез калып тыңлаган партизаннар кузгалышып куйдылар. Тик берсе дә тынлыкны бозмады. Командир Мәрдән абзыйга кулы белән ишарә ясады. Мәрдән абзый, «ярый» дигән сыман, башын иде дә ярга таба китеп югалды. Костин фуражкасын салып чирәмгә куйды һәм, җиргә утырып, тиз-тиз генә итекләрен салырга тотынды. Барлык партизаннар да командирлары артыннан аякларын чишенә башладылар. Озак та үтмәде, партизаннар, яланбаш, яланаяк калып, түшләре белән шуыша-шуыша, ярдан төшеп киттеләр. Партизаннар ярдан төшеп китүгә, әрәмәлектә кара болыт шикелле халык төркеме күренде. Әрәмәлекне чыгуга, аларның да күбесе ярга таба шуыша башлады. Илсөяр, этисе кушуы буенча, бабасы янына кереп, ишекне бикләде.

— Бабай,— диде ул, бусагадан атлауга,— кара, нишләп караңгыда утырасың? Ут кабыз, бабакай.

Агыйделгә каршы тәрәзә төбендә Бикмүш бабай кыймылдап куйды. Дәшмәде.

— Бабай, утны...

— Ярамый...— диде Бикмүш бабай,— ут кабызырга ярамый. Кил, җылытыйм үзеңне, туңгансың.

Илсөяр, сүзсез генә килеп, бабасының куенына керде.

— Ә мин, бабай, партизаннарны эзләп йөргәндә...

— Тсс, соңыннан... Әнә кара!

Илсөяр Агыйделгә карады. Анда ул су читеннән аерылып китеп барган бер көймә күрде. Көймәдә Мәр-

дән абзый булып бик әкрен ишеп бара, идәнендә бер кызыл, бер зәңгәр фонарь җемелди иде.

— Әбәү, эти бу вакытта фонарьлар белән нишләп йөри икән?

— Тонык яналар ич, маякларның фонарьларын алыштырырга уйлаган, күрәсең...

Бикмүш бабай дөрес әйтте, ләкин фонарьларның ни өчен тонык янганнарын, Мәрдән абзыйның аларны ни өчен алмаштырып йөргәнен әйтмәде.

Илсөяр, күзләрен көймәдән алып, пароходка карады. Капитан күперчегендә эчпошыргыч тонык сары ут яктысында кинәт бер солдат калыкты. Солдат, ике-өч атлауга, пароход кырыена килеп җитте.

— Кем килә? — дип кабатлады ул.

Мәрдән абзый, башын күтәреп:

— Бу мин, маякчы, дус кеше,— диде.

Солдат, син булсаң ярый дигән сыман итеп, кире борылды һәм күздән югалды. Мәрдән абзый тиз-тиз ишеп килде дә тонык янган зәңгәр маякны алыштырды. Аннары кызылы янына — пароход койрыгына килде.

Теге солдат тагы калыкты һәм, пароход кырыена килеп, көймәгә таба иелде. Ахрысы, тартырга сорады, Мәрдән абзый солдатка янчык ыргытты. Солдат, капитан күперчегендә әлеге саргылт утлы фонарь янына китеп, тәмәке төрде дә, янчыкны кире бирү өчен, тагын Мәрдән абзый янына килеп иелде. Нәкъ шул вакытта солдат артында бер партизан пәйда булды[1]. (Ул Мәрдән абзыйның көймәсе артына посып килгән иде.) Менә партизанның кулында пычак ялтырап китте, һәм солдат, җил аударган көлтә кебек, бер тавышсыз авып төште.

Нәкъ шул чакта ярдан төшеп комлыкны үткән партизаннар, мылтыкларын баш очларына күтәреп, әкрен генә суга керә башладылар.

Мәрдән абзый пароходка якын килү хәйләсе белән алыштырылган маякларны тиз генә килеп бөтенләй

---

[1] Пәйда булды — күренде, кайдандыр килеп чыкты.

сүндерде. Маяклар сүнүгә, пароходның тирә-ягы караңгыланып китте. Озак та үтмәде, Мәрдән абзый пароход түбәсендә күренде. Будка тәрәзәсеннән карап торган Илсөяр белән Бикмүш бабай тонык ут яктысында аның, сакчы солдатка кадаган кыю партизан белән бергәләп, пулеметны баскычка таба борып куйганын күрделәр.

Менә халык та су читенә килеп җитте.

Кешеләр, кайсы чишенеп, кайсы чишенмичә генә, тиз-тиз суга кереп киттеләр һәм, партизаннардан күрмәкче, судан башларын гына калкытып, пароходка таба бара башладылар.

Болар барысы да Илсөяргә кызык булып тоелды. Аның хәзер генә булып үткәннәрнең барысын да яңадан күреп үткәрәсе килде һәм әкренләп тәрәзәдән тышка таба сузыла барды. Ул күзләре белән пароходтан әтисен, часовойга пычак белән кадаган кыю партизанны эзләде, ләкин берсен дә таба алмады. Пароходта әле сугышмыйлар, аннан һаман да иренеп шыңшыган гармун белән исерек җыр гына ишетелә иде.

Байтак вакыт үткәч, пароходның түбәнге палубасында партизаннар күренә башлады. Алар анда ишәйгәннән-ишәя бардылар. Бераздан партизаннар һәм крестьяннар пароходның түбәсендә дә күренделәр. Кинәт «ура» тавышы яңгырап китте. Бер-бер артлы атылган мылтык тавышлары ишетелде. Пароход түбәсеннән көлтә хәтле ут бөркелде, туп булгандыр, бик каты гөрселдәде. Мондый гөрселдәүне Илсөярнең беркайчан да ишеткәне юк иде әле. Кыз, куркып, артына чигенде, гөрселдәү кабатланмагач, тагын тәрәзәдән тышка таба шуыша башлады. Бикмүш бабай аны иңнәреннән тотып туктатты.

— Ярамый, кызым. Моны безнекеләр ата. Хәзер, мөгаен, кара-каршы атыш башланыр,— диде ул һәм Илсөярне тәрәзәдән читкә өстерәде.

Менә монысын инде Илсөярнең бик үк тыңлыйсы килмәде. Бабасы өстерәгән саен, ул аякларын катырак терәде. Күңеле тышта, пароходта иде аның. Мылтык,

«ура» тавышлары аны шунда чакырды. Һәм Илсөяр бабасына ялынырга тотынды:

— Бабай дим, бераз гына карап керим инде!

— Ташла... Әллә син аны мәзәк эш дип беләсеңме? Һе... сугыш ич ул.

— Сугы-ыш!..

Пароходта кабат «ура» тавышлары ишетелү белән, Илсөяр тагын тыпырчынырга кереште.

— Бабай, дим, бабакай гынам, җибәр инде, ә, бәгырькәй генәм. Иртәгә үзеңә урманнан бик күп итеп миләш җыеп алып кайтыр идем, бабакай гынам...

— Шаулама, ялгыш пуля килеп тисә үзеңә...

— Бабай, дим, зинһар, җибәр инде, ә? Мин хәзер керәм... Бер әйбер белән керәм.

Бикмүш бабай эндәшмәгәч, күндереп булыр күк күреп, балаларча беркатлылык белән аны кызыктыра башлады.

— Әй миләш, бабай, быел урманда! Үзе чикләвек хәтле эре, үзе кызыл... Ә исе тагы...

— Һе.

— Йә.

— Бик күп итеп җыеп алып кайтырмын, яме, бабай?

Илсөяр, инде күнде бугай дип, чөйдән кыска бишмәтен ала башлады. Бикмүш бабай аның кулын тотты.

— Ә юк, йөрмисең, кызым. Бик тәмле итеп кабартма пешердем, мичтә әнә. Чәй дә шунда. Кайнар килеш ашап эч тә ят, арыгансың.

Юк инде, болай булмады. Илсөярнең нәни генә хәйлә капчыгы бар иде, шуны чишеп җибәрде. Башта ул кабартманы алып ашады (кабартма дөрестән дә тәмле иде, Илсөяр ярата торган — асты кетердәп тора торган), аннан кинәт исенә төшкән булып, бабасын битәрләгән булып, эт өчен кайнар суда апара болгата башлады. «Аны көне буе ач тоткан. Үлмәсә ярый әле менә...» дигән булды ул.

Чыннан да, эт көнозын ач килеш куышта бикләнеп ята икән ич... Монысына инде бабасы да каршы килә

алмады. Илсөяр бишмәтен киде, чиләген алды да, бәхәсләшеп торырга урын калдырмый торган итеп, ишеккә килде. Бикмүш бабай:

— Ләкин, кызым, берүк, су читенә төшмә, ярдан бар,— дип кычкырып калды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Партизаннар һөҗүмгә ничек әзерләнәләр? Илсөяр аларга ничек ярдәм итә?

2. Илсөярнең күзәтү «постында» торгандагы хәлен тасвирлаган урынга игътибар итегез. Ул ни өчен «постын» ташлап китми?

3. Аклар утырган пароходка партизаннар белән бергә тагын кемнәр һөҗүм итә?

4. Партизаннар пароходка ничек үтеп керә алалар? Аларга кем ярдәм итә, нинди хәйлә уйлап тапкан булалар?

5. Илсөяр аклар пароходына һөҗүмне кайдан карап тора? Аның нигә яр буена чыгасы килә? Бабасына ничек дип ялына? Теләгенә ирешү өчен, нинди хәйлә кора?

6. Илсөяр сезнең күз алдына килдеме, ул сезгә ошадымы? Илсөярдә нинди сыйфатлар бар, шулар турында сөйләгез.

7. «Маякчы кызы» әсәрен өйдә тулысынча укып чыгыгыз.

МАЯКЧЫ КЫЗЫ БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

Ямьле Агыйдел буенда, искиткеч матур табигать кочагында урнашкан бәләкәй генә йортта бер гаилә яши. Мәрдән абзый маякларны карап, төннәрен аларның утын кабызып, көндезләрен сүндереп тора, давыл аларны аудармасын, пароходлар сайга утырмасын дип кайгырта. Аның хезмәте кирәкле, әһәмиятле булса да, әсәрдә сөйләнгән сүз аның үзе турында түгел, күбрәк кызы Илсөяр турында. Дөрес, Мәрдән абзый турында да без күп нәрсә белеп өлгерәбез. Ул бердәнбер куанычы булган кызын бик ярата. Алар бергәләп Агыйделдә таң каршылыйлар, су керәләр, Мәрдән абзый кызының бетмәс-төкәнмәс сорауларына җаваплар таба. Иң әһәмиятлесе — ул Илсөярнең үзе кебек көчле, куркусыз булып, хәзердән үк яхшы белән яманны, рәхимсезлек белән шәфкатьлелекне аера белә торган булып үсүен тели. Алар бик кырыс елларда, куркыныч вакыйгалар

уртасында яшиләр. Менә шундый вакытта да кызы югалып, каушап калмаска, гаделлек җиңсен өчен, кулыннан килгән кадәр тырышырга тиеш дип саный Мәрдән абзый. Ул безнең хәтердә ягымлы, кайгыртучан ата булып та, партизаннарга бик зур ярдәм күрсәтүче акыллы, кирәк вакытта хәйләкәр дә була белгән көчле, ышанычлы кеше булып кала.

Мәрдән абзыйның үз этисе — Бикмүш бабай да бездә бик җылы хисләр уята. Улының авыр хезмәтен җиңеләйтеп, оныгының бик якын дусты булып яши бабай. Сез игътибар иттегезме: аның кулыннан килмәгән эше юк. Кирәк булса, ул маякларны карый белә; аучы да һәм балыкчы да ул; өй эчендә хатын-кызлар башкара торган эшләрне дә оста гына эшләп бара. Аның пешергән ипи, кабартмаларының тәмен язучы шундый оста тасвирлап бирә, безнең дә авыздан сулар килә.

Менә шундый ике яклаучысы, кайгыртучысы бар Илсөярнең. Ул үзе дә аларны гаҗәеп ярата, һәр кушканнарын үтәп, аларның тормышын булдыра алган кадәр җиңеләйтеп, ярдәм итеп яшәргә тырыша. Моны ул, бик табигый итеп, бары шулай гына булырга тиеш дип санап эшли. Шуңа күрә аларның бер-берсенә мөнәсәбәте безне сокландыра, тормышта менә шулай булырга тиеш, яшәүнең матурлыгы әнә шулай бер-береңне яратып, кайгыртып яшәүдә икән дип, тагын бер тапкыр нәтиҗә ясап куясың.

Илсөяр үзе дә исеме кебек үк матур бала булып истә кала. Карагыз сез аның шул яшьтән үзен тормышның хуҗасы итеп тоеп яшәвен. Ул табигатьне — Агыйделне, тауларны-болыннарны ярата, урманда исә үзен бөтенләй өйләрендәге кебек хис итә. Табигать тә Илсөярне ярата бит: аннан бер матурлыгын, бер серен, бер хәзинәсен дә яшерми, әйтерсең лә ул — зур бер җан иясе, шушы бәләкәй кызны иркәләп, тәмле җимешләре белән сыйлап, аны саклап үстерә. Илсөярнең куркусыз булуы нәкъ менә табигать белән дус булуыннан киләдер инде: урманнан, караңгыдан, ерак юллардан курыкмау Илсөярне, чыннан да, табигатьнең бәләкәй бер хуҗасы итеп күрсәтә.

Әтисе белән бабакаена да бик кирәк Илсөяр. Ул кайгыртып тормаса, аларга сыенып, иркәләнеп алмаса, Мәрдән абзый белән Бикмүш бабайның тормышы бик күңелсез, кояш нурыннан мәхрүм калган кебек җансыз булыр иде. Аннан соң Илсөяр гел олылар эше булган

хәтәр һәм куркыныч вакыйгаларга да катнашып китә бит әле. Таныш булмаган кешеләр янында баштарак каушап калса да, тиз ияләшә, ничек ярдәм итәргә кирәклеген тиз төшенеп ала. Илсөярне бизи торган бик матур сыйфат — аның башлаган эшен ахырына кадәр җиткерүе. Бу һәрчак, һәркемгә кирәкле сыйфатны Илсөярнең чыныккан характеры дип әйтә алабыз. Җаваплылык хисе аның, бая әйткәнчә, тормышта хуҗа булып яшәве бит инде. Әсәрдә моның мисаллары белән без еш очраштык: урманда партизаннарны тапмыйча кайтмый, көне буе ашамаган икәнлеген дә онытып, партизаннарга ярдәм итеп йөри.

Илсөярнең тагын бер сыйфатына игътибар итми калмагансыздыр. Ул гаять кызыксынучан, тиктормас характерлы кыз. «Кунак бабай»ның кем икәнен белү өчен, бик куркыныч булса да, артыннан күзәтеп бара, аклар пароходына һөҗүм вакытында да, ничек итсә итә, якынрак барып карарга җаен таба.

Сүзне маякчы кызы булу җиңелме дигән сорау белән башлаган идек. Сезнеңчә ничек? Илсөяр генә булып, иркәләнеп кенә, әтисе белән бабасына салынып кына яшәргә өйрәнгән булса, гражданнар сугышы вакыйгалары эчендә калган бу 12—13 яшьлек кызга, әлбәттә, бик кыен булыр, ул әллә нинди фаҗигале хәлләрдә калыр иде. Хикмәт тә аның маякчы кызы булуында; ул үзе турында уйлаудан бигрәк, беренче чиратта, әтисенә зыян килмәсен, бабасына җиңелрәк булсын дип тырыша. Олы җаваплылык хисе аңа иң кыен вакытларда да ярдәмгә килә.

Әсәрнең матурлыгы — менә шундый зур нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә торган нәни батырлыкта. Исегездәдер, Габдулла Тукайның да шул яшьтәге тормышын батырлык дигән идек. Күрәсең, батырлыкның олысы-кечкенәсе булмый торгандыр. Озын юллар да бит бер адымнан башланып китә!

Татар шигъриятенең юл башында сигез йөз ел элек Кол Гали, йөз ел элек Тукай торган. Безнең гасырда аларга алмашка Такташ, Җәлил, Туфаннар килгән.

Бүгенге көн поэзиясенең өлкәннәре рәтендә Хәсән Туфаннан, Сибгат Хәкимнән эстафета алган, аларның «Без сездән риза-бәхил!» дигән сүзләрен ишеткән Илдар Юзеев чордашлары бара.

Илдар Юзеев

(1933—2004)

Укытучы гаиләсендә туып үскән Илдар Юзеев әдәбият белән тиз дуслаша, өченче сыйныфта укыган чагында район газетасында аның беренче шигыре басыла. Әдәбият дөньясының ишеген шулай иртә ачып кергәнгәдер ул, егерме яшеннән үк, хыялларга бай булган шигырь һәм поэмалары белән танылып китә. Кешеләрнең, җир шарының хәсрәт-моңнарын кайгыртырлык зур шагыйрь булып җиткәч тә, Илдар Юзеев ачык, саф күңелле булып кала. Үзе әйткәнчә, ул һәрнәрсәгә сокланып, исе китеп карый, рәхимсезлек, явызлык белән нәфрәтләнеп көрәшә. Шагыйрьләр бер үк вакытта балачакның яктылыгын, җылысын тоеп һәм борчулыгамьле олы дөньяны да күңелләренә сыйдырып яшиләр. Илдар Юзеев үзе турында бер шигырендә:

> Җиргә яңа туган сабый мин
> Һәм сугышта үлгән абый мин,—

дип яза.

Табигать аңа талантны мул итеп биргән. Лирик шигырьләр һәм кызыклы поэмалардан торган егер-

медән артык китабы бар. Бик күп шигырьләренә композиторлар көй яздылар, һәм алар, халыкның үз җырлары кебек, яратып башкарылалар.

Илдар Юзеев драматург буларак та танылды. Җыр кебек моңлы, шигырь кебек тирән мәгънәле пьесаларын илебезнең төрле шәһәрләрендә, зур сәхнәләрдә уйныйлар. «Кыр казлары артыннан», «Сандугачлар килгән безгә» исемнәре кебек үк матур бу әсәрләрне республикабыз тамашачылары да бик яратып карыйлар.

Шигырьләре һәм поэмалары өчен Илдар Юзеевка Татарстанның Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясе һәм республикабызның иң дәрәҗәле бүләге — Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, ә 1993 елда «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелде.

Театр сәнгатен үстерүгә куйган хезмәтләре Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр белән бәяләнде.

Илдар Юзеевның берничә шигъри әсәре белән танышыйк.

БАКЧАЧЫ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Кайчандыр бу урын
Каргалган җир булган,
Таш атып, ут чәчеп
Тетрәгән, убылган.
Язгы кар сулары
Челтерәп акмаган,
Узучы кошлар да
Кунар җир тапмаган.
Көннәрдән бер көнне
Бакчачы карт килде,
Иелде, көрәге
Ташларга төртелде.
Ул — җиргә беректе,
Имәндәй — тамыр нык...
Ташларны йомшартты
Чыдамлык, сабырлык.
Күрделәр: Бакчачы
Куллар килеште —
Җил исте, тир тамган
Ташларга гөл үсте.
Челтери-челтери
Вак ташлар аркылы,
Гөлләрне иркәләп
Акты су салкыны.
Канатлы җырчылар
Төшәр җир сайлады,
Тирәктә, сөенеп,
Былбыллар сайрады.
Матурлык тудырган
Бакчачы хакында
Сөйләде барчасы
Еракта, якында.
...Чу, ни бу? Әллә соң
Күзенә күренә?
Гөлләргә, тирәккә
Еланнар үрелә.

Шаштыра аларны
Өстәге былбыллар,
Богаулый тирәкне
Еланнар-чылбырлар.
Хак сүзме? Ишетә
Ул күрше картыннан:
«Еланнар киләләр
Былбыллар артыннан.
Тынычлап калырсың
Агулы дошманнан.
Бары тик котылсаң
Әнә шул кошлардан».
...Читлекләр куеп ул
Кошларны аулады,
Бер генә былбыл да
Бакчада калмады.
Тындылар былбыллар,
Киттеләр еланнар.
Тынычлап яшәгез
Инде сез, оланнар!
...Акылы: «Дөрес!» — ди,
Ә йөрәк ник боек?
Ник сулган, кош куныл
Тирбәлгән төнбоек?
Шауламый тал-тирәк,
Исми җил, тын — гөлләр.
Назламый сөмбелләр,
Сайрамый былбыллар.
Төзәлмәс бер яра
Ник әрни йөрәктә?
Җырламас шул инде
Ул кошлар тирәктә...
Килсә дә бакчага
Яңа яшь былбыллар,
Юк булган былбыллар
Шикелле кем җырлар?
Тигезсез көрәштә
Ул һәлак булсачы...
Кабере өстенә
Былбыллар кунсачы...
Тирәндә-тирәндә
Хәсрәте, сагышы,
Арттыра газабын
Былбыллар тавышы.
Төзәтер иде ул
Шул еллар ялгышын,
Үзгәртер иде ул
Былбыллар язмышын...
. . . .
Сүрелә дан җыры
Алсу таң нурында,
Ташта гөл үстергән
Бакчачы турында.
Сүрелә дан җыры,
Еракта, якында
Тирбәлә җан җыры
Былбыллар хакында...

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдә тасвирланган вакыйганы сөйләп чыгыгыз. Ничек уйлыйсыз: тормышта чынлап та шундый хәл булганмы әллә әкиятләргә охшаш бу хикмәтле хәлләр уйлап чыгарылганмы?

2. Вакыйгада катнашучыларны санап чыгыгыз, нинди сурәтләр (образлар) үзара бәйләнгән?

3. Әсәрнең теленә игътибар итегез, нинди сүз төркемнәре күп кулланылган?

4. Бу вакыйгалар, геройлар ярдәмендә шагыйрь нинди фикер әйтергә тели, бүгенге көн белән бәйләп, нинди нәтиҗә ясар идегез?

Игътибар иткәнсездер, бу әсәр вакыйгаларының һәм геройларының гадәти булмавы белән аерылып тора. Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигырен, «Ана бәйрәме» поэмаларын исегезгә төшерегез, аларда да шундый ук үзенчәлекләрне күрерсез. Мондый төр әсәрне б а л л а д а дип атыйбыз.

Баллада төрле халыклар әдәбиятына уен җырларыннан, җырлы биюләрдән күчкән. Күбесенчә ул кыска үлчәмгә корылган: шигырь юллары дүрт-биш яки алты иҗектән тора.

Баллада жанрында кискен каршылыкка корылган, эзлекле итеп хикәяләп бирелгән бер вакыйга тасвирлана, ул вакыйга тормыш-көнкүрештә була торган рәвештә түгел, ә әкиятләрдәгечә серле, хикмәтле итеп сурәтләнә.

Балладаның геройлары — җанландырылган табигать күренешләре (җир, таш, диңгез, чишмә, агач, чәчәк һ. б.) яки тереклек ияләре (кошлар, еланнар, төрле җанварлар). Алар үзара сөйләшәләр, бәхәсләшәләр, көрәшәләр. Аларның үз дөньялары бар, ләкин яшәүләренең максаты — Кешегә хезмәт итү һәм, Җирдә явызлык белән көрәшеп, яхшылыкны, хаклык-гаделлекне саклау. Бу көрәштә кайвакыт батыр каһарманнар һәлак була, ләкин нәтиҗәдә яшәү — үлемне, яхшылык — явызлыкны, дөреслек ялганны, хыянәтне җиңә. Кеше кайвакыт зур ялгышлыклар да эшли, моның өчен үкенә, газаплана. Мәсәлән, Бакчачы, еланнар белән үзе көрәшкә чыгып, аларны үзе җиңәсе урында, бакчаның былбылларын-сандугачларын һәлак итә. Бакча корый, җирдән моң югала. Кеше үзенең зур байлыгын — моңын, җан авазын югалта. Шуның өчен үләргә дә риза булып үкенә, йөрәге әрни. Аның Бакчачы, ягъни табигатьне саклаучы, дигән даны да югала.

Илдар Юзеевның тагын бер балладасын укып өйрәнербез. Алда әйтелгән үзенчәлекле якларга игътибар итеп укыгыз.

ЙОЛДЫЗ КАШКА ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Яу кырына килгән Уралдан,
Йолдыз кашка йөргән иң алдан,
Кыю үткән утлар-сулардан...
Ияреңдә батыр генерал,—
Йолдыз кашка йөргән иң алдан.

Көч туплаган дошман яңадан,
Тиңсез гаскәр белән янаган,
Төрле яктан килеп камаган.
Алдан барган батыр генерал,
Ияреңә ауган — ярадан.

Тимер ташкын килгән юллардан,
Төрле яктан кашка уралган,
Боҗра уртасында ул калган.
Һәлак булган батыр генерал,—
Ялгыз атка нинди юл калган?

Тимер боҗра һаман тартыла...
Кашка, кешнәп, күккә атыла.
Күптән хыялланган атына
Менгән яңа хуҗа — илбасар
Шул минутта җиргә атыла.

Фашист генералы ачулы:
Һич баш бирми кашка — ярсулы.
Ни теләсә шул бар: бар солы...
Соңгы чиккә җитә илбасар:
Һич тә аңлый алмый ул шуны.

Бу нинди хәл: ат та буйсынмый,
Агач, тимер сына,— ул сынмый,
Һич төшенми — нинди тылсым бу...
Тирән уйга кала илбасар:
Илләрендә ат та буйсынмый!

Тырышалар соңгы кат алар,
Аулый-аулый тиргә баталар,
Тояк асларында яталар...
Соңгы боерык бирә илбасар:
Таш диварга терәп аталар...

Кашка, кешнәп, күккә омтыла,
Башын чөеп бераз тын тора,
Ава... ава... тагын ул тора...
Куркып, үзе ата илбасар:
Башын җиргә салып, ул тына.

Җыр ишетелә Идел, Уралдан,
Йолдыз кашка узган юллардан,
Яуда ятып калган уллардан:
«Иярендә — батыр генерал,
Йолдыз кашка бара иң алдан».

Каһарманлык ничек онытылсын,
Һәйкәлебез шушы җыр булсын!
Гади җыр бу: юктыр бер тылсым,
Чордан чорга барсын генерал,
Йолдыз кашка күккә омтылсын!

Сораулар һәм биремнәр

1. Балладаның эчтәлеген сөйләгез; вакыйгада кемнәр катнаша, ягъни әсәрнең геройлары кемнәр?

2. Нинди яу турында сүз бара? «Яу», «илбасар» сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз. Аларны тагын нинди сүзләр белән белдереп була?

3. Баллада нинди хисләр уята, нинди нәтиҗә ясап була?

Бу нинди хәл: ат та буйсынмый,
Агач, тимер сына,— ул сынмый.
Илләрендә ат та буйсынмый! —

дигән сүзләрдән нинди фикер аңлашыла? Кайсы ил турында сүз бара, ничек уйлыйсыз?

4. Йолдыз кашка дип нинди атка әйтәләр? Тагын нинди атларны беләсез? Халык иҗатында, әдәби әсәрләрдә тасвирланган ат образларын искә төшерегез.

5. Әсәрдә ничә строфа бар, алар ничәшәр юлдан тора? Кайсы юллар рифмалашкан? Кабатланган сүзләрне, юлларны күрсәтегез.

ГАДЕЛЛЕКНЕ ЯКЛАУ, МАТУРЛЫКНЫ САКЛАУ

Узган дәресләрдә без конфликт турында сөйләшкән идек. Ягъни кемнәр каршылыкка керә, үзара көрәшә; нинди сыйфатлар, төшенчәләр бер-берсенә каршы куела?

Баллада жанрында конфликт бик көчле сурәтләнә, әсәр нинди дә булса көрәшне, хәлиткеч хәлләрне тасвирлауга корыла. Исегезгә төшерегез әле: Бакчачы башта каргалган, тетрәгән, убылган җирне бакча итәргә тырыша, күп көч сарыф итә. Ягъни ул җирне шул хәлгә китергән ниндидер рәхимсез көч белән көрәшә һәм җиңүгә ирешә. Ул бакча үстерә, бакчага былбыллар-сандугачлар килеп, рәхәтләнеп яши башлыйлар. Ләкин берзаман бакчага еланнар иярләшә, бу агулы дошманнар Бакчачыга куркыныч тудыралар. Бакчачы белән агулы еланнар арасында туган бу каршылык көрәш юлы белән хәл ителергә тиеш. Бакчачы агулы еланнардан котыла, ләкин бу тынычлык аңа шатлык китерми, киресенчә, аны кайгыга сала. Ни өчен? Чөнки ул, еланнардан котылу өчен, былбылларны һәлак итә. Күрәсезме, ул еланнарны ж и ң м и, бары алардан котыла гына. Үзен түгел, ә сандугачларны, үзләре дә ярдәмгә мохтаҗ булган җан ияләрен, нинди матур кошларны корбан итә. Бу инде батырлык түгел, бу — куркаклык. Шуңа күрә аны кешеләр гафу итмиләр, хәер, Бакчачы үзен-үзе дә гафу итә алмый. Былбылларны кире кайтарыр өчен, ул үләргә дә риза, әмма соң инде — төзәтеп булмаслык ялгышлык эшләнгән, былбылларга хыянәт ителгән. Вакыйгаларның шундый борылыш алуы конфликтны үзгәртә — Бакчачыда эчке каршылык туа: ул үкенә, әрни, газаплана. Димәк, конфликт, әсәрнең умыртка сөяге кебек, үзенә бик әһәмиятле фикерләрне беркетеп тора. Автор үгет-нәсыйхәт укып тормый, гыйбрәтле хәлне бик оста итеп тасвирлап кына бирә.

Шулай итеп, нинди н ә т и җ ә ясап була? Кешегә тормышта нәрсәгәдер ирешү өчен күп тырышлык куярга кирәк. Ләкин уңышка ирешкәч тә, тынычланып, ваемсыз булып яшәргә ярамый. Җирдә матурлыкка, яхшылыкка, синнән көчсезрәк булган терекләеккә куркыныч янап тора. Кайвакыт явызлык баш күтәрә, синең каршыңа килеп баса. Менә шул чакта инде синең ныклыгың сынала. Син куркып чигенсәң, бәлки вакытлыча тынычлап та калырсың, әмма үзеңә хөрмәт югалыр, яшәвеңнең мәгънәсе бетәр. Яшәү салкын бушлык, кирәксез-кызыксыз гомергә әйләнеп калыр.

Шагыйрь әнә шундый зур хакыйкатьне аңлата безгә. Сак булыгыз, кешеләр, уяу булыгыз, көрәшчеләр булыгыз, ди.

Беренче әсәрдә конфликт вакыйганың үзенә үрелеп бирелгән, аны табып күрсәтү дә кыен түгел. «Йолдыз кашка турында баллада» беркадәр аерылып тора. Конфликт кемнәр арасында бара? Әйе, төп герой Йолдыз кашка белән аны кулга иярләштерергә, үзенә буйсындырырга тырышкан илбасар арасында. Кайсы җиңә? Исән калу яки үлү белән генә бәйләп карасак, Йолдыз кашканы таш диварга терәп аталар, илбасар исән кала (һәрхәлдә, әсәрдә аның үлеме турында әйтелми). Ләкин бөтен хикмәт тә шунда: җиңү ул — зур төшенчә, бер гомер озынлыгы белән генә үлчәнми, ул ерак буыннарга, мәңгелеккә күчә. Дан булып яңгырый, җыр булып әйләнеп кайта, кешелекнең хәтерендә яши. Йолдыз кашка турындагы җыр да аның дошманга буйсынмас, баш бирмәс каһарманлыгын мәңгеләштерә. Шагыйрь нинди матур образ тапкан: кашка кешнәп күккә атыла!

Әсәрдә бит тагын бер герой бар әле. Эзләп таптыгызмы? Нәкъ шулай, Йолдыз кашканың иярендә утырган, яралангач та, җиргә түгел, атының ияренә ауган батыр генерал. Ул төп конфликттан читтәрәк кала кебек. Әмма шагыйрь гаҗәеп бер сәнгатьчә бизәк, әдәби чара уйлап тапкан. Бу «хәйләсен» ул рифмалар төзелешенә яшергән.

Беренче строфаны укыйбыз, юллар тәмамланган сүзләр: Уралдан — иң алдан, сулардан — иң алдан. Дүрт юл үзара рифмалашкан, дүрт сүз бер үк яңгыраашта, «генерал» сүзе берүзе аерылып калган. Башка строфаларны тикшереп карагыз әле, нәрсә күрәсез? 1, 2, 3 строфалардагы һәр дүртенче юл «генерал» сүзе белән тәмам-

лана. Шуннан соңгы биш строфада бу урыннарда «илбасар» сүзе килә. Әйтерсең ул «генерал» сүзен шигырьдән кысрыклап чыгарды, аны «җиңде». Юк икән, соңгы ике строфада «генерал» сүзе үз урынына яңадан әйләнеп кайта. Йолдыз кашка иярендә түгел, ә халык телендә, җыр канатында.

Конфликтның менә шулай автор осталыгы булып гәүдәләнгән төрләре дә була. Аны күреп алу өчен, зиһенне эшкә җигәргә, үткен күзле булырга кирәк.

Нәтиҗә ясыйк.

Баллада — яшәү, тормыш, кешелеклелек турында зур фикерләрне аңлаешлы һәм тәэсирле итеп шигъри формада сөйләп бирүче әсәр. Ул тугрылык, намуслылык, горурлык, ярату яки нәфрәтләнү кебек олы хисләрне тасвирлый. Баллада зур гомумиләштерү көченә ия, аңарда бервакытта да әһәмиятен югалтмый торган сыйфатлар, мәгънәләр турында сүз бара.

Әдәби әсәрләрдә балалар турында күп языла, чөнки тормышның бик күп яклары алар белән бәйле. Шулай да ул әсәрләрнең күбесендә тормышның зур, җитди мәсьәләләре турында сүз бара, олы кешеләр генә хәл итә алырлык катлаулы-каршылыклы вакыйгалар тасвирлана.

Мондый әсәрләрне балалар аңлап, кызыксынып укый алмыйлар. Шуңа күрә зур әдәбиятның бер өлеше балалар өчен дип махсус языла. Анда балаларның үзләре турында сүз бара, гаҗәеп кызыклы, мавыктыргыч һәм хикмәтле балачак дөньясы тасвирлана.

Балалар өчен беренче булып кем яза башлаган дисәк, шунда ук Габдулла Тукай, аның «Сабыйга», «Эшкә өндәү», «Эш беткәч уйнарга ярый» һәм башка бик күп шигырьләре, «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләре искә төшә. Тукайның бу изге эшен дәвам итеп, һәр язучы диярлек балалар өчен шигырь яки хикәя язган. Араларында үзләрен балалар язучысы дип санаган, аларга багышлап әсәрләр язган зур әдипләр дә бар.

Ибраһим Гази
(1907—1971)

«Бер җәйне миңа Ибраһим Газиның Аккош күлендәге дачасында булырга туры килде. Бәләкәй генә йорт тирәли үскән бакчага килеп кергәч, һәр ботакны сырып алган чикләвек-чикләвек карлыганнарга, яфракларны каплап киткән сырга-сырга крыжовникларга, каракучкыл чияләргә, ботакларны сыгып төшергән аксыл алмаларга хәйран калып, хуҗадан сорап куйдым:

— Нигә бу җимешләрне җыеп алмыйсыз инде?

Ибраһим агай, күзлеген сул кулы белән күтәреп, елмайгандай итте:

— Мин — үстерүче. Теләгән кеше үзенә кирәген җыяр әле. Әнә күңелең теләгән куагыңнан рәхим ит...»

Ибраһим Газиның иҗатын өйрәнеп, язучы турында китап язган әдәбият галиме Суфиян Сафуанов сүзләре бу. Тормышта булган вакыйганы яза галим. Шулай да ниндидер хикмәте дә бар бит — язучының иҗаты да, нәкъ бакчасы кебек, төрле җимешләргә гаять бай. Ул үзе дә бакчачы кебек юмарт, мәрхәмәтле кеше булган.

Тугыз яшьтән ятим калып, тормышның михнәтләрен күп күргән Ибраһимның бала чагын бер сүз белән: «бәхетле» яки «бәхетсез» дип кенә аңлатып бетереп булыр микән. Тегесе дә, бусы да җитәрлек һәм үзәкләргә үтәрлек булган. Шуңа күрә дә бүгенгедәй исендә сакланган аның бала чагы. Бу турыда ул, гаҗәеп тә тәэсирле итеп, «Малайлыкта кунакта» дигән автобиографик әсәрендә яза. Югары сыйныфларда сез өйрәнәчәк зур романы «Онытылмас еллар» да үзе кичергән балалык чорыннан башланып китә.

Ибраһим Гази әллә ничә кеше гомеренә җитәрлек катлаулы вакыйгаларның шаһиты була, әмма барыбер бала чагын «без үзебезчә бәхетле идек» дип искә ала. Язучы буларак та бәхетле язмыш кичерә ул, геройлары да шуңа күрә безгә бик якын һәм таныш. Ә бәлки нәкъ сезнең турыда язадыр да әле ул. Хәзер укыячак ике хикәя — балалар әдәбиятының матур үрнәкләре. Әйдәгез, шушы бәхетле, матур дөньяга сәяхәтне башлыйк.

МӘҮЛИЯ НИГӘ КӨЛДЕ?

(Хикәя)

Мәүлиягә быел унике тулды. Кечкенә чагыннан ук аны «дәү әнисе кызы», «чат дәү әнисе» дип аптыраталар иде. Маңгаена табарак сикергән кара кашлары да, чекерәеп торган кечкенә кара күзләре дә — барысы да дәү әнисенеке. Берни булса, үз әнкәсе аңа: «Син минем кызым түгел, дәү әниең кызы, бар дәү әниеңнәргә»,— дип, яисә: «Алай сүз тыңламасаң, тотармын да дәү әниеңнәргә илтеп бирермен, алар кызы булырсың»,— дип, Мәүлияне «куркыта» торган иде.

Тик шулай да бер ягы белән кыз үз әнкәсенә бик охшаган иде. Мәүлиянең әнисе — карт кеше булмаса да, җыен юк-барга ышанучан кеше. Самовар сызгырса, кунак килә. Мәче битен юса, тагын кунак. Козгын кычкырса, бусы инде бөтенләй харап. Берәр төрле бәхетсезлекне көт тә тор.

Борынгылар әйтмешли, алмагачның алмасы бик ерак төшми икән. Мәүлия дә, әнкәсе кебек, җыен чүрт-гүргә ышана иде. Шуның аркасында ул быел, яз көне бер экзаменын бирә алмыйча, көзгә калды.

Болай булды. Май ае иде. Шомырт котырып чәчәк ата иде. Экзамен бирәсе көнне Мәүлия, бусаганы уң аягы белән атлап чыгып, өйалды баскычыннан төште, урамга чыкты. «Әгәр дә хәзер,— дип юрады ул,— күршеләрнең Актырнагы каршыма чабып чыгып, койрыгын өч тапкыр болгаса, экзаменнарны бирә алам». Көн саен кызның каршысына чыга торган Актырнак (Мәүлия аңа гел ипи бирә торган иде) бу юлы да чабып чыкты, койрыгын болгый-болгый, кызның кулыннан икмәкне алды һәм кызны бераз озата барды. «Бирәм икән!»— дип сөенде Мәүлия. Ләкин мәктәп каршындагы коега җитәрәк, кызның баш очында, биектә-биектә, козгын кычкырып җибәрде:

— Коңгыйк! Коңгыйк!

Мәүлиянең төсләре үк агарып китте. Козгын инде ул хәерлегә кычкырмый. Бирә алмый икән! Чырае киткән, бик каушаган хәлдә Мәүлия мәктәпкә килеп җитте. Бик каушаган хәлдә экзаменга керде һәм бирә алмыйча елап килеп чыкты.

Җәй буе укып, хәзерләнеп, бүген ул менә тагын экзаменга бара. Муенына галстугын бәйләде. Бусаганы тагын уң аягы белән генә атлап чыгып, өйалды баскычыннан төште. Урамга чыкты. Бу юлы Мәүлия: «Казык башына киптерергә элгән чүлмәк күрсәм, экзаменымны бирә алам»,— дип юрап куйды. Чыгуга күршеләренең читәнендәге кызыл чүлмәккә күзе төште. Ләкин чүлмәк күрү генә аз булып тоелды, тагын берәр нәрсә юрарга булды.

Мәүлия ерактан ук дәү әниләре капкасыннан бәбкәләрен иярткән каз чыгып килгәнне күрде дә: «Әгәр дәү әни, мин узып киткәндә, читән аркылы карап калса, бирә алам»,— дип юрады.

Болай дип юрауның хәйләсе бар иде. Мәүлиянең дәү әнисе көн саен иртән казларны капкадан чыгарып җибәрә дә үзе, күлгә төшеп баручы каз бәбкәләренә сокланып, артларыннан бер кавым карап тора иде. Тик дәү әнисе көн дә казларны бик иртә чыгара торган иде, ә бүген никтер соңгарак калган.

Мәүлия дәү әниләре турысына җитте. Читәнгә күп итеп керләр эленгән, читән артында кемдер йөри: «Кер сыгып элә икән»,— дип уйлады Мәүлия. «Дәү әни, исәнме!» — дип кычкырып узып китте.

Мәктәпкә бик куанып барып керде. Дәү әнисе читән аркылы карап тормады торуын, тик шулай да читән артында йөри иде бит. Барыбер түгелмени? Экзаменга бер дә курыкмыйча керде, билеттагы сорауларга шатырдатып җавап бирде. Укытучы Әлфия апасы:

— Менә яхшы! Менә тырышкан! — дип, кызга «биш»ле куеп чыгарды.

Мәүлиянең башы түбәгә тия язды. Кайтышлый дәү әниләренә керергә, сөенечен алып чыгарга булды.

Капка турысына җиткәч, ишегалдындагы бабасының сукранган тавышын ишетте:

— Мур кырасы хайван! Кер чәйнәмәсәң, беткәнмени сиңа...

— Бабакай! — дип, Мәүлия йөгереп килеп керде.— Бабакай, «биш»кә бирдем!

— Бик яхшы булган, кызым, бик яхшы. Менә бозауны ачуланам әле, киптерергә элгән керләрне чәйнәгән.

Бабасы шулай диде дә бакча читәненә кашынып торган бозауга таба кизәнде.

— Мин сине! Кит, ышкынма читәнгә! Аударырсың!

— Дәү әни өйдәме? — диде Мәүлия, өйалды баскычына йөгереп менде.

— Дәү әниең бүген таң белән духтырга киткән иде, раюнга. Биле сызлап тора.

Мәүлия аптырап калды. Соң әле иртә белән генә ишегалдында кер сыгып йөри иде ич.

— Юк, кызым,— диде бабасы.— Таңнан юлга чыкты. Менә керне карарга миңа кушып калдырган иде. Карадым... Мин сине! — дип кабатлады ул, читән янында дымлы матур күзләре белән юаш кына карап торган бозауга бармак янап.— Дәү әниең киткәч, өйнең рәте-башы югалды. Чәй дә куеп эчә алганым юк әле.

Мәүлия баягынак читән артында кемнеңдер мыш-мыш килеп азаплануын хәтеренә китерде дә: «Бозауга, дәү әни, исәнме! дип кычкырганмын икән»,— дип, көлмәс җиреннән көлеп җибәрде һәм, ашыга-ашыга, бабасына самовар куярга тотынды.

Сораулар һәм бирем

1. Мәүлиянең кичерешләре сезгә танышмы? Аларны нинди сүзләр белән әйтеп була? Хикәядән ул сүзләрне табыгыз.

2. Төрле юраулар, юк-барга ышанулар каян килә дип уйлыйсыз?

3. Юк-барга түгел, ә үз-үзеңә ышану өчен нишләргә кирәк?

4. Әсәр кем исеменнән хикәяләнә? Хикәяләүченең Мәүлиягә мөнәсәбәте нинди?

ӨЧ МӘХМҮТ

(Хикәя)

Безнең мәктәптә өч Мәхмүт бар. Берсен без яратабыз, хәтта бераз куркабыз да, икенчесен чүпкә дә санамыйбыз, ә өченчесен... Өченчесенме? Анысы турында әйтми торыйм әле, ярыймы? Берсенә Мәхмүт абый дип эндәшәбез, икенчесенә Кәтүк Мәхмүт дип кушамат бирдек. Өченчесен әйтми торырга булдык бит...

Берсе, Мәхмүт абый, дигәнебез, әлеге без шүрли торганы безнең 6 нчы «Б» сыйныфында хезмәт дәресе

укыта, икенчесе үзе безнең белән укып йөргән була. Йөргән була дип мыскыл итебрәк әйтеп ташладым бугай. Мондый дәресләрдә ул бер генә бездән калышмый, табигать дәресеннән хәтта уздырып та җибәрә, ә менә хезмәт дәресенә килгәндә... И, хезмәт дәресе кулыннан килми дә инде бичараның.

Беркөннәре Мәхмүт абый барыбызга да чүкеч ясарга бирде. Әй, җанталашып эшләгән була, Кәтүк Мәхмүтне әйтәм. Өч потлы капчык күтәргән кебек, мыш та мыш килә, маңгаеннан бармак башы-бармак башы тирләр тама, ә үзе, ай киттем, ел киттем, инә буе җир киттем шикелле, бер чүкечне атна буе азапландырды, әле анда да чүкеч урынына... кадак ясап бирде. Әй көлештек, әй көлештек! Мәхмүт абый аның ул кадагын... әй лә, чүкечен безнең чүкечләр белән бергә такта шүрлеккә куйды. Янәсе, күренеп торсын: йодрык хәтле тимердән кадак юнып бирү дә уен эш түгел... Мастерскойга кергән саен, Мәхмүткә көн күрсәтмибез, малайның кабыргасына төртеп: «Кадак кагарга чүкечеңне алып торыйк сана»,— дигән булып, тегене ирештерәбез; үртәгәнне бер тапкыр Мәхмүт абый да ишетте, безгә таба борылып карагач, үзебез дә уңайсызланып калдык, беләсез ич, Мәхмүт абыйдан без шүрлибез.

Юк, Кәтүк Мәхмүттән слесарь чыкмас, мин сезгә моны алдан ук әйтеп куям. Соң ничек слесарь чыксын, башлап торып әле аның куллары инструмент тота алмый, барып ябышты исә, зубило шалтырап идәнгә барып төшә. Беләкләре неп-нечкә, бармаклары салам, ә үзе... әйтәм бит, үзе — җебен сүтеп аткан кәтүк! Верстакка җитәрлек тә буе юк месекенкәйнең! Мин аны, теләсәмме... чәнчә бармагым белән төртеп ега алам, теләмим генә, буяласы килми...

Тәнәфес вакытында урамга чыксак, кемнең маңгаена кар йомарлап кундырганнар — Мәхмүтнекенә! Кемне аяк чалып кар өстенә екканнар — Мәхмүтне! Кемне күче-мала ясап аста калдырганнар — тагын шул Кәтүк Мәхмүтне! Үзе бер дә үпкәли белми тагы, көлеп тик

йөри... Менә шундый бер мәхлук җан инде ул безнең Кәтүк.

Әйттем бугай, мондый дәресләрдә аның теленә шайтан төкергән диярсең: чатыр-чотыр килеп тора. Син, укытучы апа күрмәсен, сорамасын дип, партага сеңеп утырасың, ә ул, Кәтүк башы белән, миннән соратыз, мин беләм дип, кулын күтәрә. Шуның өчен дә без аны яратып бетермибез, ахры... Бөтен сыйныф белмәгәндә, бер ул гына кул күтәреп утырмасын...

Җитмәсә тагын, үзен быел чуп-чуар сипкел басты — бите күке йомыркасы төсле булып калды. Буй дисәң буй, көч дисәң көч юк үзендә, ни пычагыма слесарь булырга уйлагандыр... Аңа кызлар белән бергә өй эшләренә, чигү чигәргә өйрәнәсе калган. Безнең әби, анысы, әйтүен әйтә дә бит, янәсе, хикмәт беләктә түгел, ә йөрәктә дип... Ни генә димәсеннәр, слесарь булу өчен, Мәхмүт абыйныкы кебек чукмарлы йодрык, мускуллы беләк кирәк. Бер йөрәк белән генә бик әллә кая сикереп булмый. Шуның өчен дә шул мин спорт яратам... Чаңгыда чабам, аркылы тимердә уйныйм, әле бокс түгәрәгенә язылырга чамалап торам. Мәхмүт, мескен, аркылы тимергә сузыла да алмый, ә боксны инде әйтәсе дә юк... Бәбиләр йодрыгы хәтле йодрыгы белән ул кемне җиңә алсын.

Кышкы каникулда безне ел саен спорт базасына алып баралар. Безне шефка алган завод базасы ул, шәһәрдән читкә салынган. Әй рәхәт тә була соң урманда чаңгы шуулары! Таулардан ыжгыртып чабып төшүләр дисеңме, егылып китکәндә, баш белән карга кадалулар дисеңме, агач араларыннан борыла-борыла төшкәндә, чаңгы астыннан кар бураннары уйнап калулар дисеңме! Чаңгы шуа белмәгән кешегә аның рәхәтен аңлатып торып булмый инде! Ә сезнең кышкы урманда тук-тук тукран тукылдатканны тыңлап торганыгыз бармы? Яисә песнәк сайраганны ишеткәнегез? Ә саесканның койрыгы ник шул тамаша озын булганны беләсезме? Анысын мин дә белмим.

Каникул җиткәнне, урмандагы спорт базасына барыр көнне без зарыгып көтә башладык. Ай, көткәндә вакыт акрын уза да соң. Андый чакта әллә көннәр юри терәлеп торалар инде? Шулай да барыр сәгатьләр җитте. Автобуска утыртып, безне Аккош күле ягына урманга чаптырып алып киттеләр. Базага без әле иртүк барып җиттек. Чаңгылар алып шуарга чыгып киттек. Шәһәрдә кар пычрак, ә монда ап-ак, очкынланып, җем-җем итеп ята.

Мәхмүт чаңгыда галәмәт кенә йөри икән, ләкин миңа җитү кая! Мин аны ярты юлда ук ташлап узып киттем. Мактанып әйтүем түгел, мактанырга бер дә яратмыйм. Әнә Мәхмүт үзенең чүкече белән мактансын. Мин чынлабрак шуарга тотынсаммы? Мәхмүт абыйның үзен дә узып китә алам. Мин төшкән таулардан ул төшә алмый, беләсегез килсә! Мин, валлаһи әгәр, мактана дип уйлый күрмәгез, нинди текә тау булмасын, юан-юан наратлар нинди тыгыз утырмасын, җилдәй сызгыртып шул наратлар арасыннан очып төшә алам! Ышанмыйсызмы? Килегез, карап торыгыз. Бер генә тапкыр егылсаммы? Гомердә! Шулай да бүген ике тапкыр егылдым. Кәтүк аркасында! Аяк астында бутала бит, нишләтәсең аны... Куып та җибәрмәкче идем, Мәхмүт абый карап тора, уңайсыз. Әйдә йөрсен инде, җан иясе бит дип кумадым. Мин шуган таулардан шуып маташкан була. И бичара... Берсендә шундый чәчрәп барып төште, чаңгылары, ычкынып, тау астына очтылар...

Шуа-шуа карыннарыбыз ачып бетте. Базага кайтырга булдык. Мин Мәхмүт абый белән янәшә кайтам, бүтәннәр безнең арттан киләләр. Чаңгылар астында тыгыз кар, яңа итек кебек, шыгыр-шыгыр итә. Бик күңелле! Мәхмүт абыйны мин яратам, чөнки ул безне бер дә ачуланмый, алай булма, болай бул дип, дилбегә буе акыл да сатып тормый, бер борылып карый, шуңардан барысы да аңлашыла... Бар бит, әй, кешеләр... Анда басма, монда бас, алай борылма, болай борыл дип, ник тегеләй булмадың да ник болай булмадың дип,

теңкәне корытып бетерәләр. Мәхмүт абый андый түгел. Әйтәм бит, борылып бер караса, әле анда да елмаеп карый бит, шул җиткән инде безгә, аңлап алабыз.

Мичләр бездән ягыла калган иде. Кайтып керсәк, әй җып-җылы! Өстәлләр тирәсенә җыелышып, азык капчыкларыбызны бушаттык, термослардан кайнар чәй агызып алып, шикәрне шытырдатып тешләп, чәй эчәргә, ашарга тотындык.

Ашау дигәндә безнең Кәтүк кызык кеше: тавык кебек, аннан бер чукый, моннан бер чукый, шуның белән аның тамагы тук. Битләре кызарып чыга, күзләре елт-елт итә... Ничек җан асрый торгандыр ул, белмим. Шуңа ябык микән әллә ул?

Тамакларны туйдырып, өстәлләрне җыештыргач, барыбыз да Мәхмүт абый тирәсенә килеп өелештек. Аңардан берәр нәрсә сөйләтмәк булабыз. Ул сөйләргә тотынсамы? Әллә ниләр белә ул. Аның авызы ачылуга, без колакларыбызны эләбез дә тынабыз.

— Сез бәхетлеләр, сугыш елларын күрмәдегез,— дип башлап китте ул бу юлы.— Авылда хатын-кыз да бала-чага өелеп калды. Ул чакта мин дә сезнең ише малай гына әле... Тик ул заманда малай дип тормадылар, бик авыр эшләр эшләттеләр. Сугыш бит! Ничек тә дошманның муенын сындырырга кирәк. Безнең колхозда бер ятим хатын бар иде. Ире сугышта үлеп өлгергән, балалары мич башы тулы... Хатынның олы улы, сезнең яшьләрдәге малай, йортта атасы урынына хуҗа булып йөри. Җыелыш җыелса, олылар рәтеннән аны да чакырталар. Урман кисәргәме анда, бүтән авыр эшкәме, олылар рәтеннән аны да җибәрәләр. Хуҗа дияр җире юк инде үзенең. Гәүдәгә кем хәтле дип әйтим? Мәхмүттән бер дә артык җире юк. Ат башына буе җитми, шуннан үзегез аңлагыз инде. Әти-әнисе куштырган исе-

ме белән дә йөртмиләр үзен, кимсетеп, Мутәй дип кенә атыйлар. Берни булса: «Әнә Мутәй килә, бәрде-екты булыр үзегезне!» Янәсе, көче юкка шулай мыскыл итәләр. «Әнә Мутәйне җибәрегез, андый хәтәр эшне Мутәй генә башкарып чыкса чыгар». Гел шулай көләләр иде малайдан.

Ул заманда атлы эштә эшләүчегә тормыш алып бару ансатрак иде. Кәҗәгә булыр дип, тез астына бераз печән салып кайта ала, ягарга утынны да җилкәләп ташымый. Ат, чана үз кулында — урманнан узышлый чана төбенә салып алып кайта... Колхозчылар, кызганып, Мутәйгә дә ат беркеттеләр, буе ат башына җитми дип тормадылар. Егетең сабан да сөрде, сыек кына куллары белән капчык та күтәрде, фермага салам да, печән дә ташыды... Сугыш заманасында нинди эш килеп чыкса, барысын да маташтырды.

Яшьтән үк шулай авыр эшләгәнгәме, ашау-эчү бик такы-токы булгангамы, безнең Мутәй бер дә үсмәде. Иптәшләре егет булып буйга җитте, ә ул, коры елдагы арыш камылы шикелле, җирдән бераз күтәрелде дә катты да калды.

Кайчакны әнкәсе:

— Улым, ник бер дә үсмисең, тирең тегелмәгән ич, үс инде,— дип, гүя үсү-үсмәү малайның үзеннән торган кебек итеп, әйтеп куйгалый торган иде.

Билгеле инде, ятим кешенең яклаучысы да булмый. Еш кына иптәшләре Мутәйне кырын да кагалар иде, аның турында мәзәкләр сөйләп, егетнең күңелен рәнҗетәләр иде. Мутәйнең кешегә күрсәтми генә балавыз сыккан чаклары да булгалады.

Сугыш заманасында, билгеле инде: берәүләрне сугышка алып китәләр, сугышка ярамаганны хезмәт фронтына... Таза кызлар, баласыз киленнәр Уралга, Себергә корал эшли торган заводларга, яшүсмерләр ФЗӨ мәктәпләренә алынып торалар иде.

Кеше сорап районнан кәгазьнең килеп кенә торган көне, ә бит колхозның үз эше дә муеннан, кешеләр җит-

ми, игенне карап үстерергә кирәк. Фронтның да тамагы тук булсын, эшчеләрнең дә... Тизрәк Гитлерның башына җитәргә кирәк ләбаса.

Явып торган кәгазьләрнең берсе безнең Мүтәйгә дә килеп кагылды. Әнисенең бердәнбер олы улы, йортның тоткасы дип тормадылар, аны шәһәргә ФЗӨгә озатырга куштылар. Кемне дә булса озатырга кирәк бит, хөкүмәт сорый. Сохарилар киптереп, елашып, әнкәсе, энеләре Мүтәйне районга озатып калдылар. Иртән озаттылар, кичен малаең ялт итеп кайтып та керде. Алмаганнар егетне, буең юк дип, комиссия уздырмаган. Мүтәй тагын колхоз эшенә йөри башлады. Хуҗа үзе өйдә булгач, йортка акмаса да тамып тора. Терлеккә печәне дә кайта, мичкә — утыны да... Мич башы тулы балаларга — азыгы да...

Тик районнан кәгазь тагын килде бит. Мүтәйне тагын озатып калдылар. Ләкин Мүтәй кичен тагын кайтып керде. Алмыйлар егетне, комиссия уздырмый. Колхоз җитәкчеләренә бу ошап куйды: кеше сорап кәгазь килде исә, кайда әле Мүтәй? Чакыртыгыз әле Мүтәйне! Бар инде энем, син комиссиягә күренеп кайт. Мүтәй бара, күренеп кайта. Районнан кеше дип дәгъвалый башласалар,— «җибәрдек, алмадыгыз». Җавабы кыска.

Бер баруда Мүтәй кайтмады. Сохарилар да киптермичә, елашып та калмыйча озатканнар иде. Мүтәйне алганнар. Инде Мүтәйне дә алгач, авылларда рәтлерәк кешеләр бетеп барадыр, ашады бу сугыш бер хәл кешене. Мүтәй булып Мүтәй дә эшкә ярады дип, авылда бер кавым сөйләшеп йөрделәр дә тындылар. Баштарак Мүтәй шәһәрдә ямансулады бугай, әнкәсенә хатлар язгалап торды. Аерым караватта йоклыйм, өстемдә йон юрган, астымда ап-ак җәймә, тамакка да ярыйсы гына, тимер эшенә өйрәтәләр дип язган иде ул. Аннары хатлары да килми башлады. Югалды Мүтәй. Суга баткан кебек югалды.

— Бөтенләй, бөтенләй югалдымы? — дип сорадым мин, Мәхмүт абыйның сөйләүдән туктаганын күргәч.

Мүтәйне югалтасы килми иде минем, шәһәр җирендә үзенә бирәр эш табып, тик эшләп йөрсен иде шунда үз ишләре арасында... Билгеле инде, ул әллә ни эш майтара алмас иде, безнең кебек әйбәт слесарь да була алмас иде, ну, шулай да бөтенләйгә, бөтенләйгә югалмасын иде. Әллә нәрсә, кызганыпмы, яратыпмы җибәрдем мин шул Мүтәйне! Мескенне эти-әнисе биргән исем белән дә атамыйлар бит. Мүтәй дип кушамат белән генә йөртәләр. Аның чын исеме ничек булды икән соң?

— Мәхмүт абый,— дидем мин, баскан урынымда сикереп куеп.— Ул малайның... ну, егетнең чын исемен белми идегезме?

— Мүтәйнең чын исеме? Мәхмүт иде.

— Мәхмүт? И, ничек бозганнар...

Баядан бирле сорау бирергә матапып, кулын бер күтәреп, бер төшереп торган Кәтүк:

— Мәхмүт абый, бу чынмы әллә үзегез уйлап чыгардыгызмы? — дип кызарынып, сорау биреп ташлады.

— Чын хәл,— диде Мәхмүт абый.— Инде алай бик беләсегез килсә, әйтим, Мүтәйнең үзе табылды...

— Кайда ул, кайда, әйтегез,— дип, без барыбыз да кычкырып җибәрдек.

— Мүтәй сезнең алдыгызда басып тора, Мүтәй ул — мин...

Без аптырадык та калдык. Комиссиядән үтә алмыйча, кире борылып-борылып кайткан Мүтәй белән безнең Мәхмүт абый икесе бер кеше булсын, имеш. Безнең моңа ышанасыбыз килмәде. Шуннан Мәхмүт абый, кесәсеннән кара тышлы дәфтәр чыгарып, безнең алга фотокарточкалар җәеп салды. Кеше рәтеннән Кәтүк тә килеп карточкаларны карап-карап чыкты. Суыкта озак йөргәнгәме, аның колаклары, битләре кыпкызыл булган иде. Күз карашлары да әллә нишләгән иде. Ул әле карточкаларга, әле Мәхмүт абыйның үзенә карап торды. Мин аның шунда ни уйлаганын сиздем: «Мин дә Мәхмүт абый кебек үсәрменме икән, йодрык-

ларым, Мәхмүт абыйныкы шикелле, чукмар-чукмар булырмы икән»,— дип уйлады ул.

Кич белән машинага төялдек тә кайтып киттек. Гаҗәп, шушы вакыйгадан соң без үзебезнең Кәтүккә икенчерәк карый башладык. Элекке шикелле, юкка да, барга да мыскыл итмибез, хезмәт дәресләрендә эш барып терәлсә, иптәшләрчә булышабыз. Кәтүк дигән кушаматы да тора-бара төшеп калды.

Баштук әйткән идем инде: безнең мәктәптә өч Мәхмүт бар. Берсен беләсез — ул безнең Мәхмүт абый, икенчесен дә беләсез — ул безнең кечкенә Мәхмүт. Өченчесе кем соң? Ник аның турында бер сүз дә булмады? Ничек инде сүз булмасын! Өченчесе — мин үзем. Мин дә Мәхмүт ич. Өченче Мәхмүт ошадымы сезгә? Ярыйсы малаймы? Кайсы Мәхмүт яхшырак? Кәтүк Мәхмүтме әллә минме? Мактанып әйтүем түгел, минемчә, мин әйбәтрәк...

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәр кем исеменнән хикәяләнә? Ни өчен автор — Ибраһим Гази «минә шундый малай бар иде» дип үзе сөйләми икән? Аермасын аңлатып карагыз.

2. Кайсы Мәхмүт ачыграк, тулырак һәм җанлырак булып күз алдыгызга килде?

3. Хикәяләүченең Кәтүк Мәхмүткә мөнәсәбәте нинди? Сезнең карашлар бәяләүләр белән туры киләме?

4. Хикәяләүченең сөйләм рәвешен алдагы әсәр белән чагыштырып карагыз. Нинди аерма күрәсез? Сезнең үзара сөйләмегез кайсысына күбрәк охшаган?

5. «Чүпкә дә санамыйбыз», «җанталашып», «күче-мала», «мәхлук җан», «теленә шайтан төкергән», «чатыр-чотыр килеп тора» дигән сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз. Мондый күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне хикәяләрдән үзегез тагын эзләп табыгыз, аларның сөйләмне ничек җанландырып, кызыклы итеп җибәргәнлекләренә игътибар итегез.

6. Өченче Мәхмүт сезгә ошадымы? Ни өчен икәнен аңлатыгыз.

ХИКӘЯЛӘҮ ОСТАЛЫГЫ

Зур күләмле проза әсәрләрендә — повесть яки романда — безне беренче чиратта автор н ә р с ә турында яза, нинди вакыйгаларны тасвирлый, геройлар нинди кешеләр, аларның гомерләре нинди шартларда, ничек уза дигән сораулар кызыксындыра. Мондый әсәрләрдә зур тормыш вакыйгаларын, катлаулы язмышларны сыйдырырлык киң мәйдан, мөмкинлекләр бар.

Хикәя жанры исә нечкә сызыклар ярдәмендә ясалган нәфис рәсем кебек. Гадәттә, без анда бер тавышка хикәяләүченең, ягъни вакыйганы сөйләүченең, тавышына колак салабыз. Аның нәрсә турында сөйләве дә кызыксындыра, әлбәттә, шулай да без, әкиятчене тыңлаган кебек, аның сөйли белү осталыгына күбрәк игътибар бирәбез. Юк кына вакыйганы да матурлап, бизәкләп, бераз арттырып та җибәреп, үзенең бәясен дә сиздереп, кыскасы: тыңлар өчен кызыклы итеп сөйли белүчеләр була. Бу инде — үзе бер сәләт, осталык. Язучыларны без шуңа күрә рәссамнар дип тә атыйбыз. Алар, рәссам кебек, сүзләрдән сурәт ясыйлар, сөйләгәннәрен без күреп торгандай булабыз. Димәк, **хикәяләү** дигәндә без язучының н и ч е к сөйләвен, кем исеменнән, кем булып сөйләвен дә күздә тотабыз.

«Мәүлия нигә көлде?» хикәясендә Мәүлиянең кызык бер гадәте турында автор үзе сөйли. Без аның олы яшьтәге кеше икәнлеген нинди сүзләр белән сөйләвеннән үк чамалап алабыз. Мәсәлән, ул «Борынгылар әйтмешли, алмагачның алмасы бик ерак төшми икән» дип, тәҗрибәле кеше, Мәүлияне читтән генә күзәтеп торучы булып сөйли. Вакыйгаларга үзе катнашмый, үзенең карашларын да белдереп бармый. Өстәвенә, бик кызыклы итеп, бабайны да сөйләндереп ала.

Кара инде, нинди юктан гына тора Мәүлиянең имтиханын бирә алмавы. Үзен читтән карап тора алса, шулай юк-барга ихлас ышануыннан Мәүлия үзе дә көләр иде. Хәер, имтиханын бирергә «ярдәм итүченең» әбисе түгел, бозау икәнлеген белгәч, ул көлмәс җирдән көлеп җибәрә бит. Үз хәлеңнән көлә белү ул шулай ук үзеңә читтән торып карый белү инде. Без дә бит Мәүлиядән көлгәндә уйлап куябыз: үзебез дә Мәүлия хәлендә түгелме икән?

«Өч Мәхмүт» хикәясе бераз катлаулырак, андагы фикерләр дә әһәмиятлерәк, геройлары да өчәү. Автор

барысына да нигә бер үк исем бирде икән? Укучысын «адаштыру» өченме? Юк, ул өч героен баштан ук янәшә куеп чагыштыра башлый. Уртага Кәтүк Мәхмүтне куя, чөнки хикәяләүче аның турында күп сөйли, беренче карашка, гел аның турында гына сөйли дә кебек.

Шулай да безнең игътибарны Кәтүк Мәхмүткә караганда, «күрегез инде бу булдыксыз малайны» дип, кызып-кызып үзенең аннан шәбрәк икәнлеген исбатларга тырышучы өченче Мәхмүт күбрәк җәлеп итә. Чөнки хикәяләүче ул үзе, шуңа күрә без аның «авызына карап» торабыз, ул үзе дә гел безгә эндәшеп, тыңламас җиреңнән тыңларлык итеп сөйли.

Әйдәгез, бу өч Мәхмүтне аңлап, бәяләп карыйк. Укытучы Мәхмүт кемгә дә охшарлык — ул барысына да тигез карый, Кәтүк Мәхмүтне дә кыерсытмый, аны дәртләндерергә, күңелен күтәрергә тырыша (чүкеч вакыйгасын исегезгә төшерегез). Гомумән, сабыр, ягымлы һәм ышанычлы кеше.

Кәтүк Мәхмүт ниндирәк булып күз алдыгызга килде? Ул чынлап та бәләкәй буйлы, физик яктан әллә ни мактанырлыгы юк. Шулай да юкка-барга үпкәләми, иптәшләренең үртәвенә дә елмаеп кына карый, бик исе китми. Чөнки ул алай булдыксыз да түгел бит: яхшы укый, чаңгыга басса да, башкалардан калышмый. Кыскасы, ихлас күңелле, шат табигатьле малай булып күренә ул.

Ә менә өченче Мәхмүт белән эш катлаулырак тора. «Мактанырга яратмыйм» дип кабатлап торса да, үзенең көче, чаңгыда шәп шуувы белән масаерга ярата, мактана торгач арттырып та җибәрә. Шул ук вакытта ул алдакчы да түгел бугай: мәсәлән, белем ягы чамалы икәнлеген ул яшерми. Укытучысына мөнәсәбәте дә сизгер, ихтирамлы (күз карашыннан ук аңлап ала). Өстәвенә бик кызыклы итеп сөйли; шул сөйләм рәвешеннән чыгып, аның бик тере, хәрәкәтчән, күзәтүчән, мавыгучан малай икәнлеген күреп алабыз. Ул кайнарланып, сорау һәм өндәү җөмләләрне әнә ничек мул итеп сибеп, үзен дәртләндереп, үзен дә ышандырып сөйли.

Әсәр барышында бу Мәхмүт безгә көтелмәгән яктан ачылып китә: укытучысы сөйләгән, үзенә бөтенләй таныш булмаган Мүтәйне ул ничек кызгана! Хаксызга рәнҗеткәннәр бит Мүтәйне, исемен дә танымаслык иткәннәр. Үзе гаеплемени шундый кечкенә буйлы булып

калуына ул малай? Олы кешеләр генә тарта алырлык йөкне җилкәңә күтәреп кара әле син?! Гаделсезлек безнең Мәхмүтнең күңелен кузгатып җибәрә, ярдәм итәсе килә аның Мүтәйгә.

Кеше күңелендәге кызгану хисе, хаксызга рәнҗетелгәннәрне яклау теләге, гаделлек җиңсен өчен, нәрсәдер эшләргә тырышу, кешеләр язмышына битараф булмау — иң кирәкле сыйфатлар, иң зур байлык, матурлык. Югыйсә туң йөрәкле булып калачаксың.

Без үзебез турында да уйланмый кала алмыйбыз. Арабызда Мәхмүтләрнең тегесе дә, бусы да бардыр, әлбәттә. Тар күңеллелек күрсәтеп, көчсезләрне кыерсытмыйбызмы, иптәшләребезне рәнҗетмибезме? Иптәшеңне мыскыллау, гомумән, егетлек түгел, өстәвенә син авыз ерып көлеп йөргән арада үзгәреп тә куя бит әле ул синең «мескенең». Олыларның гасырлар буена җыелган тормыш тәҗрибәсе беркайчан да ялгышмый, чынлап та бит,— хикмәт беләктә түгел, йөрәктә!

Күрәсез, талантлы язучы сүз ярдәмендә укучының җаны, акылы белән ничек оста идарә итә. Зур фикерләрне, нәтиҗәләрне, гыйбрәт һәм акылны ничек сиздермичә, ягъни «дилбегә буе» үгет-нәсыйхәт сөйләмичә генә, безнең күңелләргә салып куя. Әдәбиятның көче, әһәмияте, кирәклеге нәкъ әнә шунда да инде.

Фәйзрахман Әминев. Су буе.

Бакый Урманче. Салтык болыны.

Һәр халыкның күренекле әдипләре, зур шәхесләре бар. Алар — үз милләтенең талантлы, көчле рухлы һәм шигъри җанлы икәнлеген бөтен дөньяга раслап торучылар.

Телләре, гореф-гадәтләре белән татар халкына якын, аңлаешлы булган тугандаш төрки халыкларның шундый язучылары белән без дә кызыксынабыз, аларның иҗаты, халыкларының тормышы, культурасы белән танышып, аралашып яшибез. Татар укучысына бик таныш булган шундый шәхесләрнең берсе — күренекле кыргыз язучысы —

Чыңгыз Айтматов

(1928 елда туган)

Кыргыз халкының иң күренекле вәкилләреннән берсе, илебездә генә түгел, бөтен дөнья әдәбиятында танылган зур әдип, актив җәмәгать эшлеклесе Чыңгыз Айтматов дала киңлекләренә урнашкан кышлакта туа, бала чагы да шунда үтә. Әтисе — Теркел Айтматов Кыргызстанның беренче большевикларыннан була, үз халкына намуслы хезмәт итә. Әнисе Нәгыймә апа балаларын белемле, хезмәт сөючән итеп тәрбияли. Бик иртә әтисез калган Чыңгыз ун яшеннән колхоз кырында эшли, ундүрт яшендә аны авыл Советы секретаре итеп куялар. Тормыш үзе белем кирәклеген гел искәртеп тора — Чыңгыз Айтматов башта техникумда, аннан соң институтта укый. Алган белеме авыл хуҗалыгы белән бәйле булса да, Чыңгыз институтта укыган чагында ук мәкаләләр, очерклар яза, аларны газета-журналларда бастырып чыгара. Шулай итеп ул зур әдәбият дөнья-

сына чыга. Мәскәүдә әдәби курсларда уку аның осталыгын арттыра, бу чорда яшь язучының хикәя, повестьлары рус телендә басыла, төрле телләргә тәрҗемә ителә.

Чыңгыз Айтматов 60 нчы еллардан алып гаять күп һәм тиз язды. Берсеннән-берсе кызыклы әсәрләре аны бөтендөнья әдәбиятының күренекле язучысы итеп танытты. Талантын, куйган хезмәтләрен югары бәяләп, Чыңгыз Айтматовка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде, ул Ленин премиясе белән бүләкләнде, Кыргызстан Фәннәр академиясенең академигы дәрәҗәсенә күтәрелде.

Татар укучысы да Чыңгыз Айтматов иҗатын яратып, үз итеп кабул итте. Аның күп әсәрләре татар теленә дә тәрҗемә ителде. «Җәмилә», «Анам кыры», «Кызыл яулыклы гүзәлкәй генәм», «Ахырзаман» («Плаха») әсәрләре радио аша да яңгырыйлар, театр сәхнәләрендә дә уйналалар.

Хәзер сез «Беренче мөгаллим» повестеннан өзекләр укырсыз. Кыргыз халкының тормышыннан алып тасвирланган вакыйгалар ярдәмендә изге күңелле, мәрхәмәтле булу иң кирәкле, кешелекле сыйфат икәнлегенә игътибар итәрсез.

БЕРЕНЧЕ МӨГАЛЛИМ

(Повестьтан өзекләр)

Бу вакыйга 1924 елны булды. Әйе, яхшы хәтерлим. Нәкъ шул елны булды. Ул чакта, хәзер безнең авыл утырган җирдә, ун-унбишләп ярлы-ятаклар[1] торалар иде. Мин ундүрт яшьлек үсмер кыз идем һәм мәрхүм атаемның туганнан туган агасы кулында тора идем. Минем әнием дә ул чакта юк иде инде.

Шул елның көзендә, баерак хуҗалар кышлар өчен, малларын куып тауларга күчеп киткәч, безнең авылга солдат шинеле кигән бер егет килде. Мин аның шинелен бик яхшы хәтерлим, чөнки ул кара сукнодан тегелгән иде. Барлык юллардан читтә, каядыр таулар

[1] Ярлы-ятак — күченеп йөрү өчен, маллары һәм мөмкинлекләре булмаганга, бер урында яшәп ятучы ярлылар.

итәгендә утырган кечкенә авылга шинель кигән кешенең килүе үзенә күрә бер вакыйга булды.

Башта аны армиядә командир булган, авылга да начальник булыр өчен кайткан кеше дип сөйләделәр. Ә соңга табарак: «Юк, бу егет командир да, начальник та түгел икән, ә теге ачлык елны тимер юлга күчеп киткән Таштинбәкнең улы Дүшән икән, хөкүмәт аны, солдат хезмәтеннән бушатып, авылга балалар укытыр өчен мөгаллим итеп җибәргән икән»,— дип сөйли башладылар. Ул заманда «мәктәп», «укыту» дигән сүзләр безнең өчен бик яңа сүзләр иде, ә күпләр исә аларны юньләп төшенеп тә бетмиләр иде. Бу ишеткәннәр чынмы-ялганмы, ышаныргамы-юкмы дип торган арада, беркөнне авыл халкын җыенга чакырдылар. Минем агам: «Ай, бу нинди җыелыш тагын, гөнаһ шомлыгы!» — дип зарлана-зарлана атына менде дә китеп барды, аның артыннан бала-чагалар иярделәр, аларга кушылып мин дә йөгердем. Без барып җиткәндә, биш-алтысы атка атланган, калганнары җәяүләп кенә килгән кешеләр уртасында әлеге кара шинель кигән ак чырайлы егет нидер сөйләп тора иде. Шул чакта тыңлаучылар арасыннан каткан тире тунлы бер карт егетнең сүзен бүлде:

— Карале, улым,— диде ул, ашыгудан бераз тотлыгыбрак,— элек балаларны мулла укыта иде, ә без синең атаңны яхшы беләбез, ул да бит нәкъ безнең төсле бер томана[1] иде... Кай арада әле син мулла булып өлгердең?

Дүшән картка таба борыла төшеп җавап бирде:

— Мин мулла түгел, аксакал[2], мин — комсомол. Хәзер балаларны мулла урынына мөгаллим укытачак. Мин армиядә укырга-язарга өйрәндем, менә минем муллалыгым шул.

— Ә бу ярый...

— Бусын яхшы иткәнсең,— диештеләр арадан кайберәүләр, егетне куәтләп.

---

[1] Томана — укый-яза белмәгән, надан кеше.

[2] Аксакал — олы яшьтәге кешегә хөрмәтләп дәшү.

— Мена комсомол мине мөгаллим итеп, балалар укытырга җибәрде. Ә моның өчен безгә мәктәп кирәк. Мин үзем әнә теге түбә җирдәге иске сарайны, сезнең ярдәмегез белән, мәктәп итеп корырга уйлап торам. Ни әйтәсез, авылдашлар, киңәшләрегезне бирегез!

Кешеләр, бу егет нәрсә кыйратмакчы[1] була, дигән төсле бераз уйланып тордылар. Шул чакта баядан бирле җыендагы сүзләргә колак салып, иярена таянып утырган Сатымкол агай сыңар күзен йома төшеп һәм теш арасыннан гына бер төкереп әйтеп куйды:

— Туктале, егет, синең укытуың безгә нигә кирәк соң әле ул?

Дүшән бу көтелмәгән сорауга ни әйтергә белмичә аптырап калды.

— Чыннан да шулай бит,— диештеләр арадан кемнәрдер. Халыкның берише кузгалышып шаулашырга тотындылар.

— Без — борын-борыннан китмән белән тамак туйдыручы дихканнар[2]. Безнең балаларыбыз да шулай яшәрләр. Аларның түрә[3] буласылары юк, уку нигә аларга? Син инде, егет, безнең башны юк-бар белән катырма!

Дүшән гаҗәпләнүдән бу кычкыручыларның әле берсенә, әле икенчесенә туп-туры карап торды:

— Сез, чынлап та, балаларыгызны укытуга каршы торасызмы?

— Торсак ни, әллә көчләп кушар идеңме? Ул заманнар үтте инде. Без хәзер ирекле халык, ничек теләсәк, шулай торачакбыз!

Дүшәннең йөзенә кан йөгерде. Шинеленең каптырмаларын ашыгып ычкындырды да, эчке кесәсеннән дүрткә бөкләгән бер кәгазь чыгарып, шуны халыкка селкеп күрсәтте:

— Димәк, сез мена бу совет печате басылган, балаларыгызны укытырга кушкан язуга каршы киләсез?

---

[1] Кыйратмакчы — башкармакчы, эшләмәкче.

[2] Дихкан — крестьян.

[3] Түрә — башлык, идарә итүче.

Ә кем сезгә ирек бирде, җир-су бирде? Йә, кем Совет властеның законына каршы бара? Җавап бирегез!

Ул соңгы сүзен шундый ачу белән әче итеп кычкырды ки, тавышы, атылган уктай көзге тын һаваны ярып, таш-кыяларга барып бәрелгәндәй булды. Берәү дә сүз әйтергә җөрьәт итмәде[1], барысы да башларын иеп тик тордылар.

— Без ярлы халык,— диде Дүшән, тавышын баса төшеп,— без гомер буе изелеп, тапталып, караңгыда яшәдек. Ә хәзер Совет хөкүмәте безне яктыга чыгарырга, күзләребезне ачарга тели. Менә шуның өчен без балаларыбызны укытырга тиешбез.

Дүшән «йә, шулай түгелме» дигән төсле беразга туктап калды. Әлеге каткан тун кигән, кайчан әле син мулла булдың дип сораган карт килешкәндәй әйтеп куйды:

— Ярый инде алайса, бик теләсәң укытырсың, безгә ни. Без законга каршы түгел.

— Ләкин мин сезнең ярдәм итүегезне сорыйм. Безгә әнә теге тау түбәсендәге, байдан калган абзарны мәктәп итеп төзәтергә кирәк, инеш аша басма салырга кирәк, кышлык утын әзерләргә кирәк.

— Туктале, егет, син алай бик зурдан купма,—диде әлеге гел кирегә тырнаучы Сатымкол. Аннары, тагын теш арасыннан гына черт төкереп, атарга җыенгандай, бер күзен кыса төште:

— Мәктәп ачам, имеш! Кем син ул кадәр? Өстеңдә туның, астыңда атың юк[2], бер карыш сөргән җирең, бер баш малың юк. Ничек кенә яшәмәкче буласың син, чибәр егет? Кеше малы куыпмы?.. Ләкин бит безнең куарлык малларыбыз юк. Маллы кешеләр тауларга китеп беттеләр.

Дүшән моңа каршы бик усал итеп җавап бирмәкче булган иде дә тыелып калды. Бары әкрен генә әйтеп куйды:

---

[1] Җөрьәт итмәде — батырчылык итмәде, кыюлыгы җитмәде.

[2] Астыңда атың юк — атланырга атың юк.

— Торырмын әле ничек тә... Хөкүмәттән эш хакы алырмын.

— Ә-ә, күптән шулай диярга кирәк иде! — Сатымкол, җиңеп чыккан бер кыяфәт белән, ияре өстендә турая биреп утырды.

— Менә хәзер аңлашылды. Алайса инде син, егет, әнә шул хезмәт хакына мәктәбеңне дә ач, балаларны да укыт. Казнаның[1] акчасы барысына да җитәр. Ә безне юкка борчыма, безнең үз мәшәкатебез дә баштан ашкан.

Шулай диде дә атын борып китеп тә барды. Бүтәннәр дә аның артыннан ияРделәр. Ә Дүшән, бичара, кәгазен тотып, ялгызы гына торды да калды. Шул чакта мин аны бик кызгандым, күзләремне алмыйча аңа, кая барыр, нишләр инде бу дип, тик карап тордым. Бары агам аты өстеннән миңа: «Нәрсә син монда авызыңны ачып торасың, көнҗәлә[2] баш!» — дип кычкыргач кына, мин башка балалар артыннан йөгердем.

Икенче көнне без, кызлар, инеш буена төшкәч, шунда Дүшәнне күрдек. Ул көрәк, китмән һәм бер иске чиләк тоткан килеш инешне кичеп, калкулыкка таба китеп бара иде.

Шул көннән башлап, без аны ялгызын гел шул тау түбәсендә күрә торган булдык. Тик караңгы төшкәч кенә ул, елга аша чыгып, авылга кайта иде. Еш кына без аның, бау белән бәйләп, аркасына кура[3] яки салам күтәреп барган чагын да күрә идек. Ерактан аны шәйләп алган кешеләр, өзәңгеләренә басып һәм кулларын күз өстенә куеп, бер-берсеннән гаҗәпләнеп сорыйлар иде:

— Карагыз әле, әнә теге аркасына салам күтәреп барган кеше мөгаллим Дүшән түгелме соң?

— Шул үзе.

— Һай, бичара. Мөгаллимлек эше дә ансаттан түгел, күрәсең.

---

[1] Казна — хөкүмәт.

[2] Көнҗәлә — тузган чәчле.

[3] Кура — кипкән дала үсемлеге, ягар өчен файдаланыла.

— Шулай булмыйча... Кара син аны, бай ялчысыдай, аркасына күпме төягән.

— Ә сүзләрен тыңласаң, әллә кем дип белерсең!

— Аның кулында пичәтле кәгазь бар бит, шуңа таяна инде ул.

Бервакытны без, кызлар, далада капчык тутырып кизәк[1] җыйганнан соң, авылга кайтышлый, мөгаллим нишли икән дип, шул калкулыкка күтәрелдек. Балчык белән сыланган мондагы иске сарай кайчандыр бер байның елкылар[2] абзары булган. Кышкы бураннарда колынлаган бияләрне шушында китереп япканнар. Совет власте булганнан соң, бай каядыр күчеп киткән, ә иске сарай тора да тора әле. Тирә-ягын кычыткан, әрекмән, тигәнәк басып бетергән, күптән инде бу җиргә аяк баскан кеше дә юк иде. Хәзер килеп карасак, ни күрик, сарай әйләнәсендәге чүп үләннәр уталып беткән, бер читкә өеп куелган, тирә-як чистарып калган, ә сарайның яңгырдан кубып төшкән стеналары яңа балчык белән сыланган, каерылып яткан ишеге әйбәтләп тупсасына утыртылган иде.

Без, капчыкларыбызны җилкәдән төшереп, ял итәр өчен җиргә утырырга да өлгермәдек, ишектән балчыкка буялып беткән Дүшән үзе килеп чыкты. Безне күреп, ул башта бераз гаҗәпләнеп калды, аннары битендәге тирен сөртә-сөртә елмаеп дәште:

— Кайдан сез болай, кызлар?

Без бер-беребезгә карашып алдык. Оялудан җавап бирмичә торуыбызны сизеп, Дүшән безгә күз кысып куйды.

— Капчыкларыгыз үзегездән дә зур икән... Ярый, яхшы иткәнсез, кызлар, монда килеп. Сез укый торган мәктәп булачак инде бу... Мәктәбегез әзер дисәк тә ярый... Менә әле бер почмакка мич сыман нәрсә салдым, әнә күрәсезме, озын морҗасы да чыгып тора. Хәзер

[1] **Кизәк** — ат яки башка мал тизәге, ягар өчен ярый.
[2] **Елкы** — ат.

инде кышлык утын әзерлисе генә калды, шәт, ансы да булыр, далада кура күп ич! Ә идәнгә калынрак итеп салам түшәрбез, шуннан соң укуны башлап җибәрергә дә була. Йә, әйтегез, укырга йөрерсезме?

Мин арада зуррак идем, шуңа күрә беренче башлап җавап бирдем:

— Җиңгәм җибәрсә йөрермен,— дидем.

— Йә, ник җибәрмәсен ди, җибәрер. Ә исемең ничек синең?

— Алтынай,— дидем мин, күлмәк ертыгыннан күренгән тиземне итәгем белән каплап.

— Алтынай — матур исем,— диде ул һәм, ничектер, бик ягымлы итеп елмайды. Аның елмаюыннан хәтта йөрәк җылынып киткәндәй булды.

— Ә кем кызы соң син?

Мин җавап бирмәдем: кешеләрнең миңа кызганып карауларын яратмый идем. Минем өчен кызлар җавап бирделәр.

— Ул — ятим кыз, агасында тора.

— Алайса, менә нәрсә, Алтынай,— диде Дүшән, тагын елмаеп.— Син бүтән балаларны да мәктәпкә дәш, ярыймы?.. Сез дә, кызлар, килегез, яме!

— Ярый, агай.

— Мине мөгаллим дип йөртерсез. Ә хәзер мәктәпне карыйсыгыз киләме? Курыкмагыз, керегез.

— Юк, без китәбез, өйгә кайтырга кирәк,— дидек без, уңайсызланып.

— Ярый, алайса, барыгыз. Укырга килгәч күрерсез инде. Ә мин, караңгы төшмәс борын, далага барып, кура алып кайтыйм әле.

Дүшән бау белән урак алды да кырга таба китте. Без дә торып, капчыкларыбызны күтәреп, авылга таба атладык. Кинәт минем күңелемә бер уй килде.

— Туктагыз әле, кызлар! — дидем мин иптәшләремә.— Әйдәгез, кизәкләрне мәктәпкә бушатып калдырыйк.

— Ә өйгә буш кул белән кайтыйкмы? — диделәр кызлар.— Кара син аны, акыллы башны!

Һәм, мине көтеп тә тормыйча, алар тизрәк өйләренә кайтып киттеләр.

Хәзергә кадәр әле мин шул чакта кызлардан ни өчен аерылып калуымны аңлап җиткәнем юк. Аларның мине тыңламыйча китүләренә үпкәләпме әллә булмаса бик кече яшьтән үк тупас кешеләр тарафыннан гел изелеп, кыйналып, үзем теләгәнне бервакытта да үти алмыйча килгәнгә күрәме, белмим, әмма минем кинәт шул билгесез кешегә, елмаеп йөрәгемне җылытуы өчен, миңа бер-ике генә авыз җылы сүз әйтүе өчен рәхмәт йөзеннән бер яхшылык эшлисем килде. Һәм, мин беләм, мин аңлыйм хәзер, нәкъ шул көннән, шул бер капчык кизәктән минем киләчәк язмышым, шатлык һәм газаплар белән тулы яңа тормышым башланды. Чөнки нәкъ шул көнне мин гомеремдә беренче тапкыр һич икеләнеп тормыйча һәм берәүдән дә курыкмыйча үзем кирәк дип тапканны, үзем теләгәнне эшләдем. Кызлар ташлап киткәч, мин тиз генә борылып, капчыктагы кизәкләремне Дүшән мәктәбенә илтеп бушаттым да, яңадан кизәк җыяр өчен, тау итәгенә, чокыр-чакыр буйларына чаптым.

Әйтерсең зур бер изгелек эшләгәндәй, мин йөрәгемдә гаҗәп бер шатлык, тәнемдә искиткеч бер җиңеллек тоеп, аякларымның кая басканын да, кая чапканымны да белмәдем. Гүя кояш та минем бу шатлыгымны күреп тора иде. Юк, чынлап та, кояш минем ни өчен бу кадәр сөенеп, рәхәтләнеп җилдәй очып йөрүемне, һичшиксез, белгәндер. Мин бит, кечкенә генә булса да, бер изгелек эшләдем.

Кояш инде дала түренә төшеп бара иде, ләкин ул, мине күргәч, юри батарга ашыкмый кебек иде, ул минем юлымны яктырта, иске бишмәтемнең ак төймәләрендә җем-җем чагыла, йөземнән, маңгаемнан иркәләп сөя иде. Ә мин чабам да чабам, куанычымнан үземне белештермичә җиргә, күккә, җилләргә эчемнән генә

кычкырам: «Карагыз сез миңа, карагыз! Мин нинди бәхетле! Мин укырга барачакмын, мин мәктәпкә йөреячәкмен, үзем генә түгел, бүтәннәрне дә артымнан ияртәчәкмен!..»

Сораулар һәм биремнәр

1. Геройларның исемнәренә игътибар итегез. Дүшән, Сатымкол, Алтынай — бу кыргыз исемнәрен дөрес итеп әйтегез. Нинди сүзләрдән ясалган? Шуны билгеләп карагыз.

2. Ни өчен Дүшән балаларны укытырга тели? Аның бу теләгенә кемнәр каршы килә һәм ни өчен? Аларның әйткән сүзләрен укып күрсәтегез.

3. Дүшәннең яклаучысы бармы? Ул кемгә, нәрсәгә таяна?

4. Сез ничек уйлыйсыз: ни өчен Дүшәнгә олылар ярдәм итми, ә Алтынай үзе теләп аңа булыша башлый? Әсәрдән шул урынны табып укыгыз.

5. Алтынайның нинди хәлдә яшәгәнлеген кайсы җөмләләрдән белеп була?

6. Ни өчен Алтынайның күңеле күтәрелеп китә, һәм ул үзен канатлангандай хис итә?

Беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, мөгаллим безне салам җәйгән идәнгә утыртты, һәркайсыбызга берәр дәфтәр, каләм һәм кара такта бирде.

— Такталарыгызны тез өстенә куегыз, язарга уңай булыр,— диде ул безгә. Аннары стенада эленеп торган бер рәсемгә күрсәтте: — Бу — Ленин!

Шушы рәсем гомерем буена минем күңелемдә сакланып калды. Соңыннан мин бервакытта да ул рәсемне ни өчендер бүтән күрмәдем, шуңа, ахрысы, мин аны хәзер дә «Дүшәннеке» дип йөртәм. Бу рәсемдә Ленин иркен генә френч киеп, яралы кулын кара чүпрәк белән муенына асып төшкән иде. Сакалы җиткән, йөзе сулган, кепкасын бераз арткарак этәргән. Күзләре кешегә бик туры, тыныч карый, һәм бу җылы бөркегән йомшак караш безгә гүя: «Белсәгез иде сез, балалар, киләчәктә

сезне нинди матур тормыш көтә!» — дип әйтеп тора кебек иде. Чыннан да, шул рәсемгә караган саен, гүя минә Ленин минем киләчәгем турында уйлана кебек тоела иде миңа.

Дүшән бу гади кәгазьгә төшерелгән рәсемне күптән үзендә саклап йөрткән булса кирәк, аның чит-читләре тузып, кырылып беткән иде инде. Шуңардан башка мәктәп стенасында бүтән бер рәсем дә юк иде.

— Мин сезне, балалар, хәреф танырга, саннарны аерырга, укырга, язарга өйрәтермен,— диде Дүшән безгә.—Кыскасы, үзем белгәннең барысына да өйрәтермен.

Һәм, дөрестән дә, ул бик зур чыдамлык белән безне укытырга тотынды. Һәр бала янына чүгәләп, ул каләмне ничек итеп тотарга күрсәтте, ә аннары безгә таныш булмаган яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлатып бирде.

Мин хәзер дә уйласам хәйран калам: ничек итеп бу үзе дә юньләп язу танымаган, кулында бер генә дәреслек, хәтта бер генә әлифбасы да булмаган егет шундый зур эшкә тотынырга җөрьәт итте икән. Җиде бабадан алып, гомер-гомерләренә надан булып килгән халыкның балаларын укырга-язарга өйрәтү уен эш түгел бит! Шуның өстенә Дүшән кулында программа, методика дигән бернәрсә дә юк, ул аларның хәтта дөньяда барлыгын да белми иде. Ул безне бары тик үзе белгәнчә, үзе аңлаганча, үзенең көч-хәленнән килгәнчә укыта иде. Әмма аның бу эшкә ихлас күңелдән гаҗәеп бер дәрт белән тотынуы, әлбәттә, бушка китмәде.

Үзе дә белмәстән, ул искиткеч зур фидакарьлек эшләде. Әйе, бу фидакарьлек иде, чөнки без, моңарчы үз авылыбыздан аяк атлап беркая чыкмаган кыргыз балалары, шул идәненә салам түшәлгән, стена ярыкларыннан каршыдагы кар таулары күренеп торган, мәктәп дип аталган абзарга йөреп, күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаҗәеп зур дөньяның барлыгын белдек.

Нәкъ менә шунда, Дүшән авызыннан без дөньяда Ташкенттан да зуррак Мәскәү дигән кала барлыгын,

анда Ленин торганын ишеттек. Без Талас даласы кебек очсыз-кырыйсыз диңгезләр барын, анда таудай кораблар йөзеп йөргәнен, лампага сала торган керосинның җир астыннан чыкканын белдек. Ниһаять, без, Дүшәнне тыңлап, киләчәктә тормышның бик әйбәтләнеп китәсенә, безнең авылда да ак таштан зур тәрәзәле мәктәп салыначагына һәм без инде анда идәндә тезләнеп түгел, ә парталарга утырып укыячагыбызга ышандык.

Әз-мәз хәреф танып, әле «әти», «әни» дип яза да белмәстән, без дәфтәр битләренә «Ленин» дип язарга өйрәндек. Без инде «бай», «батрак», «советлар» дигән сүзләрне өйрәнеп алдык. Дүшән әле безгә бер елдан «революция» дигән сүзне дә өйрәтергә булды.

Аны тыңлаган чакта без үзебез дә гүя аның белән бергә акларга каршы сугышып йөрдек. Ә Ленин турында ул шундый дәртләнеп, ялкынланып сөйли иде, әйтерсең менә аның тере кыяфәтен һәрвакыт күз алдында күреп кенә тора иде. Хәзер мин аңлыйм инде, Дүшән ул чакта безгә бөек юлбашчы турында халык арасында йөргән төрле легендаларны сөйләгән икән, әмма без, сөтнең ак булуына ышанган шикелле, аның һәр сүзенә ышанып утыра идек.

Бервакытны без, балаларча беркатлылык белән, аңардан сорап куйдык:

— Мөгаллим, сезнең Ленин белән кул биреп күрешкәнегез бармы?

Дүшән ничектер көенгәндәй итеп башын чайкады.

— Юк, балалар, миңа Ленинны күрергә туры килмәде.

Шулай диде ул, бездән уңайсызланып булса кирәк, авыр гына сулап куйды.

Һәр айның азагында Дүшән үз эшләре белән волостька китә торган иде. Ул җәяү бара, җәяү кайта, шунлыктан ике-өч көн вакыт үтеп китә иде.

Мондый көннәрдә без аны чынлап торып сагына идек. Мин исә бертуган агамны көткән шикелле зарыгып көтә идем аны. Әледән-әле, җиңгәмнән кача-курка

гына, өй артына чыгып, әнә шул дала юлына, бөрмәле капчыгын җилкәсенә аскан мөгаллимем кайчан гына күренер, кайчан гына мин аның йөрәкне җылытырдай итеп елмаюын күрермен, кайчан гына акыллы сүзләрен ишетермен дип, күзләрем талганчы карап тора идем.

Дүшәннең шәкертләре арасында яшькә иң олысы мин идем. Шуңадыр, ахры, бүтәннәрдән яхшырак укый да идем. Мөгаллимнең һәр әйткән сүзен, һәрбер күрсәткән хәрефен чын ихластан тыңлап, күңелемә салып бара идем. Минем өчен ул өйрәткәннәрне белүдән дә әһәмиятлерәк нәрсә юк иде. Дүшән биргән дәфтәрне саклап, мин хәрефләрне, сүзләрне урак очы белән җиргә, күмер белән өй, абзар стеналарына, чыбык белән юл тузанына яки ак карга язып йөри идем. Һәм, дөресен әйтергә кирәк, ул чагында минем өчен Дүшәннән дә акыллырак, укыганрак кеше дөньяда юк иде.

Менә акрынлап кыш та килеп җитте. Суыклар башланганчы, без тау астындагы чуер ташлар өстеннән шаулап аккан инешне тәпиләп кенә кичеп йөрдек. Торабара кичеп узу мөмкин булмый башлады, боздай салкын су аякларны уттай көйдереп ала иде. Бигрәк тә кечкенәләргә бик авыр иде, аларның хәтта күзләренә мөлдерәп яшьләр килә иде. Ахырда Дүшән үзе аларны, кайсын аркасына атландырып, кайберсен култык астына кыстырып, елга аша ташый башлады.

Хәзер менә шуларны исемә төшергәч, мин кешеләрнең ул чакта никадәр надан, явыз булуларына шаккатам. Алар, бигрәк тә таулардан тегермәнгә килүче бай кыргызлар, Дүшәннән көлә торганнар иде. Яхшы сары тун, төлке бүрек кигән һәм кыргый таза атларга менгән бу кешеләр, кичү турысына җиткәч, күзләрен акайтып, Дүшәннән мыскыллап көләргә тотыналар иде.

Шул чакта минем аларны куып җитәсем, тезгеннәреннән тотып аласым һәм оятсыз йөзләренә: «Безнең мөгаллим турында әшәке сүз әйтәсе булмагыз! Сез тупас, явыз кешеләр!» — дип кычкырасым килә иде. Әмма мин көчсез бер кыз гына шул, нишли алам мин,

бары күзләремә килеп тыгылган рәнҗү яшьләрен йотып калырга гына туры килә иде миңа...

Ә Дүшән үзе аларның көлүләренә дә, сүзләренә дә һич игътибар итми иде, тик безгә кызык мәзәк әйтеп, күңелебезне юатырга гына тырыша иде.

Елга аша басма салыр өчен, мәктәпнең агачы да, тактасы да юк иде, шуңа күрә без, беркөнне дәрестән соң Дүшән белән икәү, балаларны кичүдән чыгарып бетергәч, яр буенда калдык. Һич югы, басып чыгарлык кына булса да ярар дип, елгага ташлар салырга тотындык.

Ә бит, чынлап уйлаганда, безнең авыл кешеләренә балалар өчен берничә киртәдән басма салып бирү берни дә тормас иде. Ләкин ул заманда, әйткәнемчә, кешеләр үзләренең кара наданлыклары аркасында мәктәпкә һич әһәмият бирмиләр иде, ә Дүшәнне эшсезлектән генә балалар укыткан булып йөрүче бер юләргә санаййлар иде. Телисең икән — укыт, теләмисең икән — барысын да куып җибәр, менә ничек кенә карыйлар иде алар. Үзләре гел ат менеп йөргәнгә күрә, басманың аларга кирәге дә юк иде. Әмма шулай да авыл халкы бераз уйлап карарга тиеш иде; ни өчен һәм кем өчен бу бүтәннәрдән бер ягы белән дә ким-хур булмаган яшь егет, шулкадәр азап-кыенлыклар күрә-күрә, мыскыллап көлүләр ишетә-ишетә, шундый искитмәле чыдамлык һәм тырышлык белән аларның балаларын укытып йөри соң?

Без елгага таш салган чакта җиргә кар төшкән иде инде, су үзәкләргә үтәрлек салкын иде. Бертуктаусыз суга яланаяк кереп-чыгып йөргән Дүшән, белмим, ничек түзгәндер инде. Ә мин әйтерсең утлы күмерләргә баса-баса керә идем. Бер керүемдә шулай минем балтырларымны кинәт көзән җыерды, мин хәтта кычкыра да алмадым, тик акрын гына ава башладым. Шул чакта Дүшән, тиз генә ташын ыргытып, килеп җитте дә, мине ике куллап күтәреп алды һәм, ярга чыгарып, үзенең шинеленә утыртты. Ул алмаш-тилмәш минем күм-күк

аякларымны ышкырга, кып-кызыл кулларымны угаларга, аларны тыны белән җылытырга тотынды. Үзе һаман:

— Булды, җитте, Алтынай, утырып кына тор, җылын,— дип сөйләнде,— мин ялгызым да эшләп бетерермен...

Мин яңадан суга кермәдем, шинель өстендә бөрешеп, туңып утыра бирдем. Ниһаять, Дүшән, ташларны салып бетереп, ярга чыккач, итекләрен кия-кия, миңа бер карап алды да елмаеп дәште:

— Йә, ничек, җылындыңмы инде? Шинельне син ябынып утыр, менә шулай!

Аннары бераз дәшми торгач, сорап куйды:

— Әйт әле, Алтынай, теге вакытта мәктәп янына кизәкләрне син салып киткән идеңме?

— Әйе,— дидем мин.

Ул, «мин үзем дә шулай уйлаган идем» дигән төсле, авыз кырые белән елмайгандай итте. Аның шушы кечкенә генә бернәрсәне дә исендә тотуын күргәч, мин куанычымнан алмадай кызарып киттем, түбәм күккә тигәндәй булды... Һәм Дүшән минем шатлыгымны сизмичә калмады.

— Якты көнем син минем! — диде ул, аркамнан сөеп.— Укырга да бит синең сәләтең бар! Их, кулымнан килсә, мин сине зур калага җибәрер идем. Нинди кеше булып чыгар идең син анда!

Шулай диде дә ул, кисәк кенә торып, шаулап аккан елгачыкка таба бер-ике адым атлады һәм, башын каерып, кулларын җилкәсенә куеп, еракка, таулар өстеннән шуган ак болытларга карап тора башлады.

Ни уйлады икән ул шул чакта? Бәлки, чынлап та, мине зур калага җибәреп укыту, кеше итү турында хыялланганды
р? Ә мин, аның шинеленә төренеп, эчемнән һаман бернәрсәне кабатладым: «Ярабби, Дүшән минем бертуган агам булса иде! Мин, аның муенына сарылып кысып-кысып, күзләремне йомып, колагына иң кадерле сүзләремне пышылдап әйтә алсам иде!»

Без аны ул чакта ук инде, шушы кешелеклелеге өчен, изге ниятләре өчен, безнең киләчәгебез турында уйлануы өчен, барыбыз да бик ярата идек. Балалар гына булсак та, без аны аңлый идек шикелле. Югыйсә безне һәр көн ачы җилгә каршы өшеп-катып, кар ерып, калкулык өстенә менәргә нәрсә генә мәҗбүр итәр иде? Без бит үзебез теләп мәктәпкә бара идек. Безне беркем кумый да, көчләми дә иде. Шул мәктәп дигән абзар эчендә без, суыктан өс-башыбызга бәс кунып бетсә дә, чыдап утыра идек, мөгаллимнең сөйләгәннәрен шылт итмичә тыңлый идек, тик ара-тирә берәмләп кенә мич янына барып, кулларыбызны җылытып килә идек.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мөгаллим Дүшән белән балалар арасында нинди мөнәсәбәт урнаша?

2. Ни өчен Дүшән, шулкадәр азап-кыенлыклар күрә-күрә, балалар укытып йөри? Аның фидакарьлеген тасвирлаган урыннарны укып күрсәтегез.

3. Дүшән ни турында хыяллана?

4. «Аның елмаюыннан хәтта йөрәк җылынып киткәндәй булды», «Түбәм күккә тигәндәй булды». Күчерелмә мәгънәдә кулланылган мондый образлы сүзләрне, җөмләләрне тагын да эзләп табыгыз.

Шактый гына вакыт үтеп китте. Шыксыз тау-чокырлар артта торып калды. Ниһаять, Дүшән, атны туктатып, талчыккан күзләре белән беренче тапкыр миңа күтәрелеп карады.

— Тынычлан, Алтынай, киттек,— диде ул ахырда.— Беләсеңме, мин сиңа нәрсә әйтмәкче булам. Өченче көн мин волостька барган идем. Шунда сине калага укырга җибәрү турында сөйләштем. Син калага китәчәксең, ишетәсеңме?

Ә ике көннән соң Дүшән мине станциягә озатып куйды. Башымнан мондый хәлләр кичкәч, инде мин үзем үк авылда калырга теләмәдем. Яңа тормышны

Илдар Зарипов. Натюрморт.



Рөстәм Килдебәков. Г. Тукайның лирика дәфтәреннән.

яңа җирдә башларга кирәк иде. Минем китәргә теләвемне кешеләр дә дөрес дип таптылар. Сайкал әбием белән Кара әкә бабаем, кулыма азык-төлек тоттырып, мине елый-елый озатып калдылар. Озатырга дип күрше-күлән дә, хәтта әлеге гел кирегә тырнаучы Сатымкол агай да килгән иде.

— Йә, хәерле юл, кызым, Аллага тапшырдык! — диде ул миңа.— Бер дә борчылма, мөгаллимең Дүшән биргән киңәшләрне тотсаң, хур булмассың. Без дә бит инде кайбер нәрсәләрне аңлый башладык.

Мәктәп балалары — шәриктәшләрем[1] безнең арба артыннан шактый җир йөгерешеп бардылар һәм озак кына кул болгап карап калдылар.

Минем белән Ташкенттагы балалар йортына тагын берничә ятим малай бара иде. Станциядә безне күн тужурка кигән бер рус хатыны каршы алды.

Соңыннан, гомерем эчендә, миңа бу тополь агачларына күмелеп, таулар итәгендә утырган станциядән күп тапкырлар үтәргә туры килде. Мәңге онытылмас ул. Монда минем ярты йөрәгем торып калды.

Әкрен генә иңеп килгән тымызык[2] язгы кич, безнең аерылышуны сизгәндәй, ничектер аеруча моңсу, сагышлы иде. Дүшән бу минутта үзенә никадәр авыр булуын ничек тә белдермәскә тырыша иде, ләкин мин аның хәлен бик ачык күреп тора идем. Йөрәгемнең әрнеп сызлануы, кайнар бер төер булып, минем дә бугазыма килеп тыгылган иде. Дүшән берөзлексез тутырып күземә карый, акрын гына чәчемнән, битемнән, хәтта бишмәт төймәләремне сыйпый иде.

— Мин сине, Алтынай, үз янымнан бервакытта да, бер генә адымга да җибәрмәс идем,— ди ул миңа.— Әмма моны эшләргә минем хакым юк. Син укырга тиешсең. Миңа бит уку дигән нәрсә яхшылап эләкмәде. Әйе, сиңа китәргә кирәк! Син, бәлки, киләчәктә чын

[1] Шәриктәшләр — сабакташлар.

[2] Тымызык — җилсез, тыныч кич.

мөгаллимә булып чыгарсың, шул чакта, бәлки, безнең хәзерге мәктәпне исеңә төшереп, көлеп тә куярсың... Мәйле[1], шулай булсын ул, шулай булуы яхшы!

Еракта ике тау арасын яңгыратып поезд кычкырды, озакламый утлары да күренде. Станциядәге халык урыннарыннан кузгала башлады.

— Менә син китәсең дә,— диде Дүшән калтыранган тавыш белән һәм каты итеп кулларымны кысты.— Бәхетле бул, Алтынай... Бернигә карамый укы, укы, яме!

Мин, яшемә буылып, аңа сүз кайтарып әйтә алмадым.

— Елама, Алтынай.— Ул минем күзләремне сөртте, аннары кинәт исенә төшереп әйтте.— Ә теге без утырткан топольләрне мин карап үстерермен. Син укып, зур кеше булып кайтуыңа алар да матурланып үсеп китәрләр.

Шул арада поезд да килеп туктады, бу кечкенә станциядә ул озак торырга тиеш түгел иде.

— Йә, саубуллашыйк, Алтынай! — диде Дүшән һәм, мине кочаклап, маңгаемнан үпте.— Хәерле юл сиңа, исән-сау барып җит, хуш, кадерлем!..

Мин вагон баскычына мендем, артыма борылып карадым. Дүшән кулын муенына аскан килеш боек кына басып тора иде. Һич онытасым юк аның бу кыяфәтен... Аннары соңгы тапкыр кагылырга теләгәндәй, ул таза кулын миңа таба сузды, ләкин шул минутта поезд да кузгалып китте.

— Хуш, Алтынай! Хуш, чырагым[2].

— Хуш, мөгаллим! Хуш, минем кадерле мөгаллимем! Ул бераз вагон белән янәшә атлап барды да, поезд кызулангач, туктап торып калды. Аннары нәрсәнедер исенә төшереп, кинәт кенә алга омтылып кычкырды:

— Алты-на-ай!

Ләкин соң иде инде, мин берни дә ишетә алмадым. Әмма аның соңгы мәртәбә кинәт нидер әйтергә теләп

---

[1] Мәйле — ярый, яхшы.

[2] Чырагым — кадерлем (кыргыз сүзе).

кычкырган тавышы хәзер дә әле колагымнан китмичә тора.

Менә поезд туннельгә килеп керде, аны узып, киң, тигез казакъ даласына килеп чыкты һәм, отыры кызулап, мине билгесез яңа тормышка таба алып китте...

Әйе, мин Дүшән сөйләгән калада тордым. Дүшән сөйләгән якты тәрәзәле зур мәктәптә укыдым. Аннары рабфакны тәмамладым, шуннан соң мине Мәскәүгә — институтта укырга җибәрделәр.

Югары белемгә ирешүе минем өчен бик авыр булды. Хәзерлегем бүтәннәргә караганда түбән иде, шуңа күрә көн-төн тырышырга туры килде. Бик авырга килгән чакларда, юк, булмас, ташлармын, ахрысы, дип өметсезлеккә бирелеп уйлаган вакытларым да аз булмады. Ләкин беренче мөгаллимемнең киңәшләрен исемә төшереп һәм аның алдында зур бер җаваплылык хис итеп, мин аеруча бер кабыну-яну белән тагы да бирелебрәк, тырышыбрак укырга тотындым.

Сораулар һәм биремнәр

1. Алтынай беренче мөгаллиме белән аерылышуны ничек кичерә? Дүшән аңа нинди киңәшләр бирә?

2. Авылдашлары Алтынайны ничек озаталар? Сатымкол агай: «Без дә бит инде кайбер нәрсәләрне аңлый башладык»,— ди. Нәрсәләрне аңлый башлаган ул?

3. Ташкент, Мәскәү шәһәрләрендә укыганда да, Алтынайга беренче мөгаллиме гел «ярдәм» итеп тора. Моны ничек аңлыйсыз? Шул урынны табып укыгыз.

4. Алтынай белән Дүшәннең характер сыйфатлары арасында нинди уртаклык бар?

5. Әсәрне тулысы белән укып чыгыгыз. Кыргыз халкының тормышы нинди булып күз алдыгызга килде?

ЯХШЫЛЫК ҖИРДӘ ЯТМЫЙ

Изгелек, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. Кеше яшәгән саен бу сүзләрнең мәгънәсен күбрәк аңлый, тирәнрәк төшенә бара. Ул сүзләрне тормыш безнең күңелләребезгә язып куя, ә кешеләр китапларга язалар, аларны мәңге җуелмаслык итәләр. Менә шуңа күрә дә укый-

яза белүнең, китапның, белемнең кадере бик зур. Укырга-язарга өйрәтүче кешене дә зурлап укытучы, мөгаллим дип атыйбыз.

Әсәрнең исеме дә «Беренче мөгаллим» дип куелган. Нинди мөгаллим турында сүз бара соң? Үзе дә яңа гына укырга-язарга өйрәнгән, махсус белеме дә булмаган Дүшән, авылга кайтып, балалар укыта башлый. Үз гомерләрендә укытучы, китап күрмәгән, әйтерсең лә еракта, далада адашып калган кешеләр өчен бу бер вакыйга була. Әмма аны куанып, ярдәм итәргә әзер булып көтеп торучы юк. Кешеләргә иң башта укуның, белемнең кирәклеген төшендерергә, исбатларга кирәк әле. Автор «томана» кешеләр дигәндә укый-яза белмәүчеләрне түгел, ә аның кирәклеген аңламаучы һәм аңларга да теләмәүче, бернәрсә белән дә кызыксынмыйча, битараф яшәүчеләрне күздә тота.

Дүшән бернәрсәне бик яхшы аңлый: тормыш алга барсын өчен, кешеләрне наданлыктан коткарырга кирәк. Үзенең хаклы икәнлеген сүз белән генә аңлата алмагач, эше-хезмәте белән исбатлый. Берүзе ташландык сарайны «мәктәп» хәленә китерә, кешеләрнең аннан көлеп, мәсхәрәләп йөрүенә карамастан, бөтен күңелен балаларга бирә. Башта аңа сәер кеше итеп кенә караган авылдашлары да, аның фидакарьлеген күреп, акрынлап карашларын үзгәртә башлыйлар. Әсәр ахырында без Дүшән хезмәтенең нәтиҗәләрен дә күрәбез: ул хәреф өйрәткән укучылар дөньяның яктылыгын таныйлар, югары дәрәҗәләргә ирешәләр. Укытучының хезмәтенә иң югары бәя — өметләренең аклануында. Беренче адымнарны ясау зур тырышлык сорый. Балаларның яңа тормышка чыгуларын кайгырткан, үзенә берни таләп итмичә, эчкерсез күңел белән яшәгән Дүшәннең гомере кешеләргә эшләгән шәфкатьлелектән, изгелектән тора.

Алтынай да — бик матур образ. Җәбер-золым, ятимлек кенә күреп үскән кызның күңелендә рәхмәт хисе, өмет-ышаныч нуры туа. Ниһаять, ул күңелен җылытып, якын итеп кайгырткан кешене очрата, аңа ярдәм итүдән үзенә никадәр куаныч таба. Укытучысы-мөгаллименең изгелеген тормышка ашыру өчен, үзе дә бөтен җаны, рухы белән тырыша. Зур якты мәктәпләрдә, институтта укый, күп укытучыларны күрә, шулай да без аңлап торабыз: әгәр дә Дүшән аны явыз кешеләр

кулыннан йолып алмаган, зур шәһәргә укырга җибәрмәгән булса — боларның берсе дә булмас иде. Алтынай бик авыр булганда да чигенми, укытучысын исенә төшергән саен, алга атлап китәрлек көч таба. Ул зур галим булып җитешә, академик дәрәҗәсенә ирешә, авылдашларының горурлыгына әйләнә.

Менә шундый мөгаллим һәм аның дан-шөһрәткә ирешкән укучысы турында сөйли автор. Күптән һәм бездән бик еракта булган вакыйгалар турында сүз барса да, әсәр безнең күңелебезгә якын, чөнки без дә укучылар, безнең дә беренче укытучыларыбыз бар. Атаана хакын ничек олыласак, укытучыларыбызның изгелеген-шәфкатен дә шулай күңелләребездә саклыйбыз, игелекле һәм рәхмәтле булып яшәргә тырышабыз.

Тагын бер якка игътибар итик: әсәр безгә дәреслекләр яки телевизордан караган тапшырулар, кинофильмнар күреп кенә таныша алган ерак җирләр, тугандаш дисәк тә без белмәгән кешеләр турында сөйли. Табигать, кешеләрнең яшәү рәвешләре, гореф-гадәтләре безнеңчә түгел. Шулай булгач уртаклык та, охшашлык та юк дияр идек... ләкин нигәдер кызганабыз, нәфрәтләнәбез, ярдәм итәсе килә.

Әдәбиятның сере, тылсымы да — нәкъ шундый хискичерешләр уятуда. Автор әллә кайчан, әллә кайда яшәгән кешеләр турында сөйли, ләкин укучысына мөрәҗәгать итә. Һәм: «Ә син, укучым, үзең нинди кеше соң?» — дип сорау бирә. Димәк, әдәби әсәр белән танышканда, без әсәр геройлары турында гына түгел, үзебез турында да уйланабыз.

«Авылларда чишмәләрне карап-чистартып торучы агайлар була. Балалар язучыларын мин әнә шул мәрхәмәтле кешеләргә охшатам. Алар да халкыбызның, әдәбиятыбызның киләчәк чыганагы булган балаларны — күңел чишмәләренең чисталыгын кайгыртып яшиләр, аларга үз юлларын табарга, алга омтылырга булышалар».

Танылган язучы Шәүкәт Галиев балалар әдәбиятын әнә шулай челтерәп аккан йөгерек чишмә белән чагыштыра.

Һәр сабый, хәреф таный башлаганчы ук, өлкәннәр ярдәмендә үз китаплары, үз геройлары белән таныша башлый. Яраткан язучыларын да сайлап ала, аларны гомере буе онытмый. Шундый язучылар рәтендә торган исемнәр, аларның иҗатлары белән танышуны дәвам итәбез.

Ләбибә Ихсанова

(1923 елда туган)

Һәр язучы әдәбиятка үзенчә килеп керә. Кайберәүләр шактый зур тормыш мәктәбен үткән булалар, шуннан соң гына кулларына иҗат каләме алалар. Кайберәүләр исә мәктәп чорында ук хыял көчен эшкә җигә.

Ләбибә Ихсанова аң-белем, китап дөньясында, укытучы гаиләсендә үсә. Урта мәктәпне тәмамлаганда, Бөек Ватан сугышы башлана. Ул туган авылында эшли башлый: бер үк вакытта мәктәптә өлкән пионервожатый һәм кырчылык бригадасында бригадир ярдәмчесе дә. Ике елдан ул — Казан дәүләт университетының география факультеты студенты. Әдәбият һәм геогра-

фия. Беренче карашка, бәйләнеш юк кебек, ләкин Ләбибә Ихсанова үзенә яхшы таныш балалар дөньясын туган илнең киңлекләре, табигатьнең төрлелеге һәм байлыгы белән кушып җибәрә, кызыклы, маҗаралы дөнья барлыкка килә. Язучы буларак ул 1996 елда А. Алиш исемендәге әдәби бүләк лауреаты була. Ә аның геройлары исә язучыны чолгап алган тормышның үзендә яшиләр: хыялланалар, эзләнәләр, ялгышалар, үсәләр һәм үзгәрәләр. Әйдәгез, без дә шул геройларның кайберләре белән танышыйк.

НАИЛ ҺӘМ ФАИЛ

(Повестьтан өзекләр)

Быел уку башланган көнне мин үзебезнең классның ишеген ачып кердем дә, тәрәзә кырыендагы партадан урын алып, коридорга чыктым. Кайда нинди класслар бар, кем кайсы бүлмәдә укыр икән, карыйм әле дип. Безнең классны җиденче «В» дип йөртәчәкләр икән. Аннан кала «Б» классы, тагын алтынчы «А» күренеп тора. Ә «В» сы кая соң моның? Кайсы идән ярыгына төшеп югалды икән? Англиядә унөч саныннан куркалар дип ишеткәнем бар иде. Бәхетсезлек китерә, имеш. Унөченче өй, унөченче фатир, унөченче көн, кинода унөченче урындык, тагын әллә нинди унөчләр юк икән анда. Әллә, мин әйтәм, инглизләр унөч саныннан курыккан кебек, безнең мәктәптә дә җиденче «В»дан куркалармы? Кайчан да булса безнең дә җиденче «В» булгандыр, анда җыен ялкау, җыен хулиган, әшәке балалар гына җыелгандыр, укытучыларның «В» хәрефле классны күрәселәре дә килмидер, шуңа күрә ул классны мәңгелеккә ябып куйганнардыр, безнең җиденчене дә «В», «Г» дип йөртәләрдер дигән уйлар башка килде.

Класс җитәкчесе Зоя Михайловнадан шулай дип сораган идем, художник фантазиясе ул дип көлде. Икенче көнне үк класс ишегенә яңа такта элеп куйдылар. Шулай итеп, без җиденче «В» класс укучылары булдык.

Укытучыларны куркытырлык җыен хөрәсән җыелмаган безнең класска. Беренчедән башлап гел бишкә генә баручылар да, бара-бара төшеп калучылар да, тыныша торгач алдырып китүчеләр дә, һаман бер көе «өч»лене тартучылар да бар. Башкалардан бер генә як белән аерылабыз — классыбыз укытучылар бүлмәсенә каршы гына. Шуңа күрә ул бүлмәдә безнең турыда сүз күп буласы билгеле инде. Үзебез алай бик ишле дә түгел, егерме кыз да сигез малай гына. Гел начар малайлар дип тә әйтерлек түгел үзебезне. Зоя Михайловна гына, сигез булсагыз да егерме кызга торасыз, дип битәрли. Көч ягыннан әйтүе түгел. Көч ягыннан булса, мин берүзем егерме кызның бөтенесен бергә, алар янына Наил ишерәк юаш малайларны да кушып, бәйләп салган булыр идем. Шуклыгыбызны яратмый ул безнең, укуга күңел бирмисез, ди. Укытучыларның кайсысы шаярып утырганны ярата инде? Тик алар класс җитәкчесе кебек үк теңкәгә тимиләр, химия укытучысы әнә бөтенләй бәйләнеп утырмый, күңеленә ошамаган эш эшләсәк, күзлеген маңгаена күтәреп, озак кына карап тора. Тәнәфес булуга, Зоя Михайловнаның килеп керәсен шуннан беләсең инде. Ярый ла чыгып китәргә өлгерсәң. Өлгермәсәң, яныңа ук килеп утыра да зыңгылдап торган буш башыңа, тыныша-тыныша, акыл тутырырга керешә. Дыңгычлап тутыргач, акылың шундый күбәеп китә, башыңның сөякләре шытырдап, тиресе тартылып авырта башлый. Чыгып китәсе иде, баш сөяге түгел, арка сөяген шытырдатып, малайлар белән бер көрәшеп керәсе иде, дип астан гына ишеккә карап утырасың. Белеп торасың, Зоя Михайловна сине тиз генә ычкындырмаячак, коткарса шул сандугач күк сайрый торган җиз кыңгырау гына коткарачак. Башкалар ничектер, алар турында әйтә алмыйм. Акыл дигән нәрсә аларның башына да шундый читенлек белән керәме икән ул?

Әнә кызлар гел акыл белән йөргәч, аларга артыгын бирүче юк, акыллары таман гына булгач, аларның башлары да авыртмыйдыр.

Ә Зоя Михайловна белән сиңа ике көннең берендә шулай тырышырга туры килә.

Болар классында укуы бик күңелсез, авыр икән дип тә уйлый күрмәгез. Алтыны бетергән тәҗрибәле башым белән ышандырып әйтәм, күңелле вакытлар күп була безнең җиденче «В» классында. Класс ишеген таба алмыйча елап торган чакларың инде үткән, укытучы эндәшкәндә, исемеңне онытып утырган еллар да түгел инде бу. Тәнәфес вакытларында олы малайлар таптап китүдән куркып, аркаң белән стена терәтеп тә тормыйсың. Телисең икән, үзең теләсә кемнең башыннан йөрисең. Әле сынауларга да бик ерак. Аңар хәтле бер ел да ике чирек, аннары тагын бер ай бар. Көне-төне китапка кадалып утырасы чакларың искә дә кереп чыкмый.

Андый вакытлар да булган бит, әй. Мин үзем күреп белмим, ул вакытта мин әле космостан кайтып җитмәгәнмен, ул чакта әни үзе дә минем чаклы гына укучы кыз булган.

Менә ул әйтә инде, сезнең белән безнең уку укумыни ул, менә синең әбиең белән бабаң дүртенчедән башлап унынчыга хәтле ел саен сынау биргәннәр, хәзерге күк өч-дүрт фәннән генә түгел, унар-уникешәрдән биргәннәр, ди. Менә алар укыган, башлары да шартлап ярылмаган, үзләре дә саргаеп кипмәгән, ди. Урамда трай тибеп йөрисең, дәресләреңне вакытында әзерләмисең дип битәрләгәндә гел шул әби белән бабайны китереп кыстыра ул.

Аннары Наилне төртеп күрсәтә. Әнә Наилдән гыйбрәт ал, ди. Беренче класстан башлап бишкә генә укый, математика түгәрәгенә йөри, шәһәр ярышларында беренчелекне ала, әти-әнисенең сүзеннән чыкмый, апасының авызына гына карап тора... Китә-китә шулай Наилнең әйбәт якларын тезеп. Әгәр дә мәгәр берәр вакыт бөтен яктан да үрнәк малайга һәйкәл куярга уйласалар, ул нәкъ Наил сурәтендә булырга тиеш дип уйлый минем әни.

Кайчагында кыйнап ташларга җитәм шул Наилне. Юашлыгы белән котылып кала. Җебегән малайларны яратмыйм, яратмасам да тимим мин аларга. Кара-каршы бәргәләшерлек тә булмагач, бәйләнүнең ни кызыгы бар.

Наил белән без бәләкәйдән үк бергә. Элек тә бер ишегалдында тордык. Минем әти белән Наилнең әтисе эшләгән завод тугыз катлы зур йорт салып бетерде дә, без дә, алар да шунда күчеп килдек. Әллә юри биргәннәр инде, бу өйдә дә күрше булдык. Ишекләребез кара-каршы гына. Икебез дә бер класста укыйбыз. Тик Наилнең күрше булуыннан миңа бер кызык та юк. Кайчагында уйлап куям, аның урынына Зөбәрҗәт шикелле генә булса да берәр үткенрәк кыз күчеп килмәгән шунда дим. Күңеллерәк булыр иде. Зөбәрҗәт — әләкче кыз ул. Аның аркасында мин байтак җәфа чигәм. Берәр гаебеңне сиздеме, урынында утырып тора алмый, сикерә-сикерә кулын күтәрә. Гадәтен белеп алгач, укытучылар аның үзен шелтәләп урынына утырталар. Йә бөтенләй күрмәгәнгә салыналар. Аңар ирек бирсәңме? Дәрес урынына кырык биш минут буе Зөбәрҗәтнең әләген тыңлап утырырсың. Шулай да бер әйбәт ягы бар үзенең: малайлар кук сугыша белә. Үзе үпкәләми дә, еламый да. Беркөнне Светлана белән баскычтан төшеп баралар иде, йөгереп килдем дә, юри бәрелгән булып, портфелен төшереп җибәрдем. Шуның белән мактанып, ачуны китереп бетергән иде. Басмадан-басмага бәрелеп төшеп китте моның елык-елык итеп торган яңа портфеле: шап-шап, шап-шап! Авыз ерырга да өлгермәдем, Зөбәрҗәт дык итеп аркама китереп бәрде, Света тотып калмаса, мәктәпнең беренче катына очып барып төшкән идем. Җитмәсә, телемне тешләдем.

— О-о-о-у! — дип үкерепме-үкерәм.

Бик шәп җавап кайтарырга исәбем бар иде, кулым буш булмады. Телемнең очы өзелеп чыккандыр, авызымны ачсам төшеп китәр дип куркып, ике кулым белән авызымны тотып торасы булды.

Ярый әле Света кызганды.

— Шуның хәтле ярыймыни инде, Зөбәрҗәт? — диде ул, иптәшен шелтәләп. Миңа шуннан да рәхәт булып китте.

— Бәйләнмәсен! — диде Зөбәрҗәт, әз генә дә йомшамыйча.

Каты куллы ул. Кеше түгел, портфеле кызганыч. Кара ничек иркәләп сыпыра, тузанын өргән була, анда гына яңа портфель дип уйларсың. Ә Света бөтенләй башка, йомшак күңелле, ярдәмчел. Без аның белән бер партада утырабыз. Өйгә биргән эшләрне мин аннан күчереп куям. Башта ачулана ул мине. Синең өчен мин эшләп утырам, белеп тор, бүген актыккы күчерүең, үзең эшләп кил, иртәгә миңа ышанма, ди. Ә үзе икенче көнне дә күчертә. Контроль эшләрне дә аңа карап эшлим. Кайчагында без икебез дә бер үк хатаны ясыйбыз. Ә кайвакыт минеке күбрәк тә булып китә. Укытучылар әйтә, син, Шакиров, хатасыз күчерергә өйрән инде, диләр. Ә мин ачуны Светадан алам, син дәфтәреңне юри каплап утырдың, миңа күчертмәскә тырыштың, дим. Ә ул, чыннан да, гаепле кеше күк акланырга тотына.

Класста мин бер генә кызга сүз әйтә алмыйм. Зәпзәңгәр күзле, сары толымлы, нәзек озын буйлы Сәвия ул. Миңа аның бар әйбере: киеме, китаплары, ул утырган парта, тактага ул язган язулар — барысы да ошый. Мине санга сукмыйча, Наил белән дус булуына да сүз әйтә алмыйм. Икесе дә отличниклар алар. Икесе бергә Химиклар сараендагы яшь математиклар түгәрәгенә йөриләр. Икесе дә шахмат уйнарга яраталар. Наилнең портфелендә уч төбе хәтле генә шахмат тактасы йөри. Фигуралары карандаш башы чаклы гына. Тәнәфес булдымы — икәүләп шуңа кадалып утыралар. Шәһәр ярышына әзерләнәләр, янәсе. Класста үзләрен үрти дә башладылар инде. Сәвия белән Наилнең дуслыгына эчем пошса да, аларны үртәгәндә түзеп тора алмыйм.

Сораулар һәм биремнәр

1. Үз исеменнән сөйләүче-хикәяләүче Фаилнең нинди сыйфатлары турында әйтеп булыр иде?

2. Сыйныфта тагын нинди укучылар бар, Фаил аларның кайсы якларына игътибар иткән?

3. «В» классы кайсы идән ярыгына төшеп югалды икән?», «...зыңгылдап торган буш башыңа, тырыша-тырыша, акыл тутырырга керешә» кебек күчерелмә мәгънәдә кулланылган җөмләләрне табыгыз. Икенче төрле сүзләр белән аңлатып карагыз. Кем сөйләме кызыклырак, җанлырак булыр. Чагыштырыгыз.

4. Сезнең сыйныф нинди укучылардан тора. Үзара фикер алышып бәяләп карагыз.

Декабристлар урамыннан сәгатенә дүрт мең машина үтә, ди безнең әти. Ә, минемчә, дүрт кенә мең дә түгелдер. Урамдагы этләр дә, кешеләр дә дус миңа. Мәктәптәге йә өйдәге кебек акыл өйрәтеп торучы да юк анда. Киресенчә, кешеләрнең үзләренең йомышы төшә. Берәрсенә аптекадан дару алып кайтырга туры килсә, тәрәзә ачып кына кычкыра, очып барып кайтам. Икмәксөт ише нәрсә кирәк булса да, акча белән сумкаларын тоттырсалар, чуртан кушуы белән өстәлләренә кайта да утыра. Пенсиядәге әбиләр, бабайлар: «Исәнме, Фаил улым»,— дип кенә дәшәләр миңа.

Наилнең туган көнендә катнашасым килеп атлыгып тормый идем. Керүемне мин соңыннан да бик зур ялгышлык дип санадым.

— Нигә боегып утырасың, Фаил, берәр кызны биергә чакыр.

Наилнең әнисе икән, өстәлгә чикләвек торты урнаштыра. Мин ни әйтергә белмичә ык-мык итеп торганда, аңа Фәридә җавап бирде:

— Фаил бии белми бит ул.

Болай да каушаган идем, Фәриданең күзлек пыяласына карагач, башымдагы барлы-юклы акылым чыгып

китте, ахры. Ни өчендер урынымнан сикереп тордым, җайсыз кыймылдаудан урындыгым авып төште, аны күтәреп куярга кирәген исемә дә китермичә:

— Ә мин фокус күрсәтә беләм,— дидем.

Урындык тавышына барысы да әйләнеп караган, авызымнан «фокус» сүзе чыккач, миңа таба елыша башлаганнар иде инде. Зөбәрҗәт ванный ишеген барып какты:

— Фаил фокус күрсәтә, тизрәк чыгыгыз, күрми каласыз!

Каян телемә килде соң шундый сүз? Фокусчымыни мин? Ә Фәридәнең күзлек пыялалары ялтырапмы-ялтырый, күзләре мыскыллап карый төсле. Ишеккә шахматчылар башы тыгылды. Сәвия дә Фәридә кебек ышанмыйдыр әле миңа. Барысының да һушын алырлык берәр нәрсә эшләргә кирәк иде бит инде. Ә башка берни килми. Нишләргә инде, нишләргә? Нәрсә уйлап чыгарырга да белмичә, як-ягыма каранган идем, ярты-лаш ачык калган балкон ишеген күрдем. Андый чакта акыл кирәкмени?

— Карагыз, мировой трюк күрсәтәм! — дидем дә ишеккә ташландым.

Наил, Сәвия, Фәридә, Олеглар этешә-төртешә ишеккә тыгылганда, рәшәткәләргә тотынып, балконның тыш ягыннан асылынып тора идем инде. Беләк мускулларым нык минем, турникта бер тоташтан егерме тапкыр күтәрелгәнем бар. Ә бу бит турник түгел. Өченче кат биеклектән асылынып тору диләр моны. Аста төнге урам. Таш тротуар. Анда нилар бардыр? Трамвайлар, троллейбуслар, төрле-төрле машина тавышы башны әйләндерә. Аркама бер йомарлам кар салган кук чирата[1]. Наилнең әнисе:

— Фаил, юньсез малай, ни эшләвең бу? — дип ачыргаланып кычкыруы белән беләкнең көчен ала язды.

---

[1] Чирата — чиркандыра, чымырдата (куркыта мәгънәсендә).

Шулай да сер бирергә исәп юк. Иптәшләрнең кайсы ялынып, кайсы тиргәп, кайберләре этигә әйтү белән куркытып, балконга менәргә кушалар. Аларга да карамас идем, Света кызганыч булып китте, ике күзеннән тамчы-тамчы яшь тама. Гел Наил дип шаккатсын, гел отличникларга кызыгып көне үтсен, шулай да әйбәт ул Светлана. Әллә аның хакына туктатыргамы бу трюкны? Курыкмыйча асылынып тора алуымны күрделәр бит инде. Болай тору үземә дә җиңел түгел, балкон рәшәткәсенең кырлы тимере, авырттырып, уч төбенә батып керде, гәүдәм бөтен авырлыгы белән аска баса бара, таш тротуарга тарта. Чәлпәрәмә килеп ятачагым исемә төшә дә, куркудан тәнем камырга әйләнә, буыннарның хәле бетә. Мин инде бар көчемне җыеп беләккә салырга да, гимнастлар шикелле матур хәрәкәт ясап талпынырга һәм балкон рәшәткәсе аша иптәшләр янына менеп басарга теләгән идем. «Менә шундый була ул мировой трюк»,— дип әйтәсе сүземне дә уйлап куйдым. Шулвакыт Сәвиянең Наилгә пышылдап әйткән сүзләрен ишеттем:

— Тиле! Нәрсә исбатларга тели инде ул?

— Озак тора алмас,— диде тегесе, юаткан булып.

— Әһә! Шулаймы? Тора алмас дисеңме? Син әле кырыйга килеп түбән карарга да куркасыңдыр. Фаилне берни дә булдыра алмый торган малай дип белдегезме? Фокус күрәсегез килә иде бит, карагыз инде менә! Фаил ул, беләсең килсә, тагын бер сәгать шулай тора ала. Наил түгел ул сезгә.

Сәвия белән Наилнең пышылдашуы мине шулай котыртып җибәрсә дә, кулларның көче бетә бара иде инде. Аякларны суда йөзгәндәгедәй хәрәкәтләндереп, гәүдәмә җиңеллек бирергә теләп карадым, аннан гына көч артмады. Көчәнүдән вакыт-вакыт күз алларым караңгылана башлады. Арка чокырыннан тәнне изрәтә торган җылы дулкын йөгереп үтте, иң хәтәре — уч төбе тирләп чыкты.

Экскаватор чүмечедәй дәү куллар, калтырап торган

беләкләремнән эләктереп, җиңел генә өскә күтәрелгәндә, тәмам өзелеп төшәр хәлгә җиткән идем инде. Наилнең әтисе мине бик вакытында күтәреп алды һәм балкон идәненә бастыргач, бер дә кызганып тормыйча, каты итеп колагымны борды.

— Малай актыгы! Дөньядан туйдыңмы әллә? — диде ул, ачуланып.

Дәшми генә бүлмәгә үттем. Артымнан башкалар да кереп, эленке-салынкы гына өстәл тирәсенә утыруша башладылар. Мәҗлеснең күңеле минем өчен генә түгел, аларга да беткән иде инде. Мин, рәхмәт тә әйтмичә, үзебезгә чыгып киттем. Кал дип кыстаучы булмады.

Шул көннән миңа Акробат дигән кушамат ябышып калды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Фаил тагын кайсы яклары, нинди сыйфатлары белән ачыла башлады?

2. Аның «фокус» күрсәтүен сез ничек бәяләр идегез?

3. Геройларның үзара мөнәсәбәтләрендә каршылыклар каян килеп чыга? Сәбәпләрен эзләп, аңлатып карагыз.

Әхмәт абый будкасы торган җир безнең иң яраткан урыныбыз иде ул. Тупны да без гел шул тирәдә генә тибә идек. Әхмәт абый үзе куша. «Ике аякка басып туп типкәнегезне бер рәхәтләнеп карап утырыйм әле»,— ди ул, ишеген түбәнә хәтле ачып куеп. Ә кайчакларда без аның каршына тезелеп утырабыз да әкият сөйләгәнен тыңлыйбыз. Җен-пәриләр турында күп сөйләми иде ул безгә. Әллә үзе уйлап чыгара, әллә китаплардан укыганын исенә төшереп сөйли, аның әкиятләре урман-кырлар, хайваннар-кошлар турында. Куян турындагы әкиятне дә мин аннан ишеткән идем.

— Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк үрәтник булганда,— дип башлап җибәрә ул әкиятен. Кайчагында шул төшен юри озакка суза.—

Дуңгыз староста, сыер пүнәтәй булганда,— дип әллә ниләрне тезеп китә, безнең түземнәр бетә, тизрәк әкиятнең үзен ишетәсебез килә:

— Җитәр инде, Әхмәт абый!

— Сузма инде!

— Әкиятен сөйлә инде,— дип ялынабыз.

— Сабыр, балалар, лампаның мае, сүзнең җае булганда әйбәт ул,— ди Әхмәт абый, әкиятнең сумалалы җептән дә озынга сузылган кереш өлешен тәмамлый да, әле беребезгә, әле икенчебезгә карап, сүзен ялгап китә: — Торган, ди, булган, ди, бер мужик белән бер Куян. Мужикның булган, ди, ашъяулык чаклы гына җире, ә Куянның карасаң карашың җитмәслек киң кырлары, башларың адашырлык кара урманнары, исеннән исереп егылырлык чәчәкле аланнары булган, ди. Мужик үзенең җирендә, тырышып-тырышып, кәбестә үстергән, ди. Ә Куян кышын-җәен күңел ачып үткәргән. Җырлаган, биегән, мәтәлчек атып уйнаган. Ник уйнамасын, дөньясы түгәрәк булган Куянның. Аның өчен бөтен нәрсә әзер — пешкән дә төшкән. Җирана аңар тәмле-тәмле тамырлар, яшел яфраклар, агачларның әчкелтем-татлы кайрыларын үстергән. Кояш нурлары салкын чык сулары әзерләп куйган. Хуш исле үләннәр йомшак мендәр, мәңге яшел чыршылар калын юрган булган аңа. Табигатьнең иң матур, иң сөекле иркә баласы булган Куян.

Дуслары артык күп булмаган аның. Күршедәге Керпе малае белән генә уйнарга яраткан. Чөнки ул юаш, сүз тыңлаучан, зарарсыз малай булган. Керпе малаеның аяклары менә минеке кебек кыска икән, артык кызу йөгерә алмаган. Куышып уйнаганда хәйләгә керешеп, йомгак күк тәгәри торган булган. Беркөнне алар бик озак уйнаганнар, Куян шаркылдап көлә-көлә чапкан да чапкан, үзе, Керпе малае узып китмиме дип, әле уңга, әле сулга карый икән, шуннан аның ике күзе ике якка карый торган булып калган. Ә Керпе малае, Куян артыннан җитә алмагач, хурланып, черек агач

төбенә утырган да кычкырып елап җибәргән. Куян аны ишетмәгән, күрмәгән, аткан ук кебек очып бара торгач, аркылы яткан елганы да сикереп төшкән, елга артындагы болынны да кисеп чыккан. Бакчачы мужикның читән коймасына килеп тәртелмәсә, тагын әллә кайларга җиткән булыр иде, бәлкем. Шып туктаган Куян, үрелеп читән аша караган. Караса, күрә: тигез-тигез түтәлләрдә аксыл-яшькелт түмгәкләр тезелеп утыра. Бу нинди түмгәкләр икән, нишләп бер дә күргәнем булмады икән дип кызыксынган бу. Читән аша сикереп төшкән дә тәпие белән тибеп караган, түмгәкләр җиргә нык береккәннәр, кымшанмаганнар да. Иснәп караган Куян, урмандагы үлән исләреннән дә тәмлерәк ят ис килгән алардан. Тешләп тә караган Куян. Әнекәйләрем лә! Рәхәтләнеп күзен йомып, әчкелтем-татлы суны йотып җибәргән бу, мин сиңа әйтим, тагын китеп алган яшел яфракларны, тагын, тагын... Азмы вакыт үткән, күпме вакыт үткән, кем дә белми. Берзаман Куяныбыз, җирдән аерылып, һавага күтәрелә башламасынмы! Күзләрен ачып җибәрсә... Әтекәйләрем! Бакча хуҗасы аның озын колакларыннан эләктереп алган да борыны төбендә бармагын янап тора, ди. Каушап калган Куян, курыккан, теле тотлыккан, ни әйтергә дә аптыраган. Ахырда сүз юктан сүз булсын дип:

— Бу нә-нә-әрсә? — дип сораган.

— Кәбестә! — дигән ачулы мужик.

— Тә-тә-тәмле! — дигән Куян, әле һаман дер-дер калтырап.

— Тәмле булса үзең үстер, кеше бакчасында каракланма, үзең үстерсәң тагын да тәмлерәк була ул.

— Ничек үстерәләр соң аны?

— Базарга барып кәлшә[1] аласың да җиреңне йомшартып утыртасың. Иртә-кич су сибәргә онытмасаң, үсә дә үсә инде ул.

— Алайса, җибәр син мине, базарга барыйм әле.

---

[1] Кәлшә — үсенте, үренте.

Казанга ук барсам, кәлшәнең шәбрәген дә алырмын, тизрәк тә үсәр дип, Куян туп-туры поездга чапкан. Хәле бетеп станциягә килеп җитсә, кешеләр билет алырга чират торалар икән. Ә Куян билет алырга кирәклеген исеннән дә чыгарган, акчасы кәлшәгә җитәрлек кенә икән. Утыра икән бу уйламыйча эшләгәненә үкенеп, кире кайтып китәргә дә ашыкмый икән. Билетлы кешеләр билетларын күрсәтеп эчкә кереп утыргач та, поезд кузгалып киткән. Моңаеп утырган Куян яныннан актыкка вагон да узып бара икән инде. Кылыен кылый Куян, алай да үз кирәген күреп алган бит бу. Соңгы вагонның түбәсеннән баскыч кебегрәк бернәрсә төшеп тора икән бит. Нигә шуңа тотынып бармаска? Ике уйлый торган гадәте юк икән Озынколакның. Поездны куып җиткән дә ялт итеп сикереп тә менгән. Бара икән бу аякларын селкеп, сөенеченнән сызгырып... Шулай да шәһәргә барып җитә алмаган, аның утырганын кызыл фуражкалы абый карап калган булган. Телефоннан шалтыратып икенче станциядәге кызыл фуражкалы абыйга хәбәр иткән. Поездның килеп туктавы булган, эләктереп тә алганнар Куянны.

— Эләктеңме, кылый, түлә хәзер штраф,— дигәннәр.

Нишләсен, мескен Куян, кәбестә кәлшәсенә дигән акчасын түләп, урманга сызган. Шулай итеп, ул кәбестә үстерергә өйрәнми калган, җае чыкканда, мужик күрмәгәндә, бакчасына кереп, тансык ризыктан авыз итеп киткәли икән. Ә билетсыз йөрүчеләрне менә шуңа куян дип әйтәләр икән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятнең геройларын әйтегез. Алар халык әкиятләрендә дә очрыймы?

2. Ни өчен әкиятләрдәге төрле җанварлар кешегә хас сыйфатлар белән сурәтләнәләр икән? Аларның кешеләр белән сөйләшә, аралаша алулары без алда өйрәнгән нинди әдәби жанрга да хас иде?

3. Әхмәт абый бу әкиятне нинди максат белән, ни өчен сөйләгән икән? Куян сезнең күз алдында нindирәк «малай» булып гәүдәләнде?

4. Әкиятнең сөйләм теленә игътибар итегез әле. Ул ничек башланып китә? Табигать нинди итеп тасвирланган?

5. Куян үзенең холкы-характеры, үз-үзен тотышы белән без алдагы дәресләрдә танышкан кайсы геройларны хәтерләтә?

ӘСӘРНЕҢ ГЕРОЙЛАРЫ

Әсәрнең геройлары дип без вакыйгаларга катнашучыларны атыйбыз. Сүз алар турында бара, укучының игътибары аларга юнәлтелгән була. Димәк, вакыйгалар уртасында, игътибар үзәгендә торган өчен шулай дип атыйбыз.

Югыйсә герой сүзенең башка мәгънәсе дә бар. Тормышта герой дип ниндидер батырлык эшләгән, зур хезмәт җиңүләренә ирешкән яки төрле авырлыкларны, каршылыкларны җиңә алган к е ш е г ә әйтәбез.

Әдәбиятта исә әсәр герое һәр очракта да кеше образы булмаска мөмкин. Моның мисалларын без үткән дәресләрдә укыган әсәрләрдән китерә алабыз: сандугачлар, еланнар, Йолдыз кашка. Яки конкретлаштырып исеме белән аталмаган, гомумиләштереп бирелгән җыелма образлар: Бакчачы, генерал, илбасар.

Күрәсез, бу геройларның кайберләрендә батырлыкның нәкъ кире сыйфатлары гәүдәләнгән. Шулай да әсәрдә төп рольне үтәгәнгә, автор әйтергә теләгән төп фикерләрне чагылдырганга күрә, бу образларның яхшысын да, яманын да ә с ә р г е р о е дип атыйбыз, һәм шунда ук ачыклык та кертәбез: монысы — уңай, ә бусы кире герой дип аерабыз, каршы куябыз, чагыштырабыз.

Тик күпчелек очракта әсәр героен алай җайлы гына уңай яки кирегә, уңга яки сулга, акка яки карага аерып куеп булмый. Чөнки тормышның үзендә кешеләр — төрле сыйфатларны бергә җыйган характер ияләре, өстәвенә алар гел үзгәреп торучан булалар.

Ләбибә Ихсанова геройларына игътибар итик. Повестьның төп герое — Фаил. Вакыйгалар аның исеменнән сөйләнә, ягъни ул — хикәяләүче дә. Тагын кемнәр бар? Сыйныф җитәкчесе Зоя Михайловна, сыйныфташлары Наил, Зөбәрҗәт, Света, Сәвия, Олег, эти-әниләре һәм башка образлар. Фаилдән башка геройлар белән аңа бәйләнешле рәвештә генә танышып барабыз, әсәрдә алар ниндидер бер яклары белән генә ачылып калалар. Шуңа күрә бик үк тулы булып күз алдына килмиләр.

Фаил үзе һәм әйләнә-тирәсендәге кешеләр турында күңелендәген яшермичә, икейөзләнмичә сөйли. Димәк, безгә уй-фикерләрен, хыялларын ышанып тапшыра дигән сүз. Шуның белән үк инде ул үзенә карата теләктәшлек уята. Аның ялгыш адымнарын, вакыты белән юләрлекләр эшләгәнен (мәсәлән, «фокус» күрсәтүе) күреп торсак та, без ничектер аның яклы. Чөнки Фаилнең ни өчен алай эшләгәнен башкалар белми, ә без Фаилнең үзе сөйләгәненнән чыгып аңлап торабыз.

Фаилнең халәте, хис-кичерешләре дә безгә таныш: «Укытучыларның, бик изге теләк белән әйтелсә дә, таләпчән булуларын ошатып бетермибез, укуга күңел бирүебез дә чамалырак — анысын үзебез дә аңлыйбыз; урамда уйнарга, «шайтан чабарга» яратабыз. Нишлисең бит, бар инде бездә андый «гөнаһлар».

Шулай да Фаилне начар малай дип бәяләп куярга ашыкмыйбыз. Аның бер дә авырсынмыйча ишегалдындагыларга, күршеләренә ярдәмгә килергә әзер торуы, үзеннән көчсезләр белән «бил алышмавы», беркадәр егетлеге: өлгерлеге, җитезлеге дә бар бит әле. Әнә шундый яхшы күңелле, тик ул яхшылыгын, матур сыйфатларын әлегә тормышка ашыра, эшкә җигә белми. Фаилгә безнең мөнәсәбәтебез уңай. Өстәвенә без бит әле аның әти-әнисе дә, сыйныф җитәкчесе дә, сыйныфташлары да белмәгән серләрен дә беләбез. Бу — шулай ук Фаилне безгә якынайта торган сәбәп.

«Наил белән Фаил» әсәренең әкият өлеше үзенчә кызыклы. Әхмәт абый куян, керпе дисә дә, чынлыкта балалар турында сөйли, кешеләр һәм табигать тормышын тасвирлый. Шаянлык-наянлык, аптырап каушап калу, курку яки тәвәккәллек кебек кешегә хас сыйфатлар табигатьнең бер иркә җаны булган куянда да бар икән. Моны кешеләр күптән күреп алганнар. Шуңа күрә табигатьнең беренче хуҗалары булган кош-кортлар, җанварлар турында күпме әкиятләр, легендалар иҗат ителгән. Җир йөзендәге тереклек тә шул җан ияләреннән башланган.

Димәк, әсәр герое турында тагын бер нәтиҗә ясыйбыз: әсәр геройлары табигать күренешләре, кош-кортлар, җанварлар, хәтта җансыз предметлар булсалар да, алар җ а н л а н д ы р ы л г а н, эш-хәрәкәтләре белән кешегә охшатылганнар. Мондый образлар ярдәмендә без үзебезгә читтән караган кебек булабыз, чагыштырабыз һәм уйланабыз.

Балачак — һәркемгә таныш булган мөстәкыйль бер дөнья ул. Аның үз шатлык-куанычлары, олыларга аңлатып бетереп булмый торган мәшәкать-борчулары бар. Бу дөньяга балалар үзләре хуҗа, өлкәннәрне дә үз араларына сайлап кына кертәләр.



Шагыйрьләрнең мандаты — шигырьләре, балалар өчен куйган хезмәте, аларга мөнәсәбәте. Балалар тарафыннан үз итеп, акыллы сердәш-фикердәш итеп кабул ителү — шагыйрь өчен зур дәрәҗә. Менә шундый бәхетле язмышлы шагыйрьләрнең берсе —

Роберт Миңнуллин

(1948 елда туган)

Роберт Миңнуллинны балалар әдәбияты үзе кирәксенеп, юксынып эзләп тапты дисәк тә була. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганда, ул яшь шагыйрь буларак билгеле иде инде. «Сабантуй» газетасында эшли башлагач, балалар турында кайгыртып, аларга нәрсә кирәк, ничек ярдәм итәргә, ничек аларны аңларга икән дип уйлана торгач, Роберт балаларга бик яхшы иптәш, сердәш, киңәшче кирәклеген төшенә һәм балалар телендә яза башлый. Бу исә алар күңеленә иң якын, дөрес юл булып чыга.

Балачакның үз бәйрәмнәре, гамьнәре бар, үз яшәү кагыйдәләре бар. Ялгышмыйлармы алар, мин бала гына әле, ни кылансам да килешә дип ваемсызланмыйлармы, ни борчый икән аларны — менә шул турыда Роберт Миңнуллинның шигырьләре. Бала олысымак булып сөйләшә башладымы — юмор туа, ирексездән елмаеп куясың. Яки башка берәү дә күрмәгән, олыларның башына да

килмәгән, көтелмәгән мәгънә табып ала ул. Чөнки бала үзе ачыш ясый, үз акылы белән тормышның хикмәтле бер ягына барып җитә. Нәтиҗәдә укучы табышмакның җавабын тапкандай куанып көлеп җибәрә.

Әнә шулай куандыра, көлдерә һәм уйландыра Роберт Миңнуллин үзенең укучысын. Син дә тирә-ягыңа игътибар беләнрәк карый башлыйсың, чагыштырасың, нәтиҗә ясыйсың. Синең дә күңел күзләрең үткенрәк күрә, зиһенең җитезрәк эшли башлый.

ЭНЕКӘШ КИРӘК МИҢА!

Сезгә рәхәт! Берегез дә
Минем хәлдә түгел сез.
Беләсезме, өйдә миңа
Кызык түгел, күңелсез.
Елыйсы да килә кайчак,
Уйлап ятам-ятам да:
Юк шул минем абыем да,
Юк шул минем апам да,
Сеңлем дә, энем дә.
Бергә-бергә уйныйсым
Бик тә килә минем дә.
Ә күршеләр гөр килә:
Уйныйлар, шаяралар.
Алар күп шул, күмәк шул —
Шуңа да шаян алар.
Бер иптәш кирәк миңа,
Энекәш кирәк миңа!
Яратыр идем мин аны,
Хәтта елак булса да.

Бакчага да илтер идем,
Хәтта ерак булса да.
Энем белән мин урамга
Уйнарга чыгар идем.
Әгәр мине тыңламаса...
Ничек тә чыдар идем.
Әтиләр бит ничә кабат,
Алабыз, дип алдыйлар.
Бердәнбер малайларына
Бер энекәш алмыйлар.
Күңелсез өйдә миңа,
Уенчык нигә миңа?!
Бергәләшеп уйнарга
Бер иптәш кирәк миңа —
Берәү генә булса да,
Ямьсез генә булса да,
Елак кына булса да
Энекәш кирәк миңа!

Сораулар

1. Шигырь җиңел аңлашыла. Шулай да җитдиме ул әллә шаян шигырьме? Ни өчен алай уйлыйсыз?

2. Сез шигырьне сөйләүче лирик геройның хәлен аңлыйсызмы? Ә сезнең үзегезгә күңеллеме, рәхәтме әллә юкмы?

3. «Күп», «күмәк» дигәндә шагыйрь нинди фикер әйтергә тели? Иптәшкә ни өчен энекәш яки абый, апа кирәк? Күршеләр яки сыйныфташлар гына җитмимени?

Шагыйрь укучысын, үзенә дә сиздермичә, олы кеше булырга әзерли: гаилә, туганнар турында уйландыра. Бердәнбер бала булсаң да, бик кадерле булсаң да, балачак ялгызлыкны яратмый, ялгызлыктан котылу өчен аңа үз тиңе, иң якын булган кеше — бертуганнары кирәк.

Чынлап та, олы кеше булып уйлану өчен, ара ерак калмаган: әгәр дә бу «мин»нең әти-әнисе дә булмаса? Ул бөтенләй ятим булып кала бит! Бу чакта инде зур фаҗига, хәсрәт башлана. Шагыйрь, үгет-нәсыйхәт бирмичә генә, үз күңелең аша башкаларны да кайгырта белергә, ялгызлыкның авыр хәл икәнен аңларга өйрәтә. Ялгызлыкны үзеңдә генә тою да аз әле. Чынлап та, мәрхәмәтле булу өчен, башкаларның ялгызлыгын да күрә, үзеңнеке кебек кичерә белергә кирәк. Шул турыда тагын бер шигырь укыйбыз.

ӘНИ, МИН КӨЧЕК КҮРДЕМ!

Әни, мин уйнаганда
Көчек күрдем урамда.

Әни, ул туңган иде,
Урамда кунган иде.

Әни, салкын яңгырда
Ул бик күшеккән иде,
Ул бик ачыккан иде
Һәм бик талчыккан иде,

Әни, ул улый иде,
Ул шулай елый иде,
Ул чынлап елый иде,
Ул ныклап елый иде —
Үзем ишеттем, әни.
Мин үзем карап тордым,
Шуңа кичектем, әни.

Мин аны бик
кызгандым —
Яшьләре ага иде.

Әни, аның яшьләре
Асфальтка тама иде.

Аны, әни, яңгырда
Кемдер ташлап калдырган,
Алдаштырып калдырган,
Адаштырып калдырган...

Әни, туңганга микән,
Ул бик дерелди иде.
Салкын тисә, ул көчек
Тышта терелми инде.

Нишләр инде ул анда,
Бер ялгызы урамда?

Ул елыйдыр әле дә,
Дерелдидер тәне дә.
Иртәгә үк үләчәк,
Калдырсаң бу хәлендә...

Әнием, шул көчекне
Алып кайтыйк әле, ә?!

Кайгының зурысы-кечкенәсе юк. Кемнәрдер, бәлки әле олы кешеләрдер, алдаштырып, адаштырып кечкенә көчекне ташлап киткәннәр. Күрәсең, шул кечкенә генә җан иясенә карата да хәйлә-мәкер корганнар. Үзенә ышанган җан иясенә хыянәт бит инде бу! Зур шәһәрдә, никадәр кешеләр арасында көчек япа-ялгыз калган. Салкында-яңгырда туңып, ул бәләкәй көчекнең тәне калтырый, аны кызганудан сабый баланың җаны тетрәнгән.

Тормышның рәхимсезлеге белән очрашкан ул бала күңеле нинди кызганучан, керсез әле. Дөньяның бу гаделсезлеген төзәтергә, ярдәм итәргә ашкынып торган бала — матур образ. Әлегә ул үзе генә бу хәлне төзәтә дә алмый, энисенең дә көчекне кызгануы, өйгә алып кайтырга рөхсәт бирүе кирәк. Әмма бала кулыннан килгәнне эшли: энисенә энә ничек итеп ялына, аны да ышандырырга тырыша, көчекнең кызганыч хәлен бик ачык күз алдына китерерлек сүзләр таба.

Биремнәр

1. Көчекнең хәлен тасвирлаган сүзләргә игътибар итегез, бер үк мәгънәне төрле сүзләр белән кабатлау нигә кирәк булганлыгын аңлатыгыз.

2. Бу шигырьгә рәсем ясагыз.

3. Энисе балага нинди җавап бирер икән, шул турыда фикер алышыгыз.

БАТЫРЛЫК ЭШЛӘР ИДЕМ...

Ничек эшлим
Шәп батырлык? —
Бөтен дөнья
Шаккатарлык!

Батырлыкка
Сәләт кирәк.
Сәләтем бар —
Сәбәп кирәк!

Эзләп йөрим
Шул сәбәпне,
Иң бәхетле
Шул сәгатьне.

Тик сәбәпне
Табып булмый,
Тапмыйча да
Калып булмый.

Әрәм ята батырлыгым —
Уйланам шул хакта гына.
Үч иткәндәй, җае чыкмый
Иң-иң батыр чакта гына.

Батырлыклар эшләү җиңел,
Батыр булсаң, җайлы гына.
Батырлыклар эшләр идем —
Чыкмый әле җае гына.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Мин» исеменнән сөйләүче герой ни өчен елмаю-юмор уята?

2. Нинди батырлык турында сүз бара? Батырлык эшләү өчен, нинди сәбәп кирәк?

3. Батырлыкны сез ничек аңлыйсыз? Мисаллар китерегез.

ШУНДЫЙ МИНЕМ ТУГАН ЯГЫМ

Ак чәчәкләр чыңлап тора,
Җырлап тора әйләнәдә.
Ак каеннар сылу-сылу
Яшь кызларга әйләнә дә

Җыйнаулашып, тезелешеп
Төшеп китә Сөн буена,
Яп-ялангач калып кына
Су керергә төн буена.

Ә малайлар шундый монда:
Хикмәт кенә уйлап йөри,
Япь-яшь кенә яшеннәрне
Камчы итеп уйнап йөри.

Шул камчыны шаяртып бер
Шартлатсалар болгый-болгый,
Баш очында утлар уйный,
Күкләр күкри ургый-ургый...

Тайлар монда бер урында
Чыдый алмый биеп тора.
Ә басулар шундый биек —
Офыкка ук тиеп тора...

Менә шундый инде минем
Туган җирем, туган ягым.
Мин түзәлә алмам, ахры,—
Мактаныйлды менә тагын!

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь сурәтләгән күренеш, гаҗәеп хәлләр сезне ышандырамы? Мондый хыялый картина ясау авторга нигә кирәк булган?

2. Строфаларны берләштергән охшаш яңгырашлы сүзләрне — рифмаларны билгеләп чыгыгыз. Шигырь җиңел истә каламы? Күңелдән берничә строфаны ятлап карагыз.

3. Үз туган ягыгыз белән шулай «мактанып» күрсәтегез.

4. «Ак чәчәкләр җырлап тора», «Ак каеннар су коенырга Сөн буена төшеп китә» кебек күчерелмә мәгънәдәге яки гадәттәгедән арттырылган сүзләрне, күренешләрне табыгыз. Аларны шигъри телдән гади сөйләм теленә әйләндерсәгез, ничек әйтер идегез?

КАЙТЫЙК ЛА ҮЗЕБЕЗГӘ!

Диңгез матур,
Сүз дә юк.
Мондый диңгез
Бездә юк.
Ләкин теге ягына,
Ләкин теге ярына
Йөзеп тә чыгып булмый,
Төбенә чумып булмый.
Тотып булмый балык та,
Юк биредә таллык та.
Тозлы икән суы да —
Чистартмыйлар шуны да.
Эчкә үк кереп булмый,
Иркенләп йөреп булмый:
«Кермә!» — диеп торалар,
Керсәң, кире боралар.
Кайтыйк ла
Үзебезгә —
Кечкенә
Сөнебезгә!

Бала олысымак булып сөйләшә башласа, юмор туа дигән идек. Олысымак булып күренергә тырышуның мактануга, булдыра алмаганны булдыра алам дип ялганлауга әйләнеп китүе дә мөмкин. Мәсәлән, «Батырлык эшләр идем» шигырендәге герой кебек.

Ә бу шигырьдә — бөтен кызыгы шунда — малай гел дөресен сөйли, мактанмый, арттырмый. Тик менә шул «дөрес»не дөрес итеп аңлата гына алмый. Беренче мәртәбә шундый зур диңгезне күреп, «Менә мин нинди шәп диңгез күрдем, бер дә курыкмадым, диңгезне бик яраттым» дип, мәсәлән, мактана да ала иде бит әле ул. Бала күңеле әнә шул самимилеге белән матур: диңгезне үзенә бик таныш булган, якын булган Сөн елгасы белән чагыштырып, үлчәп карый да күрә — бернәрсә дә ул дигәнчә түгел! Иркенләп, хуҗа булып йөреп тә булмый, кирәкми алай булгач, үзебезгә кайтабыз! Күрәсезме, бик мөлаем, сөйкемле итеп, балаларча көйсезләнү, әмма олыларга иярергә тырышып, сәбәбен «аңлатып» көйсезләнү. Өйне дә сагынгандыр әле ул, җитмәсә.

Менә шундый сөйкемле, олылар кебек булырга, тизрәк үсәргә, олыгаерга, күбрәк белергә, булдырырга тырышып, дөнья белән танышып йөрүче геройлар яши Роберт Миңнуллин шигъриятендә. Шигырь юллары якты эз салып, күңелдә уелып калалар.

Туган ягы. Сөн елгасы, Башкортстанның Илеш районы — шагыйрьнең күңелендә иң матур моңнарны тудырган төбәк, экияттәгедәй гүзәл сурәтләргә әйләнеп, шигырьләренә һәм җырларына күчкән образ. Язын кошлар үз ояларына әйләнеп кайткан кебек, шагыйрь җаны, аның канатлы хыялы шул Сөненә әйләнә дә кайта. Гаҗәпләнеп тә куясың: күпме язарга була инде кечкенә генә бер елга турында?! Роберт Миңнуллин бертуктаусыз язып тора, язган саен яңара, матурлана бара аның туган ягы да.

Табигатьнең матурлыгы, гел сагындырып искә төшә торган бала чагы калган анда. Һәм тагын бер сәбәп — шагыйрьнең җанын, рухын җылытып, нурландырып торган, аны яшәргә, яратырга өйрәткән иң газиз кешесе яши Сөн буенда. Әниләр турында шигырьләр күп язылды. Гомумиләштереп, зур мәгънәләр салып язылды. Роберт бары үз әнкәсе өчен генә, бары аның турында гына яза, аңа булган рәхмәтен, әнкәсенең мәрхәмәтен күпме сөйләсә дә, аңлатып бетерә алмаганга яза. Без

дә әниләребезне шулай кадерле белсәк иде, шундый сүзләр таба алсак иде дип телисең күңелдән генә!

Шагыйрь балаларның кичерешләрен, гадәтләрен, холык-фигыльләрен белеп яза. Яшьлек, батырлык һәм шигърият символы булган Муса Җәлил исемендәге премия дә (1982 елда) аңа балалар язучысы буларак бирелде. 1998 елда шагыйрь Роберт Миңнуллин Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды, ә 2005 елда «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелде.

Шигырьләрнең геройларына игътибар итик. Аларны бу — уңай герой, монысы кире герой дип бәяләп булмый һәм алай бүлеп карарга кирәкми дә. Без үз геройларын яратып, аңлап, аларга теләктәшлек итеп, иптәш булып язган шагыйрьнең ихтыярына «буйсынабыз», аңа ияреп көләбез, куанабыз һәм уйланабыз. Бик сөйкемлеләр, бәхетлеләр икән бу балалар; бигрәк рәхәт икән ул балачак дигән дөньяда. Әмма гомер буе бала булып кала алмыйсың бит, зур дөньяга чыгарга, анда да үзеңнең әти-әниеңә, туган җиреңә булган ярату хисеңне сүндермичә яшәргә кирәк. Шулай булганда гына син зур тормышта бәхетле булачаксың.

Шундый ике дөньяны тоташтырып, бала чагындагы рәхәтлекне югалтмыйча, гел шул «рәхәтлектә коенып», чишмә суыдай «челтерәп торган» шигырьләр язучы Роберт Миңнуллин үзе дә бәхетле.

Әдәбият һәм тормыш. Үзара аңлашып, ярдәмләшеп, бер-берсен үстереп һәм яхшыртырга тырышып яшәгән ике дөнья. Тормыш никадәр катлаулырак, чишеләсе мәсьәләләр никадәр күбрәк һәм зуррак булса, әдәбият та шулкадәр кирәгрәк, әһәмиятлерәк була бара.

Язучы менә шушы ике көч арасында тора, ике арага күпер сала. Әкиятләрдә патша сарае белән ярлы егет өен тоташтырган күперләр сихер көче белән бер төн эчендә салыналар. Язучы исә үзенең әсәрләренә гомерен багышлый, талантын һәм хыял көчен сарыф итә. Шуңа күрә әдәби әсәрләрдә тылсым көче әкиятләрдәге серле урманнар, тутый кошлар, хикмәтле коелардан ким булмый. Алай гына да түгел, кеше күңеле кебек тирән һәм серле кое бары тик әдәби әсәрләрдә генә була ала. Кеше язмышы кебек бормалы, иксез-чиксез юллар да, әкияттәге серле йомгакка гына сыймыйча, әдәбиятка «тәгәрәп» чыга.

Татар әдәбиятында менә шундый зур талант ияләре, кызыклы шәхесләр иҗат итте. Аларның һәр әсәре — тормыш турында зур ачыш, иҗатлары — тормыш мәктәбе, яшәү фәне. Шундый зур язучыларның берсе —

Мөхәммәт Мәһдиев
(1930—1995)

Татар язучыларының борынгыдан килгән бик матур традицияләрен дәвам итеп, Мөхәммәт Мәһдиев хезмәт юлын аң-белем бирүдән башлап китә. Арча педагогия көллиятен тәмамлап, хәрби флотта хезмәт итеп кайтканнан соң, изге бер эшкә керешә — ун елга якын авыл мәктәпләрендә тарих фәнен укыта. Казан дәүләт педа-

гогия институтында югары белем ала. Казан дәүләт университетында аспирантура тәмамлый, кандидатлык диссертациясен яклый.

Шуннан соң ул 25 елдан артык университетта татар әдәбиятын укыта, бер үк вакытта әдәби әсәрләр дә яза.

Укытучы, галим, язучы — ничек бер кеше барсына да өлгерә, һәр өлкәдә бердәй көч белән нәтиҗәле итеп эшли ала? Талантның ни икәнлеге әлегә кадәр сер булып кала, шулай да Мөхәммәт Мәһдиевнең галимлеге язу эшенә, язучылыгы фәнни хезмәтләренә ярдәм иткәнлеген күреп сокланасың. Иң әһәмиятлесе — ул үзенең көчен, сәләтен яшьтән, бик яшьтән чыныктырган кеше, үзенең характерына, максатларына хуҗа була алган шәхес.

Татар әдәбиятында ул «Фронтовиклар», «Каз канатлары» романнары, «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Исәнме, Кәшфи абый» повестьлары белән танылды. Соңгы елларда иҗат ителгән «Мәңгелек яз», «Бәхилләшү» әсәрләре өчен Мөхәммәт Мәһдиев Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде. 1993 елда «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән исем бирелде.

Аның иҗаты югары уку йортларында тулысынча өйрәнелә, китап укучылар арасында да ул — яратып укыла торган язучы. Без Мөхәммәт Мәһдиев белән танышуны иҗатының чишмә башыннан — беренче повестеннан башлыйк.

БЕЗ — КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ

(Повестьтан өзекләр)

Менә дигән бер майор...

Коридорга чабата тузаны аркылы көлтә-көлтә булып кояш нурлары сузылган иде. Менә дөньяның рәхәте кайда икән! Әле кичә генә без колхоз басуларында көлтә кертә, бәрәңге ташый идек. Үгезне туарып, тәртә арасыннан этеп чыгарганга әле тәүлек тә тулмаган. Тырнак төпләрендәге дегет, оекбаштагы арпа кылчыклары, бирчәйгән уч төпләре — кичәге тормышның истәлеге әнә шулар. Миләр катып калган, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай. Миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар.

Аның берсе — сугыш, канкойгыч сугыш турында. Фронтка икмәк кирәк. Без, атасыз калган тәртипсез малайлар, әнә шул икмәкне кырдан җыеп, заготзернога озатырга тиешбез. Без инде һәр җәйне шулай эшлибез. Мидә икенче сыр — ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Көлтә йөгендә утырып кайтсаң — бодай башы уып ашыйсың. Урман буенда — күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый. Амбар тирәсеннән узганда, кесәгә борчак тутырып китәсең. Алабута, кычыткан, чөгендер, яшь бәрәңге яфрагы — болары ашка китә. Табигать бай — үз баласын ул ничек тә саклый. Мидә өченче сыр... Өченчесе — юк. Кичә юк иде...

Бүген беренче октябрь. Без, аркага капчыкларыбызны асып, кемнеңдер теләге буенча, укырга килдек. Үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр төтенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан безне кем аерды? Ник аердылар? Моны беребез дә белми иде.

Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, әвендә киптерелгән, төтен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп, тән ныгып беткән — бүген әнә шул көчне кая куярга белгән юк. Кичә кичен генә мунча кергәнне сылтау итеп, бүген битен дә юмаган унбиш-уналты яшьлек малайлар училище коридорында колхоз тузанын кагалар. Менә коридорның бу почмагында Түбән Кенә малайлары. Барысы да чиста ыштырдан, яңа чабатадан. Менә зәңгәр сырмалар кигән Карадуган малайлары — һәммәсе кишер ашыйлар. Мөрәле малайлары кесәләрен әйләндереп бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар. Чабыш атлары кебек барсының да борын тишекләре киңәйгән. Беренче кыңгырау чылтыраса да, класска керергә уйлап та караган кеше юк.

Кинәт өлкән класс малайларыннан берәү:

— Завуч!..— дигән бер генә сүз кычкырды да класска кереп юк булды. Аның артыннан коридорның яртысы

бушап калды. Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм, без туң миләребезне кыймылдатып өлгергәнче, тузан болыты эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде. Миләр кыймылдады. «Әһә, шул ике пыяла завуч икән»,— дип уйлап алдык. Ике пыяла безне гипнозлагандай итте. Аяклар масска өстерәделәр. Коточкыч тынлык урнашты. Мин класска күз төшердем. Бүреген салырга акылы җиткән Мөрәле малайларының чәч төпләренә хәтле кызарган башларыннан пар күтәрелә. Нәкъ шул секундта ишек ачылып аннан ике түгәрәк пыяла күренде. Миләр кызу-кызу эшләделәр. Нигә алай? Нәрсә, безнең кеше күргәнебез юкмы әллә? Безме? Без бит — фронтка икмәк җитештергән малайлар...

— Шапки снять!

Тәрәзә пыялалары зыңгылдап китте. Кемнеңдер парта астындагы сөт салган чирек литрлы шешәсе идәнгә тәгәрәде. Завуч рус теле укытучысы икән.

Тынлык урнашты. Тәрәзәдән еракгагы сары басу күренә, аның күк белән тоташкан урынында тук кибәннәр өем-өем булып утыралар, биектә-биектә тилгәнме, ниндидер кош тирбәлә. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Көлтә йөге өстендә үгез көенә баруы нинди рәхәт иде! Ә монда кыймылдарга да шикләнеп утырасың... Күзлекле кеше кесәсеннән саплы зур тарак алып озын чәчләрен рәтләде. Аннары күзлеген салып, аны ап-ак кульяулык белән озаклап сөртте. Күзлеген салгач, бу кеше бөтенләй хәтәр булып тоелды. Гел йөгән белән күреп ияләнгән ат янына йөгәнен салгач барырга куркасың. Ул әллә нинди талый торган ат күк тоела...

— Мин сезгә рус теле укытырмын, ребятки,— дип, күзлекле сүз башлады.— Мин бүгенгә сезнең белән татарча сөйләшәм. Ләкин без, акрынлап, дәрестә русча сөйләшүгә күчәрбез.

Һи-и, безнең өчен ул яңалык түгел! Без моны инде бишенче класстан бирле ишетеп киләбез. Барыбер, бернәрсә дә чыкмаячак. Бик әллә кем булып кылансаң,

үзеңне сугышка да алып куярлар әле. Гәүдәң бик тәз, тавышың таза күренә. Менә дигән бер майор чыгар үзеңнән...

— Миңа алтмыш яшь,— дип дәвам итте күзлекле, калын, көр тавыш белән, классның нәрсә уйлаганын сизгәндәй.— Минем сезне культуралы, белемле кешеләр итеп күрәсем килә. Укып бетергәнче, миндә рус теле өйрәнсәгез — үкенмәссез. Мин үзем — Мәскәү татары. Поездларда йөргәндә, сезнең як халкының рус сүзләрен сытып сөйләшүенә минем йөрәгем әрни. «Врач бареньe белән чәй эчә» дип сөйләгәннәрен ишеткәндә, мин бөгелеп төшәм, оялуымнан кая керергә белмим. Беренче дәресне без шуңа күрә бик җиңел бер эштән башларбыз. Сез миңа ике баганага бишәр сүз язгыгыз. Беренче баганага «б» авазына, икенче баганага «в» авазына башланган сүзләр булсын. Мин шул сүзләрдән чыгып кемнең кем икәнен үзем чамаларрмын...

Борыннар тартылды, каләмнәр кыштырдый башлады. «Җиңел» генә дигән эш шактый авыр булып чыкты. Парта араларыннан кайнар һава күтәрелгәндәй булды, кемнеңдер каләме сынды, берәүнең карасы, түгелеп, кемнеңдер чалбарын буяды, кайсыдыр язуын бозды...

Зур газаплар белән унар сүз язылып бетте. Күзлекле парта араларында йөри башлады. Ул һәр кешенең дәфтәрен алып, күз йөртеп чыга. Һәр дәфтәрнең үзенә аерым чырае. Бертөрле дәфтәрне алгач, «әһә-әһә» дип тиз генә карап ала да:

— Кайсы мәктәптән? Укытучың кем иде? — дип сорый. Кайбер дәфтәрне почмагыннан чеметеп җирәнеп кенә кулына ала, авызы кыйшаеп китә, йөзе сытыла. Үзе бер сүз дә дәшми, теге малай да моның чытык йөзен күреп кып-кызыл булып утыра, башын аска ия...

— Фамилия?

Тәрәзә пыяласы тагын зыңгылдап китте. Тез башлары ямаулы күксел чалбар кигән Мөрәле малае, үлем җәзасы алган кешедәй, башын түбән иде, партаны

шыгырдатып басты. Ун минут элек кенә бу малай коридорда бөтенебезне чалып егып, изеп йөргән иде.

— Зарифуллин,— диде ул, ияген бишмәт якасына яшереп. Күзлекле исә башкача бер сорау да бирмәде. Ул Зарифуллинның пычранган дәфтәрен парта өстенә төшереп җибәрде. Аннары кесәсеннән дүрткә бөкләнгән ап-ак кульяулык алды да бармак очларын сөртте. Моны ул шулкадәр чын итеп эшләде, бу вакытта бөтен классның күзе шунда гына булды. Әйтерсең Зарифуллинның дәфтәр битендә микроблар өелеп яталар икән, әйтерсең ул микроблар күзлекленең кулына да үрмәлиләр икән. Бу микроблар керсә, кешене чирләтәчәк икән...

...Мәскәү татары, шулай итеп, бу дәрестә безне җиңде. Ормады, сукмады, хәтта бер генә тапкыр ачулы сүз дә әйтмәде, шулай да җиңде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Вакыйганың кайсы чорда барганлыгын нинди сурәтләрдән аңлап була?

2. Вакыйгага катнашучыларны — әсәрнең геройларын автор ничек сурәтли? Сез кемне аерып хәтердә калдырдыгыз, тышкы кыяфәте белән күз алдына китерегез.

3. Малайлар укырга кая килделәр, кайлардан килделәр? Укуга мөнәсәбәтләре нинди? Сәбәбе нәрсәдә?

4. «Миләр катып калган», «миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар» дигән образлы җөмләләрне ничек аңлыйсыз?

Йокы кирә

Авылдан училищега кадәр нәкъ унике чакрым. Тулай торакка кичтән барып кунасы килми. Ял көнне анда салкын, шыксыз була. Болай, ичмасам, атна кыскара: биш кич кунсаң, атна тәмамлана. Ләкин дүшәмбе көн иртән торып дәрескә баруы — әҗәл. Кемдер: «Дүшәмбе — авыр көн»,— дип әйткән, имеш. Ул кеше моны

инде дүшәмбе көн иртән йокыдан торуны искә алып әйткәндер.

Тышта әле караңгы. Утлар алынмаган. Буран себереп тора. Менә Рәдифләр тәрәзәсе. Ут юк. Рәдиф, сигезенчене бетергәч, прицепщик булып эшли башлады да менә кышкы төндә рәхәтләнеп йоклый. Алар өендә йокы аеруча тәмле. Менә киң чиста идән. Анда тәгәрәшеп Рәдифнең энеләре йоклый. Аска толып, тун җәйгәннәр. Чәбәләнеп беткәннәр. Бер энесенең аягы икенче бер энесенең муенына салынган. Ә иң кечкенәсе, ике яшьтәгесе, мүкәләгән килеш капланып яткан. Аларда һәр төнне шулай. Их, нигә генә укып йөрергә, нигә прицепка гына утырылмаган соң?

Авыл артта калды. Алда кара-кучкыл урман. Анда буран юк, бүрекнең колакларын ычкындырасың. Тыптын, җылы. Менә аланда печән кибәннәре. Ул кибәннең астында бик рәхәттер. Анда берәр җәнлекнең оясы бардыр. Алар, әтисе, әнисе, балалары бергә җыелышып, җир җиләге исе килеп торган печәндә рәхәтләнеп йоклыйлардыр. Их, нигә безнең заманда могҗиза булмый икән? Булсын иде менә шулай: синең каршыңа бер кеше килеп чыга. Ул сине таный. Болай, ди:

— Энекәш, бүген уку төштән соң бит...

Менә шуннан, нәкъ шушы турыдан печән кибәннәре янына кереп китәр идең дә астына ук кереп йоклар идең. Озак итеп, рәхәтләнеп йокларга иде. Ләкин теге кеше чыкмый... Кибәннәр инде артта калдылар.

Яктыра башлады. Урман да бетте. Кырда салкынча, себерә торган буран. Иртәнге сорылыкта урман кырындагы училище бинасы күренә. Бер катлы агач йорт, урман буена сыя алмыйча, кырдагы кар диңгезенә таба сузылып, таралып ята.

Класста җылы. Морҗа исе, башка тия торган зәңгәр ис. Бөтен буыннар талып кала, тар парта арасында тик утыруы шундый рәхәт... Ләкин күзгә нәрсәдер өелә, нәрсәдер укытучы өстәле яныннан очып килә, туп-туры синең күзеңне каплый, баш аска төшеп китә... Юк, бу

әйбер бинокль икән. Әнә шуның ике трубасы эченә йокы тутырылган. Тыгызлап. Шул бинокль кара тактадан ычкына да, салмак кына тирбәлеп, синең күзеңә килеп терәлә. Менә труба эчендәге төтен сыман әйбер чыгып синең күзләреңне каплый. Баш кисәк кенә аска сыгылып китүгә, бинокль юк була.

Әллә каян укытучы тавышы ишетелә:

— Баш килеш: Буран.

Иялек килеш: Буранның.

Юнәлеш килеш: Буранга,—
дип нәрсәдер сөйли. Шул арада бу сүзләр барысы да вак кисәкләр булып оча башлыйлар. Аларның һәрберсе бер кисәк йокы икән. Алар күзгә килеп керәләр, башны авырайталар. Баш тула, «Буран, буранның, буранга... Буран, буранның, буранга...» Өстәл янында басып торган апа да һич тә укытучы түгел. Ул теге печән кибәннәре янында очрарга тиешле кеше икән. Ул кеше дә түгел, ә әллә нинди мамык сыман төтеннән оешкан бер гәүдә икән. Ул үзе йокы икән. Менә ул аз-азлап йокы очырта икән.

— Буран, буранның, буранга...

Буран, буранның, буранга...

Мамык сыман гәүдә бөтенләй таралып беткәч, барлык укучыларга башларын өстәлгә салып теләгәнчә йокларга рөхсәт ителәчәк икән... Юк, алай түгел, монда парталар юк, бу — печән кибәне төбендә икән. Менә хуш исле печәнне тишеп кергәннәр дә йомшак тәпиләренә башларын салып ике куян йоклап ята. Ул куяннарның берсе — баш килеш, икенчесе иялек килеш икән. Ә кибәннең бу ягын өстән зур итеп казыганнар. Анда Рәдиф үзенең энеләре белән йоклап ята. Кечкенә энесенең аяк бармагы Рәдифнең авызына ук тиеп тора, барысы да күкрәкләрен селкетә-селкетә мышныйлар. Шунда ук кибән төбендә бер патефон әйләнеп утыра. Пластинкадан бию такмагы ишетелә:

— Буран, буранның, буранга...

Шул көйгә кибән арасында бер олы апа бии. Үзе бии, үзенең күзләре йомык, рәхәтләнеп йоклый. Әһә,

ул таныш кеше — татар теле укытучысы Рабига апа икән. Куяннар да, Рәдиф тә, аның әниләре дә, Рабига апа да рәхәт чигәләр... Тик сине генә ниндидер ачы тавыш бүлдерә. Ул — кыңгырау тавышы икән.

Грамматика дәресе тәмам.

Өйгә эш: «Чиләк» сүзен ике төрле санда да төрләндереп дәфтәргә язып килергә...

Рабига апа җәнлек тиресеннән теккән соры тунының җиңеннән кулларын чыгара. Аның дәресе дүшәмбедә беренче сәгать булганлыктан, соңга калучылар да, йоклап утыручылар да була. Йоклаган укучыларга ул ачуланмый. Тик дәресеңне генә белеп кил.

— Сезнең каныгыз азайган,— ди ул.— Менә сугыш бетәр, теләгәнчә шикәр, яшелчә, җиләк-җимеш ашарсыз. Йоклау — кан азлыктан ул...

Шулай да йокы — рәхәт эш.

Сораулар һәм биремнәр

1. Барасы озын юлын автор ничек итеп «кыскарта»? Ни өчен бик иртә йокыдан торулары авыр булса да, ул юлга чыккан?

2. Йокы килү халәтен автор ничек, нинди сүзләр белән тасвирлый? Шул урыннарны укып чыгыгыз. Сез тагын нинди сүзләр табар идегез?

3. Укытучы Рабига апа ни өчен йоклап утыручыларга ачуланмый?

4. «Их, нигә генә укып йөрергә?», «Их, нигә безнең заманда могҗиза булмый икән?» дигән җөмләләр нинди хис-кичерешне белдерә? Без «их!» дип кайсы очракларда әйтәбез?

Сугыш турында хикәяләр

Складта бәрәңге әрчегән төнне күңелле була. Беренчедән, ул төнне төне буе ашыйсың. Кәбестә, кишер, суган — нәрсә бар, барысын да. Икенчедән, ул төннән соң дәрескә бармаска рөхсәт ителә. Иртән сәгать

өчләрдә кайтып йокыга таласың, таласың... «Минем иртәгә дәрескә барасы юк бит әле» дип йокыга яту — үзе бер ләззәт. Иртән кычкырышып сикереп торалар, чәйгә йөгерәләр, бераздан бүлмәне җыештыралар. Син боларның барысын да сизеп йоклыйсың. Аның саен йокыга тәм керә бара. Менә-менә, сине караватың-ниең белән күтәреп күчерәләр, менә кемдер мыш-мыш килеп синең караватастында идән юа, җәфалана, ә синең эш — йоклау! Рәхәт бу дөнья. Менә сине яңадан үз урыныңа күчерәләр, ашыгып дәрескә чыгып йөгерәләр. Бөтен төкләрең белән сизеп йоклыйсың: менә педагогика укытучысы класска керде, менә берәүне бастырды, теге малай, әлбәттә, газап чигә — ә син киерелеп йоклыйсың... Сиңа бу вакытта берни дә кирәк түгел, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия бирү мәсьәләсе дә, гөберле баканың ашказаны системасы да, сыйфат ясагыч кушымчалар да, хәтта Елизавета патшаның ничә күлмәге булуы мәсьәләсе дә сине кызыксындырмый. Ләкин складта уздырган төннең тагын бер күңелле ягы бар әле: склад мөдире һәм шундагы бөтен складларның төнге каравылчысы Сабир абзый — хикәяче. Искиткеч ипле, җайлы кеше. Педучилищеның каравылчысы да педагогиканы белә торган кеше була икән! Ул төннәр буе утырып сөйләргә ярата.

Сабир абзый, мичтән күмер алып, тәмәкесен көйрәтә. Тирән сулап куя. Бүреген салып, яртылаш агарган чәчләрен сыйпап ала.

— Миңа ничә яшь дип уйлыйсыз?

Без кишер, кәбестә тутырган авызларыбызны ярым ачып аптырап калабыз. Илле? Алтмыш?

— Юк,— ди Сабир абзый,— миңа нибары кырык сигез. Берегез дә белмәдегез. Ә бу чәч нидән агарган дип уйлыйсыз?

Без тагын җавап бирергә омтылып карыйбыз. Җәфа күрүдән? Кайгы-хәсрәт күп күрелгәннән? Әлтафи мәсьәләне биологик юл белән чишмәкче була. Организмда тиешле витамин җитмәгәнлектән, янәсе.

— Юк,— ди Сабир абзый, борыныннан акрын гына төтен өреп.— Беренче тапкыр фашистлар белән очрашканда шулай агардым. Ярты сәгать эчендә. Сезнең кеше асканны күргәнегез бармы? Юк. Күрергә язмасын. Кырык беренче елны Смоленск өлкәсендә беренче тапкыр разведкага бардым. Мин разведкада идем яраланганчы. Үзебезнең старший лейтенант, мин и тагын бер латыш малае. Таза, әллә ничә фашистыңнан кәтлит ясарлык. Ну, минем дә куәтле вакыт. Төн уртасында шуышып кереп, авыл кырыендагы бер ташландык мунчаның очырмасына урнаштык. Задание: авылда нинди часть тора, штаб йорты кайда, таш юлдан нинди техника килә. Һәммәсен дә хәтергә алырга. Атарга, тавыш чыгарырга ярамый. Бездән мәгълүмат алып кайту гына сорала. Яктырды. Черек түбә ярыгыннан карап ятабыз. Кая эләккәнбез дип уйлыйсыз? Авыл Советы йорты янына. Авыл читендә ике катлы йорт. Бездән нибары илле-алтмыш метр читтә. Урам тулы мотоцикллар. Иртән хәрәкәт башланды. Тын да алмый ятабыз. Безгә төчкермичә, ютәлләмичә көн уздырасы гына калды. Безнең позиция шәп. Күзәтәбез. Немец малайлары шат күңелле халык булып чыкты — штаб малайлары булды, ахрысы. Урамга чыгып котелоктан су салып юындылар, берберсенә су сибештеләр, шау да шу иттеләр, берсе, артист шикелле кыланып, әллә ни әкәмәтләр ясап күрсәтте, җырлады, биеде, и мин сиңа әйтим, үзләренчә кычкырышалар, ихахайлап көләләр. Белми бит адәм баласы үзләренең уч төбендә кебек күзәтү астында икәнен. Белми. Одним словом, бу егетләр ошады миңа. Нүжәли шушындый шат чырайлы таза егетләр безнең җирдә кеше талап, бала-чага, карт-корыны атып йөриләр, мин әйтәм.

Сабир абзый авыр сулап тын ала. Аның тәмәкесе инде болай гына төтенли, ул аны суырмый да. Күзләрен билгесез бушлыкка тери, күз алмаларында мичнең кызгылт ялкыннары чагылып ала.

— Шуннан нәрсә булды дип уйлыйсыз? Сәгать нәкъ унда ябык машина килеп туктады. Уен-көлке бетте.

Урам буйлап фашистлар йөгереште. Шау-шу китереп халык җыйдылар. Картлар да бала-чага. Фашист солдатлары автоматларын таккан килеш стройга тезелделәр. Площадь тынды. Минем нервлар ычкынды бугай — дерелдим икән. Иске мунча селкенә башлады. Старший лейтенант шыпырт кына әйтә: ир кеше бул, Гарипов, ди. Хәзер, ди, болар җәза оештырачаклар. Әнә, ди, күр!

Читкәрәк карасам, исләрем-акылларым китте. Баулар, колгалар асылган физкультура станы була бит әле? Шуның бер бавына элмәк ясап яталар. Минем күзне әллә ниткән пәрдә каплады. Кыймылдарга ярамый. Ә тегеләр тыныч — иптәшләрне әйтәм. Алар инде әллә ничәнче тапкыр. Миңа нәрсә? Мин — үз гомеремдә тавык суймаган кеше. Тәбегә койрыгыннан гына эләккән тычканнарны кызганып, ычкындырып йөри идем мин. Шулай ятабыз. Зур нәчәннекләре чыкты. Янында йөгерешеп офицерлар йөри. Ябык машинаны ачтылар. Кем чыкты дип уйлыйсыз? Куллары артка бәйләнгән күлмәксез бер ир. Кыйналган, бөтен тәне-бите кан, шеш, кара янган. Старший лейтенант бинокленн суздыр. Карыйм — таза гына бер ир. Кара чалбардан, күн итектән. Бер күзе агып чыккан бичараның. Төрткәләп элмәк астына алып килделәр. Элмәк астына бер полуторка кереп туктады. Баскыч китереп сөяделәр. Муенына элмәкне киерттеләр. Площадь тып-тын. Бераздан полуторкага өч-дүрт офицер менеп басты. Ялт иткән папкалары бар. Шунда берсе, папкасын ачып, фашист телендә нәрсәдер укый башлады. Безгә начар ишетелә. Игътибар беләнрәк тыңласак, янында берсе русчага әйләндереп тора икән. Аңладык. Кичә генә авылга партизан һөҗүме булган икән. Бу — партизан. Күрәсең, эләккән. Предатель табылгандыр инде — бөтенесен белеп сөйләгәндәй итте. Коммунист, ди, сугышка хәтле шушы зур авылда мәктәп директоры булган, ди, партоешма секретаре булган, ди. Күрдегезме? Мәктәп директоры — и шул кешене площадьта, балалар алдында. Мин бинокльне

латыш егетенә суздым. Шуннан нәрсә булды дисез? Бик ачы тавыш белән үзләренчә нәрсәдер кычкырдылар да ыгы-зыгы килеп алдылар: карыйм — машина кабинасына бер фашист кереп тә китте. Мин һаман өмет итәм әле — бу, дим, куркыту гынадыр. Халыкны өркетүдер дим.

Сабир абзыйның куллары калтырый башлады. Ул яңадан тәмәке төрергә азаплана иде.

— Шуннан машинаны кабызды ук бу. Газ бирде, кузгалмакчы була. Кабинадан башын чыгарып кузовка карый. Ә теге директор тора, бичара, бер хәрәкәтсез. Менә берзаман машина кузгалды, теге бичара чайкалып китте. Мин күзләремне йомдым. Тешем тешкә бәрелгәнен хәтерлим. Шунда сизәм: пилоткам баштан чыгып маташа. Бу нәрсә булыр дим?

Без тын да алырга куркып тыңлыйбыз.

— Сезнең «чәч үрә торды» дигәнне ишеткәнегез бармы? Менә шул. Чәчләр керпе энәсе кебек үрә торган. Пилотка күтәрелгән. Үземне кемдер селкеткәнгә айнып киттем. Старший лейтенантның беләгенә чытырдатып ябышкан икәнмен. Карадым. Гәүдә чайкалып, бөтерелеп тора. Площадьта коточкыч елау тавышы. Әбиләр берөзлексез чукыналар. Китте тавыш, китте тавыш. Мылтык аскан егетләр аларны төрткәләп тарата, куа башладылар. Берсенең кулында противогаз горловинасы. Аны ишеткән бар иде, имеш, шуның очына ташмы, тимерме тыгып калдыралар икән дип. Шуның белән яра гына бу халыкны. Халыкны куа-куа, без яткан җирдән 20 метр арада узды бу. Таныдым. Теге иртән, штаб янында бөтен немецны көлдереп, артист булып кыланганы икән. Зверь дип белерсең. Карткорыны кыйный.

Сабир абзый тынсыз тора. Ул кисәкләп сөйли. Барысын да рәттән түгел.

— Менә үз кешеңне фашистлар үтергәнне шулай карап тор әле син. Ә бит бездә корал, граната. Ә ярдәм итәргә ярамый. Безнең задание аерым. Дөрес, без баеп

кайттык. Без алып кайткан сведение аларга бик кыйммәткә төште. Ну, теге момент әнә минем дә чәчләрне нишләткән? Хәзер менә каты әйбер ашый алмыйм: шул моментта тешне каты кысып, мускулларын имгәткәнмен. Да-а-а... Фашист — кабахәт халык ул. Аларның җир йөзендә эзләрен калдырмаска кирәк...

— Мин,— ди Сабир абзый,— кырык беренче елның көзендә Белый янында контузия алдым. Смоленск юнәлешендә. Аннан, госпитальдән чыккач, Сталинградка эләктем. Ишеткәнегез бармы? Ту-ты. Мин актыт камчы танга хәтле көрәштем (шушы җөмләдә ул һәрвакыт шулай авазларны бутый, ни хикмәт?), татар халкының йөзенә тап төшермәдем.

Кәбестә күчәне кимерә-кимерә тыңлыйбыз. Ул мичтәге утлы күмерне кисәү таягы белән әвәләп китерә дә тәмәкесенә ут ала. Бәрәңге әрчелеп беткән, бакларга тутырылган, иртәгесен ашханә кешеләре аны килеп алып китәчәкләр. Бәрәңге кабыгын училищеның атына дип конюх алып китәчәк. Кем белә, атка гынамы ул?

— Смоленск янында бер карт белән карчыкта кунарга туры килде. Сөйләшә киттек. Син, ди, карт, кем? Казакъмы, монголмы? Мин әйтәм, татар. Кайсы татар? Казанскиймы, Себерскиймы? Казанский, мин әйтәм. Карт та, карчык та шунда бернәрсә сөйләделәр. Аларның өендә фрицларның штабы булган. Кара төнне боларның өенә солдатлар бер партизанка тотып китергәннәр. Өстендә телогрейка, ике толым чәче асылынып тора, ди. Кара кашлы, коңгырт битле, кара күзле унсигез-унтугыз яшьлек бер һәйбәт сылу кыз, ди. Кыйнаганнар теге дуңгызлар. Ләм-мим бер сүз дәшмәгән бичара. Таң атканчы ләм-мим. Таң атканда үзләре алгы өйгә кереп йокыга яткач, карчык бу бичараның янына килгән. Кайнар чәй биргән, эчкән теге, дәшмәгән. Карчык сораган:

— Кызым, болар сине харап итә бит, атаң-анаң бармы, син кем, миннән тел яшермә,— дигән. Шунда теге кызның авызыннан бердәнбер сүз чыккан. Мин, дигән,

татарка! Менә бөтен сүзе шул булган. Мин — татарка! Иртән аны алып чыгып китканнәр. Кая? Нәрсәгә?

Сабир абзый авыр сулый.

— Фашистларның билгеле инде. Мәсхәрә итәләр дә тотып аталар. Менә, балалар, фашист кем ул.

Без тып-тын калып тыңлыйбыз.

Сораулар

1. Ни өчен складта бәрәңге әрчегән төннәр күңелле булган?

2. «Педучилищеның каравылчысы да педагогиканы белә торган кеше була икән!» Әсәрнең герое— хикәяләүче нигә шундый нәтиҗә ясый?

3. Сабир абзыйның сөйләм теле автор хикәяләвеннән аерылып торамы? Ни өчен ул рус сүзләрен күп куллана һәм аларны бозып әйтә? Ни өчен сөйләме өзек-өзек кыска җөмләләрдән тора?

4. Сабир абзыйның кичерешләрен ничек аңладыгыз? Аларны нинди сүзләр белән әйтеп булыр иде?

Таңнар кайда да матурдыр...

Җәйге каникулга кайткач, Гыйззәтуллинның бер көне авыл белән танышып үтте.

Аларның авылында зур су юк. Әүвәл-әүвәлтеннән суны көрәкләр белән кәз кисеп буып куялар да, бала-чага, каз-үрдәк шунда ята. Эссе көнне ул су бик җылы була, кояшны аз гына болыт капласа — суына. Бала-чага бик күп җыелса, суы болганчыклана, судан чыкканда борын асларына, иякке, күкрәк чокырларына ләм утырган була. Җәй бик коры килгәндә, ул су да кибә, эссе көннәрдә каз-үрдәк авызын ачып әлсерәп, тавышлары бетеп тилмереп йөри. Ап-ак казлар каралып, керләнеп бетәләр, хуҗаларына мөлдерәтеп карап, каңгырашып капка күләгәсендә торалар. Авылда су кибү — зур эш. Моны бөтен тереклек иясе авыр кичерә. Дөрес, эчәргә су бар. Авылның өч-дүрт җиреннән менә дигән

чишмә чыга. Һәр чишмәнең үз исеме бар. Чишмә суы кимеми. Әмма инештә су кипкәч, казлар каралгач (Гыйззәтуллинның сынаганы бар), халыкның табигате бозыла, кеше үзеннән-үзе холыксызлана. Холыксызланган кеше моның сәбәбен белми, аңламый, әмма Гыйззәтуллин моны бик яхшы аңлый: сусызлык хикмәте бу. Училищеда укый башлагач, Гыйззәтуллин үзенең бу күзәтүләрен тагын да тирәнәйтте. Бигрәк тә психология фәнен өйрәнгәннән соң. Аның инде үзе нык ышанган билгеле бер карашлар системасы бар. Бөтенләй сусыз авыллар була: анда кое белән генә көн күрәләр. Ярым-йорты сулы авыллар була: авыл уртасыннан инеш ага, чишмәләр ага, кечерәк кенә буалар була. Зур сулы авыллар бар: авыл читендә көзгедәй ялтырап болын суы җәелеп ята, җилле көннәрдә ул су ярларына чап-чоп бәрелеп утыра, су өсләрендә төнбоек, яр кырыйларында серле, куркыныч камышлыклар... Бакча башларында әллә ниткән басмалар, таллыклар, тугайлар... Зур сулы авылның нәрсә аның? Эштән кайталар да чишенеп ташлап суга чумалар, колач салып, кушаяклап тибеп бер йөзәләр. Анадан яңадан туган кебек буласың. Ул арада шул ук суда кер чайкап алалар, ул арада эссе кояш астында кер кибеп тә өлгерә. Зур сулы авылда тузан да булмый...

Чишмәле, инешле авылның да эш ярыйсы. Болар колхоз эшендә бик актив, боларның колхоз һәрвакыт алда, каралты-кура таза, холык-фигыль уртача. Чишмәле авылның тагын бер ягы бар: чишмә тавышын ишетеп үскән бала моңлы була. Мәсәлән, Гыйззәтуллин үзе. Гыйззәтуллин җырлый белми, әмма аның күңеле тулы моң. Аның йөрәгендә һәрвакыт бер җыр яши. Гыйззәтуллинның күңеле гел шуны җырлый.

Моңлы балага җитә ул,
Күгәрчен гөрләсә дә,—

дип кабатлый. Дөрес, моңлылыкның сәбәбен Гыйззәтуллин әле тагын бернәрсәдән күрә. Аларның авылы

урманга терәлеп кенә урнашкан. Авылның кайсы гына капкасыннан чыгып китмә — ике чакрым юл үтсәң, урман. Чишмә буенда уйнап, аякларын чебиләтеп ике-өч ел уздырган адәм баласының шуннан алдагы яшьлеге урман белән бәйле. Гыйззәтуллин әллә кайчан ук, сугыш дигән нәрсә әле төшкә дә кермәгән заманда ук, беренче тапкыр урманга барган иде. Әтисе белән. Сезнең печән салган тимер ходлы арбада җәйге матур көнне ат белән урманда йөргәнегез бармы? Әтисе атны туарып бер чыршы астына кертеп бәйләде (көн үзәгендә кигәвеннән шулай гына котыла аласың), үзе печән чапты. Гыйззәтуллин — ул вакытта әле аның фамилиясе юк, ул нибары Нурулла исемле бер малай иде — шунда биек-биек абагалар арасында йөрде. Урмандагы тавыш! Әнә карт юкә башыннан торып күке кычкыра. Әнә куелыктан «Көр-р-р! Көр-р-р!» дигән тавыш ишетелә. Әнә ана тилгәнне эзләп бала тилгән елый:

— Пиль-дер-рек!

— Пиль-дер-рек!

Тагын әллә ниткән тавышлар...

Аларның авылында таң урман почмагыннан ата башлый. Кызгылт нурларның иң беренчесе мәктәпкә әйләндерелгән ике катлы мәчетнең очырма тәрәзәсенә төшә. Аннан авыл башындагы карт нарат алтын сыман төскә керә. Кайдадыр шыгырдап капка ачыла, каз-үрдәк тавышланып ала. Кемнеңдер мунчасыннан куе төтен күтәрелә: эшкә киткәнче томалап, мунча чабынмакчылар.

Ачлы-туклы авыл үзенең морҗаларыннан сыек кына төтен бөрки, зур өметләр, матур хыяллар белән сугыш елының тагын бер көне туып килә. Кырыен кычыткан баскан киртәләрдән, су буендагы ямьшәйгән мунчалардан, авыл кырыендагы ат абзарларыннан, янгын сараеның каланчасыннан — бөтен авылдан дөньяга моң тарала, ул моң төнлә төшкән чык белән бергә күккә аша.

Авыл сулый, үзенең алтмышка якын ирен сугыш кырына озаткан авыл моң катыш җай гына сулый.

Ындыр арты урамыннан балта, очланган казык күтәргән, аркан белән бозау җитәкләгән Әхмәтша карт атлый. Ат караучының ат абзары ишеген авыр шыгырдатып ачканы ишетелә. Халык озын җәйге хезмәт көнен каршылый. Шул халыкнымы җиңәр фашист? Шул чишмәләргәме, шул киртәләргә, шул бәрәңге басуларынамы фашист хуҗа булыр? Гыйззәтуллинның бервакытта да авылда мондый таңны күргәне юк иде. Күрәсең, училищеда уку аны үстергән, тормышны, табигатьне нечкәләбрәк аңларга өйрәткән.

Юк, мондый табигате булган, мондый чыдамлыгы булган халык беркайчан да беркемгә дә кол булмас! Мондый таңы, мондый һавасы булган халык иң зур бәхеткә — ирекле, тук, тыныч тормышка лаек. Ләкин бит таңнар Германиядә дә матурдыр? Анда да шушындый мөлаем авыллар бармы икән? Германиядә дә кычыткан үсәме икән? Без инде җиребез азат булганчы дип өмет белән яшибез, шатлык көтәбез. Ә аларның балалары нәрсә уйлый икән? Әйтик, ниндидер Альфред яки Вилли үзләренең әтиләре Днепр буенда сугышта йөрүне нәрсә дип аңлыйлар икән? Немец икәнсең — яшәү өчен Германияң бар бит! Кояш сезгә дә төшә, яңгыр сезгә дә ява бит? Нигә безнең җиргә кердегез? Нигә барыгыз да бер булып сөйләшеп, кире борылып кайтып китмисез, нигә шундый матур таңнарда окопларда ятасыз?

Гыйззәтуллин бу сорауларга әле җавап таба алмый, чөнки ул әле укуны тәмамламаган.

Училищены исән-сау тәмамлап булса, алга таба укырга кирәк. Һәм, һичшиксез, сайланган юлны үзгәртергә кирәк булыр. Сугыштан халык ярты-йорты гына кайтыр. Авыр булыр. Йә агрономлыкка, йә председательлеккә укырга кирәк. Зират астыннан суны зур буа белән буарга. Бөтен су буенда иңләп-буйлап йөзәрлек зур буа булсын. Кычыткан җыеп, алабута җыеп, балаларына аш әзерләп йөргән хатын-кызларны авыр хезмәттән азат итәргә. Ватан өчен канын коеп кайткан агай-

ларның кадерен белеп кенә яшәргә. Үлеп калганнарны онытмаска. Үзеңнең бөтен гомереңне әнә шул максатларга багышларга.

Аргы як урамда көтү куа башладылар.

Гыйззәтуллин учак яныннан торды, өенә таба атлады. Каникул әле башланып кына килә иде...

Сораулар һәм биремнәр

1. Авыл табигатенең матурлыгы, яме нәрсәләргә бәйле? Нигә алай? Сез Гыйззәтуллин белән килешәсезме?

2. Гыйззәтуллинның күңеле тулы моң. Кешегә моң каян килә? Сез үзегез яки бер-берегез турында «күңеле моңлы» дип әйтә алыр идегезме?

3. Бер кыш белем алу Гыйззәтуллинга нинди сыйфатлар өстәгән? Ул кайсы якка үзгәргән?

4. Бүлек исеменең матурлыгын аңлатып карагыз.

5. Әсәрнең сурәтле теленә игътибар итегез. Үзегезгә аеруча ошаган урыннарны укып күрсәтегез.

6. Үзегез дә авылыгыз турында кечкенә хикәя язып карагыз.

ЧЫНЫГУ ТУРЫНДАГЫ ӘСӘР

Кырык беренче ел — Бөек Ватан сугышы башланган ел, ул шуның белән тарихка кереп калды. Автор «сугыш елы балалары» дими, нәкъ менә сугыш башланган елны атап әйтә. Нигә әсәргә шундый исем куелган икән? Повестьта геройларның бер ел эчендәге тормышлары гына тасвирланмый бит, ул сугыш беткән вакытны сурәтләү белән тәмамлана.

Язучы гүяки Зарифуллиннар, Гыйззәтуллиннар, Әлтафиләр кебек син дә уйлан, баш ват: үзең эзләп тапкан җавап, ачыш кына кадерле була дип әйтергә тели. Әсәр чынлап та уйландыра, чөнки ул тормышның без үзебез күрмәгән, кичермәгән чоры белән таныштыра. Автор шулкадәр оста тасвирлый, син ул малайларны күреп, янәшәләрендә генә басып торасың кебек. Алар белән синең арада охшашлык бар, чөнки синең дә дәресеңне белмичә газапланып, кызарып басып торган чакларың булгалады; бик йоклыйсы килеп тә, йокларга ярамаган чактагы интегү, йокы белән көрәшү

дә таныш сиңа. Сугыш турында мавыгып тыңлаганың яки укыганың, табигатькә карап хозурланганың, «Нигә алай?» дип, тормыш турында уйлаганың бар.

Малайлыкның, балачакның кайсы чорда да кабатланып торган үз сыйфатлары, үз холкы-гадәтләре бар икән. Ерак елларда калган малайларны-кызларны да танып, аңлап була икән. Менә шундый нәтиҗә ясап куясың син. Таныш икән, димәк, аңа битараф кала алмыйсың, синдә йә теләктәшлек, йә риза булмау хисе туа. Ягъни ул геройларга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерәсең, чагыштыра һәм бәяли башлыйсың.

Үзебезне сынап карыйк. Кемнәр белән таныштык әле әсәрнең бу бүлекләрендә? Әле кичә генә күмәк хуҗалык басуларында көлтә җыйган, бәрәңге ташыган, уч төпләре бирчәйгән чабаталы малайлар. Атасыз калган тәртипсез малайлар. Аркага капчыкларын асып, кемнеңдер теләге буенча укырга килгән малайлар.

Киемнәре кызыгырлык түгел, бит-кулларын да чиста дип әйтеп булмый, өстәвенә укырга да үз теләкләре белән килмәгәннәр. Кыскасы, үрнәк булырлык малайлар түгел. Шулай да ни өчен, таныша башлау белән, бу малайларга-кызларга ярдәм итәсе, аларның хәлен яхшыртасы килә соң? Башта, мөгаен, алар арасында автор үзе дә булганга, «мин» дип синең белән «күзгә-күз» карап, үз итеп сөйләшкәнгә күрәдер. Укый торгач, аларны ихтирам итә башлыйсың — баштарак шактый мескен булып күренгән ул малайлар ачлыкка, салкынга түзәләр, сугыш чорының авыр эшләрен үз җилкәләрендә күтәрәләр. Гомумән, сугыш ахырына кадәр, белем дөньясының никадәрле серләрен-хикмәтләрен ачып, тирә-юньгә игътибар белән карарга, уйланырга өйрәнәләр алар.

Юк, дошман илебезне буйсындыра алмаган кебек, сугыш Әлтафи, Гыйззәтуллин, Зарифуллиннарны да җиңә алмады. Нинди генә авырлыклар, михнәтләр күрсәләр дә, алар максатларына ирештеләр: укытучылар булдылар. Шул бит инде аларның җиңүгә керткән өлешләре, алар да — җиңүчеләр бит!

Тагын бер ачыш ясыйбыз — менә ни өчен Мөхәммәт Мәһдиев бу әсәрнең исемен шулай дип куйган икән: сугыш барган дүрт ел эчендә бу геройлар балалыктан үсеп чыктылар. Кырык беренче елны кая, нигә килгәнлекләрен дә белмичә диярлек педучилищега җыелган

балалар сугыш елларында чыныгып, олыгаеп, егет булып җиттеләр. Үзләре балаларга белем бирерлек булдылар һәм тормышның бик күп сынауларында сынатмаслык рухи көч керде аларга.

Кереш сүзендә автор үзе дә бу турыда ачык әйтә: «Безнең балалык вакыты дәһшәтле Ватан сугышы елларына туры килде. Ватан язмышы дигән олы хис безнең күңелләргә әнә шул елларда кереп урнашты. Без балалык чорыбызда таякны ат итеп уйный алмадык, бәлки, чын атлар җигеп, колхоз басуында эшләдек... Атлар азайгач, үгез җиктек, сыер җиктек. Ни генә эшләсәк тә — мәктәптә пионер сборы уздырабызмы, җилкәгә сәнәк салып, иген басуына чыгып китәбезме — без моны, явыз дошманны җиңү сәгатен якынайту өчен дип, чын күңелдән ышанып эшли идек...»

Тормышка мәхәббәт, яшәү көче, батырлык турында матур әдәбиятта күпме гүзәл әсәрләр иҗат ителә. Табигать кочагында яшәү, ил буйлап, дөнья буйлап сәяхәт итеп йөрү, кешеләр белән теләгәнчә аралашу — язучы өчен зур бәхет, әлбәттә. Әмма бәхетнең башка дәрәҗәдәгесе, бүтән үлчәмдәгесе дә бар әле. Ул — нинди генә хәлдә дә, нинди генә шартларда да олы җаныңны, рухи көчеңне, корычтай ихтыярыңны кешеләргә үрнәк итеп куя алу, үлем кочагыннан ычкынып, язмышны җиңә алу һәм халкыңа рухи көч бирерлек әсәрләр иҗат итү. Мондый бәхетне Тукай, Җәлил кичергән.

Корыч ихтыярның мисалы рус әдәбиятында Николай Островский булса, татар әдәбияты, хаклы рәвештә, үзенең Фәнис Яруллины белән горурлана.

Фәнис Яруллин

(1938 елда туган)

Хәрби күнегүләр вакытында имгәнеп, Фәниснең гәүдәсе хәрәкәтсез кала Еллар буена сузылган хастаханәләр... операция бүлмәләре... йокысыз төннәр... Үзен канаты сынган бөркет итеп тойган егет җаны сыеныр урынны әдәбиятта таба, аны иҗат «газабы» дәвалый, хыялларына канатлар куя. Бүлмәсендә яткан килеш тә аның күзләре күпне күрә, колагы күпне ишетә, тынгысыз җаны барысын да тоеп-сизеп тора. Ул яшел утрауларга «хуҗа була», танышлары арасына «чыга», әдәбиятка үз сукмагын салып атлап китә. Бүген инде ул — Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге премияләр лауреаты, шигырьләр, җырлар, балладалардан, лирик һәм юмористик хикәяләрдән торган күп китаплар авторы.

Кыю рәвештә театр сәхнәсенә дә күтәрелде ул, тамашачылар аны танып, үз итеп, яратып кабул иттеләр. 2001 елда шагыйрь Фәнис Яруллинга «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелде.

Фәнис Яруллинның үзен, чынлап та, хуҗа итеп хис итә торган тагын бер дөньясы — балалар әдәбияты. Аның берничә шигыре һәм хикәясе белән танышыйк. Бу әсәрләр сезнең турыда кызыклы итеп язылганнар. Үзегезне шул геройлар урынына куеп карагыз, сезгә дә алар кичергән хисләр танышмы? Әсәрләрнең матурлыгы нәрсәдә икәнлегенә игътибар итеп укыгыз.

ГАЙНИ

Киткәннәрме соң майлап?
Урамнар бүген тайгак.
Булмаса да этүче,
Егыла һәрбер үтүче.

Мәктәптән кайта Гайни,
Аның аягы таймый.
Итекләре дагалы —
Аның шул шәп чак әле.

Күрә Гайни: бер чатта
Бер карт егылып ята.
Йөгереп бара, торгыза,
Тагын шактый юл уза.

Барган саен, отыры
Күбрәк очрый карт-коры.
Гайни кебек нык терәк
Бик күп кешегә кирәк.

Кычкыра шулчак Гайни:
— Минем аягым таймый,
Ябышыгыз кулларга,
Егылмассыз юлларда!

Арыганнар, талганнар,
Егылганнар, ауганнар —
Бар да аңа тотына,
Зур бәладән котыла.

Командирдай иң алдан
Әй басып килә Гайни!
Уң ягында ун бабай,
Сул ягында ун әби.

Сораулар һәм биремнәр

1. Гайнинең шәп малай булуын ничек исбатлар идегез: итекләре дагалы булганга, аяклары таймаганга күрә генәме? Автор аның нинди сыйфатын тасвирлап биргән?

2. Шигырь юмор белән, ягъни Гайнигә теләктәшлек белдереп, аның эш-хәрәкәтенә уңай мөнәсәбәттә язылган. Автор шул ук вакытта аңа хәйләкәр генә елмаеп карап тора. Укучы

да, елмаеп, Гайнигә «молодец» («афәрин») дип әйтеп куя. Менә шул юмор нинди сүзләрдә, кайсы юлларда аеруча ачык сизелә? Мәсәлән, гадәттәгедән арттырылган урыннарны табыгыз.

3. Шигырь нинди интонация белән укыла? Юлларның озынмы-кыскамы булуына игътибар итегез. Рифмаларны күрсәтегез; шигырьнең строфаларга бүленешен карагыз.

4. Соңгы строфаны рәсем итеп ясагыз.

ӘЙБӘТ ТӘ МИНЕМ ӘБИ!

Ни тотса шуны булдыра —
Минем әбием шәп тә!
Аның эшләгән эшләрен
Бетералмам сөйләп тә.

Төймәне өздереп кайтсам,
Тагып бирә шалт кына.
Галстугымны югалтсам,
Табып бирә ялт кына.

Китапларны, дәфтәрләрне
Тикшереп, карап тора.
Ертылган битләре булса
Тота да ябыштыра.

Тәмле сыйлар белән дә ул
Гел мине сыйлап тора.
Мин таратып ташлый торам,
Әбекәй җыйнап тора.

Күңелләре күтәрелә,
Бер ертыкны ямаса.
Минем өчен мәктәпкә дә
Барыр иде... яраса.

Килсә мәктәпкә берәрсе
Онытып кирәк китабын,
Уйлыймын шунда эчемнән:
Әбисе юк, мөгаен.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдәге «мин» образын (сурәтен) кем дип күз алдына китерәсез: шигырьне язган Фәнис Яруллин дипме әллә башкачамы? Үзе турында язмаган булса, ни өчен шагыйрь «мин» дип язды икән?

2. «Мин»не мактар идегезме әллә юкмы? Ни өчен икәнен исбатлагыз. Әбинең холкы-сыйфатлары турында ни әйтерсез?

3. Шигырьдәге юморны, аның алымнарын аңлатып карагыз, аеруча кызыклы урыннарны табып күрсәтегез.

4. Әбисе кунакка китсә, шигырьнең герое (без аны лирик герой дибез) нишләр иде икән? Шул турыда хикәя яки шигырь язып карагыз.

5. Үзегез һәм әбиегез, әниегез турында уйланыгыз, сөйләгез. Сез аларга күп мәшәкатьләр тудырасызмы?

ЯЛКАУ ЯЛЫ

Әти әйтә: «Әй улым,
Бигрәк әллә нинди син.
Эш турында әйтмим дә,
Ял итә дә белмисең».
Ял итәргә аңарга
Нинди белү кирәктер?!
Минем кебек ял иткән
Болай да бик сирәктер.
Көннәр буе өйдә мин,
Ятамын гел диванда.
Телевизор карыймын,
Мультфильмнар булганда.
Йөгермимен, чапмыйммын,
Сазга батып кайтмыйммын.
Чапсын әйдә юләрләр,
Мин аякны саклыйммын.
Киерелеп, сузылып
Ял итәм дә ял итәм.
Әнә шулай ял итеп,
Кай көнне арып бетәм.
Бәйләнәләр гел юкка,
Кызык та бу өлкәннәр.
Әйтерсең лә үзләре
Миннән шәп ял иткәннәр.

Сораулар

1. Шагыйрьнең үз героена мөнәсәбәте уңаймы, киреме? Ни өчен алай дип уйлыйсыз?

2. Шәп ял итү ничек була? Гомумән, ял нәрсә ул: көне буе чабып, уйнап йөрүме (алайса, нигә «уйнап арыдым» диләр) әллә хәрәкәтсез тик ятумы?

3. Сез ничек ял итәсез? Вакытыгызны алдан планлаштырып, бүлеп куясызмы? Югалган вакытның кадерен беләсезме?

АК ТӨНБОЕК

(Хикәя кыскартып алынды)

Кечкенә чакта Гадилә белән Шәһрәт бергәләп су коенырга бик яраталар иде. Әниләренең эшкә киткәннәрен генә саклап торалар да әллүк Каран буена. Камышлар арасыннан кыр үрдәкләрен табып булмаган шикелле, аларны да эзләп таба алмыйсың. Иреннәре күгәргәнче, тешләре тешкә бәрелгәнче, судан чыкмый алар. Гадилә йөзәргә бик ярата иде.

— Кара әле, Шәһрәт, мин әнә теге төнбоек яфрагына кереп утырсам, күтәрә алыр идеме икән? — ди ул.

— Юләр, әллә үзеңне бик җиңел дип беләсеңме? Төнбоек яфрагы түгел, мин дә көчкә күтәрәм бит сине.

— Синең мине күтәреп караганың да юк әле.

— Теге чакта, аягыңа пыяла кадалгач, кем апкайтты соң?

Алар шулай сөйләшеп утыралар. Аннан кыз тагын сорау бирә:

— Шәһрәт, нишләп агачлар суда батмый да, кешеләр бата, ә?

— Мин каян белим. Кеше җанлы бит, шуңа батадыр.

Гәпләшеп утырганнан соң, алар тагын су коеналар, комда кызыналар. Тәннәренә җылы кергәнче генә, яр башында утыралар да күлгә яңадан кереп китәләр. Күлдән төнбоек чәчәкләре җыялар. Гадилә ак төнбоекларны бик ярата. Ул яр башына менеп, бер ноктага карап утыра-утыра да, еракта матур чәчәк күреп, кинәт күлгә сикерә. Йөзү тәмен белгәч, үзеңнең батмаячагыңа тәмам ышангач, һаман саен эчкәрәк керәсе, ераккарак колач саласы килә бит. Гадиләне дә сихри ераклык, күл эчендәге гүзәллек үзенә тарта.

Бервакыт Гадилә күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга уйлады. Күл өстендә сарылы-аклы төнбоек шулкадәр күп, әйтерсең зәңгәр күлгә янып торган йолдызлар таратып ташлаганнар. Гадилә шул җем-җем итеп тору-

чы йолдыз-чәчәкләрне өзеп ала да чәчләренә кадый, өзеп ала да чәчләренә кадый. Ә чәчәкләр эчкәрәк кергән саен матуррак. Вак дулкыннар өсләрен су белән коендырып та китсәләр, алардан да гүзәл, алардан да сокландыргыч нәрсә юк төсле. Яр өстеннән караганда Гадилә төнбоеклар арасыннан күренми дә диярлек. Чәченә күп итеп чәчәкләр кадагач, үзе дә чәчәк бәйләменә охшап киткән. Шөһрәт аны күздән ычкындырмаска тырыша, һәр хәрәкәтен күзәтә. Кыз ераккарак китә башласа:

— Бик эчкә кермә, Гадилә,— дип кисәтеп куя. Ә Гадилә аның саен киреләнә. Хәле беткәнен сизсә дә, кире борылып чыгарга уйламый. Әнкәсенең тешләре шикелле ак чәчәкләр, аны үзенә чакыргандай, әкрен генә тирбәләләр. Иң матурын, иң агын өзим ди торгач, ул тәмам арый. Салкын суда озак булгангамы, аякларын көзән җыера башлый. Шөһрәт, Гадиләнең бер батып, бер калкып маташканын күреп, күлгә ташлана. Ул килеп җиткәнче, кыз арудан һәм куркудан аңын югалткан һәм шактый гына күләмдә су йотып өлгергән була. Шөһрәт аны көч-хәл белән генә ярга алып чыга. Ләкин Гадиләдә җан әсәре булмый.

— Гадилә үлде, Гадилә үлде! — дип кычкыра-кычкыра, печәнчеләр янына чаба Шөһрәт. Колхозчылар, килеп, Гадиләгә ясалма сулыш алдыралар. Озак, бик озак азапланганнан соң гына, кызга җан керә. Аны атка салып алып китәләр.

Берничә көннән инде тәмам терелеп өлгергән Гадилә Шөһрәтләргә килеп керде:

— Әйдә, Шөһрәт, сине әти чакырды.

— Нигә?

— Кергәч белерсең.

Шөһрәт, Гадиләнең батуында үзен гаепле санаганлыктан, курка-курка гына кыз артыннан иярде. Ләкин аның куркуы юкка икән.

— Герой керде, герой,— дип каршылады аны Гадиләнең әтисе.

— Мин нинди герой булыйм ди, Илгиз абый.

— Кызны үлемнән коткаргансың бит. Маладис икәнсең. Герой дими сине кем дисең инде. Шуның өчен үзеңә бернәрсә алып җиппәрдем әле. Беләсеңме? Кәчтүм-чалбар! Кәчтүмнең дә нindie әле! Менә дигән егетләрские. Товары да шыгырдап тора.

Гадиләнең этисе, гомер буе сатучы булып эшләгәнлектән, һәрнәрсәне шулай мактарга өйрәнгән иде. Әлеге костюмны да төрлечә мактый-мактый, Шөһрәт тирәсендә бөтерелгәли башлады.

— Яле, егет, үз киемнәреңне сал да менә бу лавсан кәчтүмне киеп җиппәр. Әйдә-әйдә, беркемнән дә оялма. Биредә чит кешеләр юк.

— Минем кәчтүм бар инде, Илгиз абый.

— Бар өстенә бар сыя ул. Шундый зур батырлык эшлә дә, понимаешь, бүләк тә алма, ди. Аннан нәрсә була ул? Әллә соң кәчтүм ошамыймы?

— Ошый да...

— Ошагач, давай ки!

Шөһрәт Илгиз абыйсының сүзен тыңламый булдыра алмады. Ничек шундый шәп костюмнан баш тартасың инде? Андый костюм беркемдә дә юк бит. Ә Шөһрәттә булачак.

Шөһрәт Гадиләләрдән тәэсирләнеп чыкты. Гадиләне судан тартып чыгаруны зур батырлыкка санап, чын күңелдән рәхмәт әйтүләре һәм кыйммәтле костюм бүләк итүләре Шөһрәтне нык дулкынландырды. Озак кына ул күңелле кичерешләр тәэсирендә йөрде. Ә инде бу вакыйга онытыла башлагач, авылда корреспондент дип даны чыккан, район газеталарында уймак кадәр мәкаләләр бастыручы Рәмил моны куертып җибәрде. Беркөннәрне ул, аркасына фотоаппарат асып, кулына блокнот тотып, Шөһрәтләргә килеп керде.

— Ну, Шөһрәт, сиңа исемне белеп тә кушканнар икән. Минем аркада син шөһрәт казаначаксың,— диде ул.

— Миңа бернәрсә дә кирәкми,— диде Шөһрәт, турсаеп, чөнки очраган бер кешенең үзенә төртеп күрсәтүләреннән һәм артык мактау сүзләреннән туйган иде.

Рәмил үзенең шактый калын блокнотына Шәһрәтнең «җаваплар»ын язып утырды. Озак та үтми ул язып җибәргән мәкаләләр район һәм республика газеталарында басылып чыкты. Газетаның шул ук санында аның «Суга батучыны коткарган өчен» медале белән бүләкләнүе турында указ да бар иде. Бу кинәт килгән дан малайны әллә нишләтеп җибәрде.

Дан иярле булмаса да, кайберәүләр аңа атланырга, шуның белән тормыш юлындагы барлык киртәләрне сикереп чыгарга телиләр. Шәһрәт исә бу атка үзе атланмады, иярга аны башкалар утыртты. Тик аннан ни файда? Үзе дә аңламастан эшләп ташлаган батырлыгы аны башка балалардан аерды.

Шәһрәт үсте. Кайчандыр аның батырлыгы турында язган газета битләре саргайды һәм килгән бер кешегә бармак бите белән төртә-төртә укып күрсәтүләрдән тәмам туздгы. Хәрефләр җуелды. Газета битендәге сүзләр җуелса да, Шәһрәт күңелендә ул һаман сакланды.

Гадиләне ул үзенә бурычлы дип саный башлады. Шул хакта кызның исенә төшергәләүдән дә тартынмады. Бервакыт ул, ничәнчедәр класста укыганда:

— Гадилә, өйгә эшләрне эшләдеңме? — дип килеп керде.

— Эшләдем.

— Кая, алайса, миңа дәфтәреңне бир. Тиз генә күчереп куйыйм.

— Ничек инде сиңа дәфтәр бирим? Аңламасаң сора, аңлатырмын. Ә кешедән күчерү гаделсезлек бит.

— Синең аңлатканнарыңны тыңлап торырга вакытым юк. Малайлар белән тауга менәбез.

— Алайса, кайткач килерсең.

— Икешәр тапкыр килергә үзеңне кем дип белдең? — дип кызып китте Шәһрәт. Ул бу минутта үзен кимсетелгән, кыерсытылган итеп тойды: — Әле килгәнемә рәхмәт әйт. Үзеңнең миңа бурычлы икәнеңне онытма.

Гадиләнең өстенә утлы кисәү ыргыттыLармыни? Кызу булып китте. Шөһрәт авызыннан мондый сүзләр элек тә ишеткәләсә дә, һаман үзенең дөньяда яшәве белән кешегә бурычлы икәненә күнегеп җитә алмый иде ул. Акылы, җаны моңа каршы төшә. Ул үзе кемгә дә булса яхшылык итсә, шуны кешенең исенә төшерергә чын-чынлап ояла. Башкаларны да үзе кебек итеп күз алдына китергәнлектән, адым саен Шөһрәтнең үз яхшылыгы турында тукып торуы кызны рәнҗетә иде.

— Мә, оялмасаң күчер,— дип, дәфтәрен атты ул Шөһрәткә.

— Оялырга, мин кеше әйберен урламаган,— диде Шөһрәт.

Караклыкның башы энә урлаудан башлана, диләр. Ялкаулыкның да башы менә шулай кеше хезмәтеннән файдаланудандыр, мөгаен. Шөһрәт баштарак вакыты җитмәгәндә яки үзе аңламаганда гына Гадиләдән күчергәләсә, тора-бара бу аның гадәтенә кереп китте. Кыз да гел-гел каршылык күрсәтмәде, чөнки теге сүзләрне ишетүдән курыкты.

Укытучы Шөһрәтне тактага чакырса да, Шөһрәт Гадиләнең авызына гына карап тора башлады. Гадилә кырый рәт парталарның иң алдагысында утырганлыктан, кызның күп кенә хәрәкәтләре укытучы карашыннан читтә кала иде. Әмма укытучы күрмәсә дә, классташлары һәммәсен дә күреп, белеп тордылар. Алар Шөһрәтне үрти үк башладылар. Бигрәк тә ерык авыз Кәшиф җанына тиде.

— Синең эшләр хутта, малай, ә? — диде ул бер тәнәфестә.— Өйгә бирелгән мәсьәләләрне чишеп, баш ватасың юк. Гадиләдән күчерәдең куйдың. Такта янына чыксаң да, Гадилә коткара. Берәр «биш»легә укучы кыз бәкегә дә төшми, ичмасам, тартып чыгарыр идем дә үземнең дә бөтен эшемне шуңардан эшләтер идем.

— Кызыгасыңмыни? — диде Шәһрәт, мактанулы тавыш белән.

— Кызыгам. Кем шундый кәләшкә кызыкмасын!

Кәшифнең авыз тутырып «кәләш» дип әйтүеннән кызлар хихылдап куйдылар. Ә Шәһрәт, тагын да масаебрак:

— Кәләш шул! — диде.— Беләсегез килсә, Гадилә минем өчен утка да, суга да керәчәк.

— Суга төшкәнен беләбез инде. Утына да керер — анысына да ышанабыз, әмма кәләш булмас,— диде тыйнак табигатьле Тәлгать. Ул Гадиләне бик якын итә һәм Шәһрәт алдында кызның шулай түбәнсенүен һич тә кичерә алмый иде. Шәһрәт тә Тәлгатьнең Гадиләгә тыныч кына карый алмавын сизә, шуңа күрә Тәлгатькә үзенең өстенлеген күрсәтергә тели иде.

— Телисезме, менә бөтен класс алдында Гадиләдән мин синең кәләшең дип әйттертәм?

— Булмый!

— Менә күрерсез.

Класска башка укучылар да җыела башлады. Тәлгать, Шәһрәтнең янына ук килеп:

— Әз генә акылың булса да, син мондый түбәнлекне эшләмәячәксең,— диде.

— Кем өчен түбәнлек бит,— дип авыз ерды Шәһрәт.

Колактан колакка сүз китте, кызлар бер-берләре белән пышылдаша башладылар. Ярык кыңгырау Кәшиф бу хәбәрне бөтен класска таратып өлгерде. Менә, ниһаять, йөгерә-атлый Гадилә килеп керде. Әллә йөгерүдән, әллә яшьлек дәртеннән аның йөзләре алсуланган. Елмаеп китәргә торган иреннәре, авыз эченнән шигырь укыгандай, сизелер-сизелмәс кенә кымшаналар. Гадилә класс бусагасын атлауга ук, Шәһрәт аның каршысына килеп басты. Класс, моңарчы күрелмәгән вакыйга көтеп, тып-тын калды. Ә Гадилә, берни аңламыйча:

— Нәрсә бар? — дип аптырап, дусларына карады.

— Гадилә,— диде Шәһрәт, кискен генә,— бөтен класска ишетелерлек итеп «мин синең кәләшең» дип әйт әле. Моңа ышанып җитмәүчеләр бар икән.

Гадилә, үзе белән шаяралар дип уйлап, урынына барып утырмакчы булды, ләкин Шәһрәт аның юлына аркылы төште:

— Давай әйт. Син бит миңа гомерең белән бурычлы...

Кыз кинәт агарынып китте. Елмаерга торган иреннәре усал кысылды. Ул Шәһрәтнең мыскыллаудан чалшаебрак торган йөзенә чалтыратып чабып җибәрде.

Класста әйтерсең бомба шартлаттылар, гөрс итте дә тынды. Гадилә, сумкасын да алмыйча, урамга чыгып йөгерде. Шуннан соң гына укучылар шаулапырга, кычкырышырга тотындылар. Шәһрәтнең яңагына Гадиләдән башка да өстәүчеләр булды. Ләкин ул инде авыртуны тоярлык хәлдә түгел иде.

Берничә көн Гадилә дә, Шәһрәт тә мәктәпкә килмәделәр. Бераздан классташ дуслары Гадиләнең район мәктәбендә укый башлавын ишеттеләр. Ә Шәһрәт, ярты ел каңгырып йөргәннән соң, кайсыдыр шәһәргә һөнәр училищесына китеп барды. Ике дусның язмышлары шулай аерылды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шәһрәтнең үзгәрүенә сәбәп булган вакыйгаларны сөйләгез.

2. Ялкаулыкка, масаюга бирелмәс өчен, кешегә нинди сыйфатларга ия булырга кирәк дип уйлыйсыз? Әсәрдә ул сыйфатларны кайсы геройларда күрдегез?

3. Сиңа ышанган дустыңны, якыннарыңны һәм, гомумән, кешеләрне түбәнсетү, рәнҗетү — түбәнлек, мәрхәмәтсезлек. Үзегезнең шундый хәлләргә очраганыгыз, кимсетелгәннәрне яклаганыгыз бармы?

ОЛЫ ҖАНЛЫЛЫК КЕЧЕ ЯШЬТӘН БАШЛАНА

Игътибар иттегезме, укучылар, Фәнис Яруллинның геройлары кайсыдыр яклары белән аның үзенә охшаганнар. Гайнинең киң күңелле, игътибарлы булуы, ярдәмгә килергә әзер торуы — аның үзен генә түгел, гомумән, тормышны матурлап торган сыйфатлар бит.

Янәшәңдә таяныр кеше булу куандыра, җиргә дә ышанычлырак басып йөри башлыйсың. Дөрес, әлеге Гайнинең таяныч булуын автор бер генә мәгънәдә — бозлы юлда аяклары таючыларга ярдәм итү рәвешендә генә сурәтли. Әмма без һич икеләнүсез әйтә алабыз: авыр вакытта Гайни кешеләргә ярдәм кулы сузачак, олы җанлы кеше булып үсәчәк. Андыйлар турында халык «тормышның терәге» дип зурлап әйтә. Үзеңнең булдыклы, көчле икәнлегеңне тоеп яшәү — бик әһәмиятле, кирәкле хис, канәгатьлек хисе ул. Чишмә сулары тамчылап җыелган кебек, кешелекле булуның зур сыйфатлары кечкенәдән, балачактан башлана.

Өстәвенә Гайнигә беркайчан да күңелсез түгел, чөнки ул үзенә эш-шөгыль таба белә. Югыйсә «Ялкау ялы» шигырендәге нәрсә эшләргә белмичә аптырап, эшсезлектән гаҗиз булган малай «картаеп» та өлгергән. Ялкаулыгын аклап маташа бит әле, җитмәсә. Үзебезнең дә ялкауланып киткән чакларыбыз күз алдына килә. Мондый чакта бөек шагыйребезнең шигъри юлларын искә төшерсәк, бик файдалы булыр:

> Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
> Аһ! оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.

Габдулла Тукайның ташка баскан хакыйкать кебек матур да, мәгънәле дә бу сүзләрен әбиләребез безгә гел әйтеп торалар югыйсә. Кайберләребез ул акыллы фикерләргә игътибар итеп җиткермибез шул. Әбиләр безгә әйтеп тә, эш кушып та карыйлар, аннан эшкә үзләре тотыналар. Алар — барысы да әйбәтләр, изге күңелледәр. Безне кайвакыт орышалар икән, димәк, үзебез гаепле: гел аларга салынып яшәү бер дә егетлек түгел бит инде. Ә менә әйбәт әби, күрәсең, оныгын бигрәк тә ярата инде, оныгыннан алда өлгереп, бөтен эшне ялт иттереп эшләп тә куя. Ярый ла оныгы артык иркәләнеп китмәсә. Әнә шулай мөлаем генә елмаеп, геройларын бик сизгер күңел күзеннән үткәреп яза Фәнис Яруллин.

«Ак төнбоек» хикәясендә исә ул җитди мәсьәлә күтәрә.

Кешегә яхшылык эшләү — бик күркәм гадәт. Әмма шуның белән гел мактанып, кешенең исенә төшереп, гел битәрләп тору бөтен яхшылыгыңны җимерә дә ташлый. Эшләгән яхшылыгың өчен «хак» сорап тору — гайрәтне чигерә торган сыйфат. Ул тумыштан килми,

бик масаеп киткән чакта бу яман гадәт, йогышлы чир кебек, кешенең холкын үзгәртә дә куя. Мондый түбәнлеккә төшүнең, хәер, үз «бәясе» дә бар: Шөһрәтнең яңагына сугалар. Җиңел генә шөһрәт казанмакчы булган Шөһрәтнең дусларыннан алган җәзасы бу. Өстәвенә балачактан уйнап үскән дустын югалтты. Монысы инде — Шөһрәт өчен, чыннан да, зур җәза. Ә бит Гадилә турында ничек матур итеп кайгырта белә, дөньясы нинди бизәкле, җаны тыныч, күңеле саф иде. Дуслыклары да төнбоеклы күлдәй матур иде. Масаю харап итте, малай чакта чын егетләрчә була белгән Шөһрәт егет булып килгәндә үзгәрде: күңеле тарайды, җаны вакланды.

Шулай да ул тагын бер үзгәрер — матурлыгы, олы җанлылыгы кире кайтыр әле аңа. Фәнис Яруллин үз геройларына өмет белән карый икән, без дә мәрхәмәтле булыйк — кешеләрдә яхшы сыйфатлар җыңәсенә ышаныйк.

ЭЧТӘЛЕК

Халык авыз иҗаты
Җыр 4
Галиәсгар Камал
Беренче театр 19
Һәр көлүнең мәгънәсе бар 38
Сәгыйть Рәмиев
Уку 43
Авыл 45
Әхмәт Фәйзи
Тукай 49
Бәләкәй Апуш ничек зур Тукай булды? 75
Хәсән Туфан
Каеннар сары иде 80
Илдә ниләр бар икән? . . . 82
Гөлләр инде яфрак яралар 83
Аралагыз мине 86
Кайсыгызның кулы җылы? 87
Чәчәкләр китерегез Тукайга 88
Галимҗан Ибраһимов
Кызыл чәчәкләр 93
Әсәрдә гәүдәләнгән фикерләр һәм хисләр 128
Гариф Гобәй
Маякчы кызы 133
Маякчы кызы булу җиңелме? 165
Илдар Юзеев
Бакчачы турында баллада . 169
Йолдыз кашка турында баллада 172
Гаделлекне яклау, матурлыкны саклау 174
Ибраһим Гази
Мәүлия нигә көлде? 178
Өч Мәхмүт 181
Хикәяләү осталыгы 190
Чыңгыз Айтматов
Беренче мөгаллим 194
Яхшылык җирдә ятмый . 211
Ләбибә Ихсанова
Наил һәм Фаил 215
Әсәрнең геройлары 227
Роберт Миңнуллин
Энекәш кирәк миңа! 230
Әни, мин көчек күрдем! . . 231
Батырлык эшләр идем.... 232
Шундый минем туган ягым 233
Кайтыйк ла үзебезгә! 234
Мөхәммәт Мәһдиев
Без — кырык беренче ел балалары 238
Чыныгу турындагы әсәр . 255
Фәнис Яруллин
Гайни 259
Әйбәт тә минем әби! 260
Ялкау ялы 261
Ак төнбоек 262
Олы җанлылык кече яшьтән башлана 268

Учебное издание

Ганиева Флера Акрамовна,
Гилязов Ильдус Гилязович,
Исламов Фанис Фатхуллович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник-хрестоматия по татарской литературе для 6 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание четвертое, дополненное

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Ганиева Флера Әкрамовна,
Гыйләҗев Илдус Гыйләҗевич,
Исламов Фәнис Фәтхуллович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

Тулыландырылган дүртенче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова, А. М. Закирова,*
Г. Р. Ногманова

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.05.2006. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 17,0 + форз. 0,25 + вкл. 0,25. Нәшер-хисап табагы
14,43 + форз. 0,39 + вкл. 0,37. Тиражы 13 800 д. Заказ 3-329.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш.

Сәгыйть Рәмиев